Безнен
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
МИРАС
11
ноябрь 2017
ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ХӘМЗӘ ШӘРИПОВ. «АКЛЫШ АВЫЛЫ»

СӘЕТ ВАХИДИНЕ ЯД ИТҮ

19 октябрьдә «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгының «Манеж» күргәзмәләр залында Сәет Вахидинең 130 еллыгына багышланган «Татар кульязма мирасы: өйрәнү һәм саклау мәсьәләләре» дигән Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция узды. Чарада Казакъстан һәм Россиянең төрле төбәкләреннән килгән галимнәр катнашты.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

11 (287)

ноябрь 2017

1991 елның апреленнән башлап «Мирас»,
2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ
тарафыннан кабат гамәлгә куелып,
«Чын мирас» исемнәре белән чыкты.
2014 елның маеннан «Безнең мирас»
итеп үзгәртелде.



42



68 **УЛ МИҢА АБЫЙ ДА ИДЕ...** *Ирек Нигъмәти*

87 **БЕЗНЕҢ ИҢ ҮТКЕН ҺӘМ ИҢ КӨЧЛЕ КОРАЛ.** *Әлфия Шамова*

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Йосыф Баласагуни**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Төрек вә татар тарихы.** *Ә.Вәлиди*
9 **Вязовый Гай авылы тарихы.** *М.Вәльшин*
14 **Нырсы изгеләре.** *Р.Нотфуллина*
21 **Ленин хөкүмәтенең мөселманнарга мөрәҗәгате һәм госманлы матбугаты.** *Н.Дәүләт*
29 **Исемең һәм җисемең.** *Ә.Сибгатуллина*
34 **Мөслим – тарихи хәтерле төбәк.** *А.Әхмәтҗан*
38 **Фәнни-фәһемле китап.** *Г.Хаҗиева*

ТАТАР ГАМЕ

39 **Хәтер һәм туган тел.** *Р.Фәйзуллин*
42 **«Кутадгу билик» – затлы мирас** *(Матбугат конференциясе)*
46 **«Шыгырдан төене»н чишкәндә.** *Ф.Кутлу*

ДИНИ МИРАС

52 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

58 **Тажеддин Ялчыгол.** *Р.Галиуллин*
64 **«Тау бөркете буласым килде!..»** *Ш.Мостафин*
68 **Ул миңа абый да иде...** *И.Нигъмәти*
74 **Адаш абый яки Отрар хатирәсе.** *Л.Лерон*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН

81 **Шәехзадә Бабич**

СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ

84 **Татар хәрби разведчиклары.** *Р.Зарипов*
87 **Безнең иң үткен һәм иң көчле корал.** *Ә.Шамова*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

92 **Халыкка кайтарылган исем...** *Г.Давыдова*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Ленар Гобәйдуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР мәгариф һәм фән министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррирләре
Марат Закиров
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-92)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

СӘНГАТИ МИРАС

96 **Мандолина.** *Э.Каюмова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

98 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*
100 **Борынгы татар йолалары.** *Р.Батулла*

ХӘТЕР САГЫНДА

104 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе.**
110 **Ядкәрләргә – бер гасыр**
112 **Хотнядагы «Изге чишмә»**

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның ноябрь ае.**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**

118 **Мирасворд**

119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Ноябрь*

Заказ №А-2654. Тираж – 1700 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 23.10.2017
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Ул хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61
телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Аклыш авылы». Картон, майлы буяу. 2000 ел.
Х.Шәрипов рәсеме

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

Йосыф Баласагуни*

(1019-21 еллар – вафат елы мәгълүм түгел)



***
Атың яхшы булса, тормыш итү җиңел.

***
Буе кыска – кызу, ачучан булыр,
Низаг, җәнҗал, бәхәс ачучан булыр.

***
Борынгыдан бирле бер мәкаль килә:
Атаның урыны углына кала.

***
Яхшы ирнең сөяге кабердә черер, исеме яшәр.

***
Күтәрелгән саен арта ир гаме –
Баш үскәнчә арта бүрек үлчәме.

***
Нәрсә сирәк булса, шул кыйммәтлерәк –
Аны табу өчен күп хезмәт кирәк.

***
Бәхет кайда булса, шунда бар, йөре,
Кусалар да, көрәш һәм кайтма кире.

***
Куанма бәхтеңә – килер дә китәр,
Ышанма байлыкка – артыр да бетәр.

***
Тышы эче кебек, эче нәкъ тышы –
Менә шундый була чын тугры кеше.

Текстны ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

---

*Йосыф Хас Хаҗиб Баласагуни – шагыйрь, фәйләсүф, дәүләт эшлеклесе, атаклы «Кутадгу билик» («Котадгу белег» яки «Котайткыч белем» («Бәхет турында белем») дип тә әйтәләр) әсәре (1069) авторы. Караханлылар дәүләте башкаласы Баласагун шәһәрендә туган.

ТӨРЕК ВӘ ТАТАР ТАРИХЫ

Әхмәтзәки Вәлиди

ҖАНИБӘК ХАН [1]

Җанибәк тәхеткә утыргач та һәр тарафтагы әмирләр, ханнар бәйгатьләрен[2] яңарттылар. Бу җөмләдән русларның бөек кенәзе Симеон илә митрополитлары хан хозурына үзләренең тугрылыгын белгертергә килделәр. Җанибәк, күп кенәзләрне алмаштырып, төрле кенәзләр арасында дәвам иткән низагларны өзде.

Гыйрак гаҗәм тарафларында хөкүмәт итмәктә булган Һәлякү балалары, дин исламны кабул итеп, мәмләкәтләре тәмам бер ислам мәмләкәте хәленә дүнгән иде. 1313 нче елда Һәлякү тәхетенә үзенең балаларыннан Әбү Сәгыйть хан утырды. Тәдбирле хөкемдар түгел иде, үзенең ике угылын вә әмирләрен вә бәгъзе голәмәләрен үтертте. 23 ел кадәр хан иткәннән соң вафат итте (1336). Җиренә вәли гаһед[3] итеп берсен дә тәгаен итмәгән иде. Вафаты соңыннан ук мәмләкәте үз нәсленнән булган әмир вә шаһзадәләре арасына бүленеп бетте. Бәгъдад тарафларын Хөсәен бине Акбуга исемендә вәзире алган, Азәрбәйҗан вә Тәбриз тарафлары Әшраф бине Тимерташ исемендә берәүнең кулында калган иде.

Әшраф бине Тимерташ гаять залим вә тәдбирсез бер кеше иде. Мәмләкәт идарәсенә керешү илә мәмләкәт халкына хәдсез вә хисапсыз золым итә башлады. Тиешсез урында шәһәрләрне җимерә, адәмнәрне чебен урынына үтертә, голәмәләрне хур итә иде. Халкы җирләрен ташлап күчә, голәмәләр төрле тарафларга кача башладылар.

Ошбу Әшрафның казые – Мөхетдин исемендәге галим, Әшраф янынннан качып, Сарайга килде, мәчет эчендә халыкка вәгазь сөйләп, Мәлик Әшрафның золымын әсәрле итеп белдерде. Халык егълашты. Җанибәк ошбу мәҗлестә бар иде, аңа карап: «Әгәр

[1] Әхмәтзәки Вәлидинең 1912 елда Казанда дөнья күргән «Төрек вә татар тарихы» исемле китабыннан бер бүлекчә. Кайбер бүлекчәләр журналның 2015 елгы 9 һәм 11, 2017 елгы 9 нчы саннарында басылды.

[2] Бәйгать – берәүнең хакимиятен тануны, буйсынуны белдереп, аңа сүз бирү.

[3] Вәли гаһед – патшаның үз урынына тәхеткә утырачак варисы.

Җанибәк хан

ошбу падишаһ, кулында шулкадәр икътидар вә куәт була торып, Аллаһның колларын ошбу Әшрафның золымыннан коткармаса, Кыямәт көнендә барлык рәнҗетелгәннәрнең кулы аның итәгендә булыр», – диде. Солтан Җанибәк моннан тәэсирләнеп, йөз меңнән артык гаскәр җыйды, Һәлякү мәмләкәтен Әшрәф вә башкалар кулыннан коткармак өчен, ягъни моголлык, нәсел, милләт, дин кайгылары илә Мәлик Әшрәф өстенә сәфәр итте. Әшрәф, моның килүен ишеткәч, дүрт йөз кадәр тәва йөге кыйммәтле алтын вә җәүһәрләрен Орҗан шәһәренә озатты, үзе гаскәре илә Җанибәкне каршы алды. Гаскәре Җанибәк гаскәрен мәсхәрә итеп, атларының җөгәннәре җүкәдән, иярләре агачтан, имеш, дип көлеп сөйлиләр иде, каты җил-давыл уңаеннан Җанибәк гаскәре килеп тә чыкты. Әлеге гаскәр бер эш башкара алмый җиңелде. Орҗан голәмәсеннән берсе Әшрафны Җанибәккә тотып бирде, Җанибәк аны бик каты шелтә итте. Голәмәләр: «Үтерми калдыру ярамас, ул терек калса, халык аның бәласеннән котыла алмас», – диделәр.

Тәбриз шәһәре. Эжен Фланден рәсеме. 1840 ел

Җанибәк Әшрафны үтертте, башын Тәбризгә китереп, Мораган исемендәге мәчет алдына астылар. Бөтен Тәбриз халкы, Җанибәк ханга рәхмәтләр укып, Әшрафка ләгънәтләр итте, бөтен Тәбриз фәкыйрьләренә сәдәкалар таратты. Моннан соң Җанибәк, Тәбризгә килеп, солтан сараенда бер кичә үткәрде, иртәгесе көн, иртә намазын Галишаһ мәчетендә укыды һәм Мәлик Әшрафның җыйган хәзинәсен үзенең гаскәренә таратып бирде, башка шәһәрләрдәгесен халыклар үзләре бүлешеп алдылар. Угылы Бирдебәкне гаскәре илә Тәбриздә калдырып, үзе Сарайга кайтып китте. Юлда бик каты авырый башлады вә ошбу авыруыннан, Сарайга кайтып җиткәч, озак тормый вафат итте (1357).

***

Җанибәк голәмәдән берсе, галим Шәриф бине Габделхәмид тарафыннан тәрбия ителгән, гакылы камил булып, гыйлем вә әһле гыйлемгә артык дәрәҗәдә хөрмәт вә мәхәббәт итәр иде. Хан булгач та, бөтен голәмәне кочагына алды. Җанибәк хан булгач, голәмә Сарайда Үзбәк вакытыннан артык җыелды, чөнки Үзбәк Җанибәк кадәр үк голәмәгә хисапсыз акча яудырмый иде. Сарайның байлыгы вә дәрәҗәсе янәдән артты. Тәфтазани, Разый кеби галимнәр Җанибәк хозурында булдылар вә аның исеменә китаплар яздылар. Мәдрәсәләребездә укыла торган «Тәлхис» шәрхе булган «Мохтәссар әл-Мәгари» китабын Тәфтазани ошбу Җанибәк исеменә язды. Дибаҗәсендә[4] Җанибәкнең бөеклеген вә солтанатын зикер итеп, аңа һәдия иттеген сөйләде. Җанибәк хакында ошбу бөек галим: «Адәмнәр һәммәсе вә хаклык фәкать Җанибәккә генә сыгынырлар. Ул – Аллаһның күләгәседер, хаклык вә дөньяның горурлыгы вә һәйбәтедер», – диде.

[4] Дибаҗә – китапның кереш өлеше.



Тәфтазани китабы

Җанибәк үзенең гаделлеге, мәмләкәт идарәсендә бик оста тәдбире, гыйлем вә голәмәне химая итүдә күрсәткән һиммәтләре илә атасы Үзбәк урынын тотты. Җанибәкне ислам тарихчылары гына түгел, һәрбер вакыйгаларда татарларга (моголларга) һәртөрле кабахәтләр әйтеп яза торган рус руханилары да: «Җанибәк бик яхшы хан иде, христианнарга күп яхшылыклар итте, рус җиренә күп өлгетләр[5] бирде», – диде.

***

Бирдебәк хан, атасының бик каты авырганын ишетеп, Тәбриздән Сарайга кайтырга чыкты. Ул кайтып җиткәнче Җанибәкне дәфен иткәннәр иде. Сарай хөкүмәте халкы аны атасы урынына хан итте. Бирдебәк тәхеткә хәерсез аяк илә басты. Гаять бозык, сәләтсез, кара вә каты күңелле кеше иде. Хан булгач та барлык кардәшләрен, якыннарын үтертеп бетерде. Адәмнәр күтәрә алмаслык авыр хираҗлар[6] тәгаен итте. Моның кеби сәбәпләрдән Сарайда һәм бөтен мәмләкәттә бөек фетнә купты вә ошбу ихтилял вакытында Бирдебәк хан Кулпа исемендәге мирза тарафыннан үтерелде (1360).

***

Бирдебәкнең үз урынына калдырырлык кешесе калмады. Кулпа мирза ханлык мәнсабенә[7] менде. Кулпа кеби, Җучи нәселеннән булып, Бирдебәк урынына ханлыкка бер дәрәҗәдә хаклы булган шаһзадә, әмирзадәләр бик күп иде. Һәммәсе Кулпа урынын дәгъва

[5] Өлгет, өлгөтә – льгота, ташлама.

[6] Хираҗ – салым, нигездә мөселман булмаганнар түләгән.

[7] Мәнсаб – вазыйфа.

иттеләр. Кулпа тәхетттән төште. Кулпа кеби ничә шаһзадәләр бер-бер артлы тәхеткә менеп, икенчеләренең гаскәрләр илә килүе сәбәбеннән төшеп тордылар. Ошбу вакыт Кара диңгезнең гареб[8] тарафында булган Венгрия илә Хәзәр диңгезенең ике тарафы булган Кавказ вә Хәрәзем җирләренең бөтен шималь[9] тарафыннан гыйбрәт булган бөек Дәште Кыпчак мәмләкәтенең һәр тарафындагы әмирләр, вәлиләр үз башларына мөстәкыйль хан булуны дәгъва иттеләр. Күбесенең максаты бөтен Дәште Кыпчакка бөек хан булганлыктан, өзлексез сурәттә сугыштылар да тордылар. Ошбу аянычлы хәл 15-20 еллар дәвам итте. Бөтен Сарай хөкүмәте үзләренең ханнары кем идекен тәгаеннән белмәделәр.

Бирдебәк хан

ДӘШТЕ КЫПЧАК КУӘТЕНЕҢ ИДЕЛ БУЕННАН СЫРДӘРЬЯ БУЕНА КҮЧҮЕ

Идел буенда башсызлыкның дәвам итүе куәтнең Идел буеннан китүенә сәбәп булды. Җучиның углы Иҗен, Чыңгыз тарафыннан Дәште Кыпчакның шәркый тарафына, Сырдәрья буйларына, Бату кулы астында хан итеп тәгаен ителгән иде. Бу мәмләкәт Ак Урда исеме илә Иҗеннең балалары кулында дәвам итеп килде. Боларның куәт, шәүкәтләренә ихтилял килмәде. Сарайда шәргый ханнар хөкем итмәгәч, Идел буйлары, Русия, Болгар җирләре вә бөтен Дәште Кыпчак бу Ак Урда ханнары кулында калды[10]. Мәмләкәтләрнең хакимнәре алар булдылар. Сарай тирәсендә, Идел, Урал буйларында күчеп йөри торган татарлар, кыпчаклар төпле идарә, куәт астына керергә Сырдәрья, Иргыз, Савык тарафларына агыштылар. Бирдебәктән 15-20 еллар соң Сырдәрья тарафлары, хәзерге кыргыз сахралары Идел буе татарлары, кыпчаклар илә туп-тулы булган иде. Ул вакыт Азиянең иң куәтле падишаһы (Сәмәрканд ханы) Тимерләнднең гаскәрен Ак Урда ханы Ырыс ничә мәртәбәләр ватты. Шул вакытта Идел буенда Сарайны идарә итүче Мамай түрә, Сарайдагы ихтилялдан файдаланып, баш күтәргән рус кенәзлегенә каршы гаскәр җыярга теләсә дә, Идел буенда, Сарай тирәсендә татарларны бик аз тапты. Бәлки чиркәс, яһүд кеби халыклардан яллап гаскәр җыярга мәҗбүр булды.

Ак Урда хөкүмәте бөтен кыпчакны озак идарә итә алмады һәм үзенең идарәсе вакытында да мәмләкәтнең гареб өлешенә, Идел һәм Днепр буйларына ул кадәр әһәмият бирә алмады, бәлки күбрәк вакытын үзенең шәркый күршеләре илә көрәшеп үткәрде. ■

[8] Гареб – көнбатыш.

[9] Шималь – төньяк.

[10] Ак Урданы рус вә иран тарихчылары «Күк Урда» дип йөртәләр. – Авт.иск.

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

Вязовый Гай авылы тарихы*

Мөнир Вәльшин

ЯҢА АВЫЛЛАР

1911 ел... Столыпин реформасы. Бу елларда беркетелмәгән яңа җирләргә зур авыллардан гаиләләр күчергәннәр. Спас волостена, Терешка суының сул ягына егермеләп гаилә күченә һәм яңа авылга нигез сала. Аларның күбесе Иске Лебежайкадан Давыдовлар була, шуңа күрә бу авылның исеме Давыдовка дип аталган. Бирегә үк Вязовый Гай авылыннан Шәфиевларның өч гаиләсе килеп төпләнә. Шул елларда Сарай Тау болыны каршына, Терешка суының сул ягына, Елшанка авылыннан гаиләләр килеп, Александровка исемле авыл корган. Бу чорда күчеп утырган гаиләләргә өй салырга, ат алырга, дип, казнадан акча бирелгән.

МАҖАРЛАРДА ӘСИРЛЕК

1914 елда Беренче Бөтендөнья сугышы башлана. Мине, 1962 елда укуымны тәмамлап, Яңа Зеленай авылындагы «Берлек» колхозында агроном булып эшли башлагач, Минһач (Минһаҗ) бабай Юсуповка фатирга урнаштырдылар. Минһач бабай миңа үзенең язмышы турында байтак кына сөйләгән иде. 1914 елда ул Герман сугышына китә һәм озак та үтми, әсирлеккә алына. Аның белән Вязовый Гай авылы кешесе Касыйм Измайлов та булган. Алар ике ел дәвамында маҗар гаиләсендә, ялчылар булып, дуңгызлар ашатып, кукуруз, чөгендер үстереп яшәгән.

ОСТА КУЛЛЫ ГОСМАНЛЫ ӘСИРЕ

Рәсәй ягына да байтак кына кешеләр әсирлеккә эләгә. 1917 елда ике якның килешүе төзелгәч, аларны иреккә җибәргәннәр. Әсирлектән чыккан ике төрек, март аенда Сызраньнан көньякка юл алып, Терешка буена килеп җитә һәм елга аша чыкканда суга бата. Берсе боз астына китә, икенчесе исән кала. Спас авылын-

Уфалла арбасы белән йөк ташу

*Ахыры. Башы 10 нчы санда.

нан Шамуковлар кавеменнән булган бер юлчы госманлы әсире Хәсән улы Бәкәрне авылга алып кайта. Бәкәр үзен намуслы һәм һөнәрле кеше итеп таныта: кәҗә тиресен эшкәртеп хром итек, читек, ат-сыер тиресеннән аяк киемнәре, сандаллар тегә, ат җигемнәре өчен аркалык, эшлея, ступинь (зупин), камыт баулары (гужлар), йөгәннәр һәм башка әйберләр ясап, зур ихтирам яулый. Ул Шамуковларның Сәйдә исемле сеңелләренә өйләнә һәм аларның Хәмзә, Өммегөлсем, Шәүкәт, Әбүзәр исемле дүрт балалары дөньяга аваз сала. Бәкәр, гомере буе совет хөкүмәтенә тугрылыклы булып, җаваплы вазыйфалар башкарды, кырчылык бригадиры, совет рәисе булып эшләде. Хәзерге көндә Бәкәрнең оныклары Вязовый Гай авылында, Хвалынск, Новоспасск, Сызрань һәм Мәскәү шәһәрләрендә яши.

ДАНЛЫКЛЫ МАВИЯ

XX гасырның башында Зәйниләрнең дүртенче буыны Мавия дә үсеп җитә. Ике ел Хвалынскида укып, дүрт ел Сары Тау гимназиясендә белем эстәгән егет, физик яктан таза-сау, нык бәдәнле булу өстенә, тынгысыз эшкуар булып та җитешә. Аның белән бер сыйныфта, хәзерге Павловка районы Шаховское авылыннан Михаил Суслов та укыган. М.А.Суслов, большевиклар партиясенә кереп, революция идеяләре белән янып, яшьләрдән ячейка оештыра, соңрак партиянең күренекле җитәкчесе булып таныла, КПССның политбюро әгъзасы, Үзәк Комитет секретаре кебек зур дәрәҗәләргә ирешә. 1917 елда Хвалынскида аклар большевикларның ячейка әгъзаларын кулга алгач, Суслов Вязовый Гайда, сабакташы Мавиянең утарында байтак вакыт яшеренеп ятып, исән кала.

Мавия Идел аръягыннан, Духовницкидан арендага җирләр алып, югары сыйфатлы бодай үстергән, аны тегермәндә тарттырып, оны белән Сосновоборски, Пенза якларында сәүдә иткән. Бу елларда Пенза төбәгендә нигездә арыш кына иккәннәрен истә тотсак, авылдашыбыз җитештергән продукциягә ихтыяҗ шактый зур булган. Мавия саткан оннан «Саратовский калач» пешерелгән, Кузнецкида аның он сата торган кибете дә уңышлы гына эшләгән. Мавия шул заманның белемле кешесе булып, татар һәм урыс телләрендә газета-журналлар яздырган, аларны укып, Рәсәйдәге вакыйгаларны аңлап-төшенеп яшәгән.

Авылдашыбыз хәзерге Радищево районының Чауши авылына якын гына урнашкан урманга да хуҗа булган. 1911 елда хезмәткәрләрен Байкал тарафына җибәреп, бер көтү монгол токымлы чыдамлы атлар сатып ала һәм аларны бирегә китертә. Әүвәлгеләр, аның хезмәтчеләре дә намуслы, тугрылыклы кешеләр булган, дип сөйлиләр.

1917 елның октябрь аенда Петроградтагы вакыйгалардан соң, хөкүмәт белән идарә итү большевикларга, советларга күчкәч, Мавия, үзенең хөкемгә тартылачагын, мал-мөлкәте таланып бетәчәген белеп, утарын, ашлыкларын хезмәткәрләренә калдыра һәм гаиләсе, якын туганнары белән Урта Азиягә – Ташкентка кача.

ГРАЖДАННАР СУГЫШЫ

Вязовый Гайда Советлар хакимияте урнашканчы ук, 1918 ел башында фронттан кайткан солдатлар катнашында гражданнар сугышы башлана. Вязовый Гай авылыннан Хөсәен Алим улы Усманов Чапаев җитәкләгән 25 нче дивизиядә сугышчы булган. Авыл халкы гомер буе аңа «Чапай» дигән кушым исем белән дәште. Бүген ул яшәгән урам Чапаев исеме белән атала.

Азам Усман улы Иксанов, Тухачевский армиясендә сугышып, Уфаны акгвардия-

челәрдән азат итүдә катнаша һәм шул шәһәрнең кызына өйләнеп тә кайта. Әле дә авылда «Уфа кунагы» дигән гыйбарә бар.

1919 елның җәендә Вязовый Гай авылы аша Попов бандасы да узган. Әтиемнең сөйләве буенча, Идел аръягында поповчылар кызылларның отрядларыннан качып, Духовницкидан паром ярдәмендә Хвалынскига күчкән, шуннан соң Елшанка, Дворикиларны үтеп, Вязовый Гайга җиткән. Алар авылдан үзләренә азык, атларына солы алып, Сызрань аша акларның Сембердәге армиясенә барып кушылган. Поповчылар авылда үзләрен озаттырыр өчен җигүле атлар мобилизациясе ясап, йөкләрен төяткәннәр. Бабам Сафа Вәльшин белән аның күршесе Кәлим Ибраһимовтан да җигүле атлар таләп иткәннәр. Бабамнар, үзләре курыкканга күрә, атларга улларын утыртып җибәргәннәр. Шулай итеп, әтием Борһан һәм дусты Хөсәен, поповчыларның йөкләрен төяп, Сызрань юнәлешенә юл алган. Алар, Сызраньга җитмичә, Мордва Карагуҗасы авылы тавында тукталган. Поповчылар, пушкалар урнаштырып, окоплар казып, кызылларны каршы алырга җыенган.

Икенче көнне иртән, кызылларның отряды килеп җиткәч, көчле сугыш башланган. Әтием белән Хөсәен олауларның иң читенә урнашкан булып, атышлар башлангач, арбаларындагы йөкләрен тиз генә ташлап, елга буйлап атларын чаптырып, Ореховка юнәлешенә качканнар. Шулай качып-посып, бер тәүлектән соң, алар Дворянская Терешка аша Вязовый Гайга кайтып җиткән.

АЧЛЫК

Гражданнар сугышы узгач, Совет хөкүмәте бик читен хәлдә кала. Иң элек хәрби коммунизм чорында, армияне ашатырга, шәһәр халкын тукландырырга, дип, авыл халкыннан ашлыкны бушлай алалар. Игенчеләр ашлыкны бирми башлагач, баштанаяк коралланган азык-төлек отрядлары («продовольственный отрядлар») ярдәмендә, халыкны талыйлар. Шушы хәлләр бетеп өлгерми, 1920 елның көзеннән башлап 1921 ел буе Идел буенда яңгыр да, кар да яумый, кыш буе туфрак бураны гына очып тора, чәчкән иген үсми, шуның өстенә, Әстерхан ягыннан саранча көтүе печәннәрне, куакларны ашап корыта. Идел буенда яшәүче халык, аеруча татарлар ачлыкка дучар ителә. Ул елда бабама сигез кашыклы гаиләне ашату җиңел булмагандыр. Шунлыктан, бабам, кыйммәтле әйберләрен җыеп, атын җигеп, әтине ала да ерак Тамбов ягына юл тота. Сыркыды авылында бар мөлкәтен ашлыкка алыштыра һәм әтине Сәлимҗан исемле абыйга эшче кул итеп, кыш чыгарга калдырып китә. Бу елларда, әти сөйләвенчә, тиф авыруы таралган була. Әтием шул гаиләне тиф чиреннән дәвалап, утын ярып, өйләрен җылытып, мал-туарларын ашатып, коедан су алып һәм башка авыр хезмәтләрне башкарып, кышны шунда уздырган.

1921 елда әнием ягыннан бабам Алләм Абитов та, ашлык сатып алырлык акча эшләү нияте белән, Баку шәһәренә киткән. Өйдә хатыны Мәргуб әби белән ике кызы, унбиш яшьлек Тайбә апа һәм әнием Тәнзилә кала. Алар, чәчүдән азрак артып калган көнбагыш орлыгын ашап, ачлы-туклы кыш чыга. Мәргуб әби балаларын саклап кыш үткәрә, әмма үзе тиф авыруыннан вафат була.

НЭП

1922 елда, НЭП (яңа икътисади сәясәт) нигезендә, авылларда яшәүче бар кешегә дә җир бирелә. Крестьяннар, шул бирелгән җирләрендә үзләре теләгәнчә иген чәчеп, җыелган уңышны сатып файдалана алган.

1922-1930 елларда илдә тормыш яңадан тернәкләнеп, халык берникадәр баеп

китә. 1925 елдан соң авылда унга якын хуҗалык ТОЗларга (товарищество по совместной обработки земли) берләшеп, яңа хуҗалык барлыкка килә. Шулар арасында Хөснулла Богдаловның уллары Хәсән, Хөсәен, Хияли, гаиләләре белән, «Фардзон» маркалы трактор сатып алганнар. Ибраһимовлар – Кәлим, Тәкиулла, Азам гаиләләре ашлык суктыра торган молотилка булдырган. Бавиевлар – Имать, Билял, Илач гаиләләре пар ат җигеп эшли торган чәчкеч алган, җирне пар атка җигелгән сабан белән дә сөрә башлаганнар. Сәүдә әйләнеше дә үсеп киткән: авылда кайбер гаиләләр кибет ачып, барлык кирәк-ярак, кием-салым, савыт-саба һәм хуҗалык әйберләрен сату-алу эше җайга салынган. Авылдагы байтак кына корылмалар төзекләндерелгән, яңа өйләр, хуҗалык биналары калкып чыккан. Уңай күренешләрнең нәтиҗәсе буларак, 1926-1930 елларда Вязовый Гайда яңа туган балалар саны 3-4 мәртәбә арткан.

ИСКЕ КУЛАТКЫ СОСТАВЫНА КЕРҮ

ВЦИКның (Всесоюзный Центральный Исполнительный Комитет) 1928 елның 14 маенда чыккан карары нигезендә, 9 округтан торган Средне-Волжская область оештырылган. Вязовый Гай авылы Хвалынск округына кертелгән булган. Районны оештыручылар, Вязовый Гай авылын милли район Иске Кулаткыга кушу өчен, Самарага делегацияләр җибәргән. Самара шәһәрендә кабул ителгән карарда, халык үз теләге белән керергә тиеш, диелгән.

Бу мәсьәлә буенча Вязовый Гай авылында даими рәвештә җыен оештыра башлаганнар. Кайберәүләр моңа каршы булган, чөнки алар 200 елдан артык сәүдә үзәге һәм су юлына да якын булган Хвалынск өязендә яшәп, гомер итеп, Иске Кулаткыга кушылырга теләмәгәннәр. Авылда өч-дүрт мәртәбә җыелыш үткәреп, җиде кешене делегат итеп сайлаганнар. Алар Иске Кулаткыга барып, район оештырыла торган конференциядә катнашалар һәм Вязовый Гай авылы халкы исеменнән районга керергә ризалык бирәләр. Шулай итеп, 1928 елның җәеннән Вязовый Гай авылы Иске Кулаткыга беркетелгән.

КОЛХОЗЛАШУ ЕЛЛАРЫ

Халыкны колхозга керергә агитация ярдәмендә чакырганнар. Эш барып чыкмагач, көчләп, иң эшчән гаиләләрне раскулачить итә башлаганнар. Вязовый Гайда башта ун гаиләне раскулачить итеп, өйләреннән куып чыгарганнар, аларның мал-туарларын, ашлык, кием-салымнарын тартып алып, элеккеге Мавия утарына күчергәннәр. Мавия байның утары – ике катлы пулат һәм йорты Совет, политсовет һәм башка идарә органнарының штабы булып саналган.

Раскулачиваниегә эләккән гаиләләрне, терлек ташый торган вагоннарга төяп, Казакъстан даласына илтеп ташлаганнар. Алар – Багдалов, Бариев, Ибраһимов, Шабаев, Асанов һәм башкаларның гаиләләре. Шулар арасында Алләм Идрис улы Алюшев гаиләсендә – хатыны, Тайбә алмай, 4 яшьлек Мөнир абый, 2 яшьлек Тәүхидә апа да булган. Андагы гаиләләр җир казып землянка ясап, түшәмен камыш белән ябып, талчыбык, өермә үлән, камыш һәм башка әйберләр ягып, казакъ даласында кышлаган.

Көче-байлыгы булган хәлле гаиләләр, раскулачить ителгәннәрне күреп, авылдан чыгып качкан, Ташкент, Баку, Әстерхан, Мурманск һәм башка төбәкләргә барып төпләнгән.

1933 елның кышында «Кызыл байрак» колхозы оештырылган. Аның идарәсе

дә Мавия байның пулатына урнаша. Шул утарда ук атлар калдасы да була. Раскулачиваниедән җыелган сабан, трактор, ашлык суктыргыч кебек кыр эшләрен башкару өчен эш кораллары, ашлык, кием-салым да шунда тупланган.

Бабамның ике улы – әтием, аның энесе Мәхмүт абый, Урта Азиягә китеп, Фирганәдә тимер юл төзелешендә эшләгән. Әнием, дүрт кызы, биш яшьлек Мигъдәт белән, колхозга кергән, ат-арба һәм сабанны да колхозга илтеп тапшырган.

Авылдан китәргә хәлләре булмаган гаиләләр колхозга язылган. Беркөнне Совет рәисе белән политкомиссар Мөхәммәтҗан Моракаев янына килеп (ул абзыйның кушым исеме Мокай бабай иде): «Нәрсә, Мөхәммәтҗан, колхозга керәсеңме, языйкмы?» – дип сораган. Мокай бабай әйткән: «Как хош колхоз!» – дигән. Бу колхозга керүдән башка юл калмавын аңлаткан. Каршы төшкән очракта Казакъстан даласына куылачагың көн кебек ачык. Языгыз, дигән дә йөгәнен алып, атын колхоз калдасына җибәргән.

Колхозлар оешу аерым хуҗалыкларны шактый бөлдергән. 1933 елның 22 августында әниемне, колхоз кырында арыш урган чакта хәле начарлангач, арбага салып авылга китерәләр – абыем Мидхәт туа. Әнием сөйләвенчә, өйдә бер умач пешерерлек тә он булмаган. Берничә көннән соң әтиемнән 10 кадак он посылкасы килгән. 5 яшьлек Мигъдәт абый, әниемә, баласын имезү өчен, бабайлардан көн саен бер шешә сөт алып кайткан.

Озак та үтми, әтием белән Мәхмүт абый да авылга кайтып колхозга языла. Әкренләп авылда тормыш җайлана, байтак гаиләләр кире кайта, хуҗалары ташлап киткән өйләрдә яңадан тормыш кайный башлый.

1932-1933 елларда раскулачить итүдән җыелган байлыкның шактый өлешен түрә-кара, сатып, акчасына сыйланып, юкка чыгарган. Авылга яңадан кайткан кешеләр, берләшеп, комсыз түрәләрнең халыкны мәсхәрәләгәнен исбатлап, район җитәкчеләренә гариза яза. Район күләмендәге бер җыелышта Вязовый Гай түрәләренә кисәтү ясала һәм тикшерү өчен ревизия комиссиясе җибәреләчәге турында хәбәр ителә.

Әйткәнемчә, авыл советы политкомиссары, колхоз идарәсе – барчасы да Мавия байның ике катлы пулатына урнашып, исәп-хисап кәгазьләре, документлар да шунда тупланган була. 1934 елның бер кичендә каравылчы Мөҗип бабай, пулатны җылыту нияте белән, сарайга утын ярырга чыга. Шулчак авыл түрәләренең берсе пулатка кереп керосин сибә һәм ут төртә, нәтиҗәдә, Мавиянең ике катлы мәһабәт бинасы янып юкка чыга. Бернинди гөнаһы булмаган Мөҗип бабайны ун елга төрмәгә ябалар, ә түрә-кара, ревизиядән качып, акланып кала.

Авылдагы халык колхоз тормышына ияләшеп, берегеп, күмәк көч булып яши башлый. Ә 1932-1934 елларда мал-мөлкәте булган гаиләләрне талаган түрәләр, халыкның нәфрәтеннән куркып, авылны ташлап кача. Бабамның сөйләвенә караганда, 1937 ел авыл халкы өчен аеруча уңышлы килгән. Ашлык күп булганлыктан, барлык келәт-амбарлар, раскулачиваниедән калган өйләр ашлык белән тулгач, Курмыш урамының мәчетенә дә ташыйлар. Вязовый Гай авылында оешкан «Большевик» һәм «Калинин» колхозында эшләүче тырыш гаиләләр яңа өйләр төзегән, ел саен диярлек 30-35 бала дөньяга аваз салган. Халык, үзара аңлашып, күмәкләшеп хезмәт иткән, өметле киләчәккә ышанып яшәгән. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

НЫРСЫ ИЗГЕЛӘРЕ

Рамилә Нотфуллина

КАБЕР ТАШЫ – ЧАЛ ТАРИХ

Теләче районындагы Олы Нырсы, Кече Нырсы һәм Бичер авылларының борынгы тарихы янәшәдәге «Изгеләр» зираты белән бәйле. **Казан Архиепископы Григорий** кушуы буенча, 1848 елда миссионер, көнчыгышны өйрәнүче галим **Н.И.Ильминский** Казан губернасының татар авыллары буенча сәяхәткә чыга, мөселманнарның яшәү рәвешен, динен тикшерә. Бу төбәктәге кабер ташларын да тарихта беренче булып ул исәпкә ала, *«Татарские надписи из времен Казанского царства в Лаишевском уезде»* исемле мәкаләсендә Нырсуар елгасы буендагы каенлыкта зур булмаган зират булуын һәм аның болгар чорына туры килүен дә яза.

XIX гасыр ахырында археолог **С.М.Шпилевский** Казан төбәгендә йөздән артык

кабер ташын исәпкә ала, шуларның 18ен урысчага тәрҗемә итә. 1877 елда галим археологларның IV съездында *«Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии»* исемле китабын тәкъдим итә. Анда Бичер һәм Нырсы авылларындагы зират тарих фәнендә беренче мәртәбә «Зөлката» исеме белән атала.

Һарун Йосыпов – Нырсы кабер ташларын беренчеләрдән булып тәфсилләп өйрәнгән мөхтәрәм шәхес. Эпиграфист галим «Введение в Булгаро-татарскую эпиграфику» исемле 1960 елда басылып чыккан китабында «Зөлката» зиратының дүрт кабер ташын тасвирлый, аларның фоторәсемнәрен, гарәби язуда укылышын һәм урыс теленә тәрҗемәсен тәкъдим итә. Шуннан чыгып, без зиратта 1950 елларга кадәр сакланып калган иң борынгы таш **1357 елның июль-август** айларында бакый дөньяга күчкән *«**Сөләйман улы Шәех** зираты»*на куелганын беләбез. Ташның өске өлешенә борынгы орнамент – сигез таҗлы чәчәк ясалган. Икенче ташка: *«...тарих сикиз (йөз) икедә мөбарәк мөхәррәм (аеның) ун алтынчы көн ирдеким **Ибраһим углы Исхак** утыз алты яшендә ирдеким фани дөньядин бакый...»* – дип язылган. Һ.Юсупов мәрхүмнең хәзерге ел исәбе белән **1399 елның 19 сентябрендә** вафат булганлыгын әйтә. Өченче таштан: *«...сикиз йөз кырык йитедә сәфәр аеның горрәсендә ирди **Йосыф ибне Шәех** дарелфәнадин дарелбәкая рихләт кыйлды...»* – диган юлларны укыйбыз. Миляди ел исәбе белән **1443 елның июнь аенда** вафат булган мәрхүмнең кабер ташы өстенә алтыпочмаклы Давыт йолдызы рәсеме төшерелгән. Дүртенче ташка: *«...тарих сикиз йөз йитмиш йитедә рәҗәб ае әүвәлендә ирде шинбә көн ирде **Мөхәммәд углы Әйүб** дарелфәнадин дарелбәкага рихләт кыйлды. Хак Тәгалә рәхмәт кыйлгай иншалла...»* – дип уелган. Бу датаны милади ел исәбенә күчерсәк, кабер иясенең **1472 елның 6 декабрендә** бакый дөньяга күчкәнлеге аңлашыла. Эпиграфик ядкәрнең монысы да борынгы символ – алтыпочмаклы Давыт йолдызы белән бизәлгән.

Археолог, тарих фәннәре докторы **К.А.Руденко**, каберлекләр борынгы һәм бай авыл урынында урнашкан, дип фаразлый. 2001 елда ул, ТР Милли музееның археологик экспедициясе җитәкчесе буларак, бу якларда тикшерү эшләре алып бара һәм бер әңгәмәсендә: *«Безнең тикшеренүләребез «Зөлката» зиратының элеккеге авыл урыны белән бәйләнешле булуын күрсәтә. Ул XI-XII гасырларга карый, ягъни Нырсы янындагы зират барлыкка килгәнче, якынча моннан 200 ел элек үк монда авыл булган, бәлки күпмедер дәрәҗәдә ул Казан шәһәренең тарихы белән дә бәйледер. Ни өчен, дигәндә, Казан һәм Иске Казан шәһәрләренең дә барлыкка килү вакыты шушы чорга туры килә. Масштаб ягыннан караганда, XII гасырда бу авыл яхшы гына үсешкә ирешеп, мөгаен, төбәктә иң зурысы булгандыр, чөнки табигате гаять гүзәл, урыны уңайлы, якында гына чишмәләр челтерәп ага. Дөрес, биредә археологик казу эшләре зур мәйданда алып барылмады, шунлыктан без аерым табышларга нигезләнеп кенә фикер йөртә алабыз. Әмма, билгесез сәбәпләр аркасында, бер мәлдә әлеге авыл җир йөзеннән юкка чыга. Биредә яшәгән халык бәлки башка урыннарга күчеп киткәндер яки коточкыч куркыныч авыруга бирешкәнме, әллә инде яу килеп, янгын чыгып, көлгә әйләндерелгәнме? Әлегә билгесез»*, – дип сөйли.

Алтын Урдада тәхет өчен барган сугышлардан килеп туган ыгы-зыгыдан файдаланып, 1359-1398 елларда урысларның Болгарга ун мәртәбә һөҗүм итүе билгеле. Болгарларның бу дәвердә төп дошманы «ушкуйник» дип аталган Новгород башкисәрләре һәм Мәскәү кенәзләре булган. «Изгеләр» зиратына җирләнгән мәрхүмнәр бәлки шушы сугышларда катнашып шәһид киткән баһадирлардыр.

Халыкның әлеге урынны бик хөрмәтләве игътибарга лаек. Олы һәм Кече Ныр-

сы, Бичер авылларында яшәүчеләрнең гасырдан-гасырга «Зөлката», «Нырсы суы», «Бичерхан» дип аталган бәет-риваятьләрне хәтердә саклавы, изгеләрне зурлавы, зиратта бүгенгә кадәр борынгыдан килгән йолаларны башкаруы уңай күренеш. Борынгылар, зиратның чикләрен билгеләү өчен канау казып, балчыкны эчке якка атып, үр салган. Заманында бер метр чамасы биеклектә булган үр зиратны малтуар керүдән дә саклау өчен кирәк булган, вакыт үтү белән ул кечерәйгән. Зиратка керү уңайлы булсын өчен, кечкенә капка эшләнгән булган. Зур арба белән керү мөмкинлеге дә бар – моның өчен киң һәм биек капка ясалган. Хәзерге вакытта «Изгеләр» зираты куе урманны хәтерләтә. Биредә агачлар шаулап утыра, көртлек, урман тавыгы, ябалак, тукран, урман чыпчыгы, сандугач, саескан, козгын, каргалар да бу тыныч урынны бик ярата. Кызганыч, зираттагы каберләрнең күбесе җир белән тигезләнгән, урыны билгесез, 1950 нче елларда Һ.Йосыпов тасвирлаган дүрт ташның бүген икесе генә сакланган.

2014 елда «Шәһри Казан» газетасында: *«Олы Нырсының изгеләр зиратында сакланучы ике борынгы каберне һәм аларның ташбилгеләрен безгә дә барып күрергә туры килде»*, – дип яза мөхтәрәм галимнәребез **Азат Зыятдинов һәм Марсель Әхмәтҗанов**. Алар1443 елда вафат булган Йосыф ибне Шәех һәм 1472 елда бакый дөньяга күчкән Мөхәммәд углы Әйүб кабере өстендәге ташлар белән таныша. Галимнәр фикеренчә, зират эчендә тимер киртә белән уратып алынган ташлар бер нәсел кешеләренә куелган, мәрхүмнәрнең исеме Казан ханы Сәхибгәрәй тарафыннан 1523 елның 3 гыйнварында тарханлык ярлыгы бирелгән затларның исеме белән туры килә, әлеге нәселнең исә тарханлык катлавына кертелгәне күренә. Мәкаләдә алар: «Туктамыш хан шулардан *(Кырым татарларыннан –* **Ред.***)* Кара бәк җитәкчелегендәге бер төркемне 1382 нче елларда, Болгар Олысын ушкуйниклардан яклар-саклар өчен, Урта Иделгә күчерә. Олы Нырсы авылына килеп төпләнгән татар нәселенең башы – чама белән 1382 елда Габдулла хан кул астында Кырымнан килгән тархан», – дигән фикерне җиткерәләр. «Изгеләр» зиратындагы кабер ташларының затлы булуы күзгә күренеп тора. Аңлашыла ки, зәвык белән эшләнгән мондый ташлар хаким, төрле мирза-бәкләргә һәм дин башлыкларына гына куелган.

ЗӨЛХИ АТА ЭЗЛӘРЕ…

Теләче районының Олы Нырсы һәм Бичер авыллары арасында урнашкан борынгы мөселман зираты «Зөлката» исемен йөртә. **Зөлката – Зөлхи ата, Зөлмөхәммәт** исемле тарихи шәхес XVII гасырда яшәгән. **«Зөлкә ата»**, **«Чүлкә ата»** дип тә йөртелгән кешенең Тәтеш-Буа тирәләрендә яшәгән **Багдан Чеменеев** исемле морзаның улы булуы билгеле. Галим М.Әхмәтҗанов «Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы» исемле хезмәтендә 1602-1603 елларда Багдан Чеменеев исемле йомышлы татарның урыс чыганакларына теркәлгәнен әйтә. Аның җирләре хәзерге Балык Бистәсе районы Тәберде Чаллысы авылыннан ерак булмаган «Большой» (бәлки Олы Нырсы) дигән урынны биләгән. Географик картаны карасак, Олы Нырсының Тәберде Чаллысы авылыннан ерак урнашмавы күренә. Бәлки Нырсы җирендә Зөлмөхәммәтнең нәсел җепләре саклангандыр, ата-анасы да биредә күмелгәндер? Кайбер риваятьләргә караганда, «Изгеләр зираты»нда Зөлмөхәммәтнең өч кызы ята. Олы Нырсы, Кече Нырсы һәм Бичер авылларындагы әби-бабалар Зөлхи ата кызлары **Сәгыйдәбану, Шәһидәбану, Заһидәбану**ларга багышлап бүген дә дога кыла.

Имеш, Олы Нырсыга ул вакытта зур яу килә. Авыл халкына ярдәмгә гаиләсе белән Зөлхи ата килеп төшә. Кайбер риваятьләрдә, Зөлката Бохара шәһәреннән кил-

1443 елда вафат булган Йосыф ибне Шәех каберенә куелган таш

гән, дип бәян итәлә. Дошманнар көтмәгәндә таң атканда авылга басып керәләр һәм көчле бәрелеш башлана. Зөлхи атанын өч кызы иртәнге намаз укыган вакытта бер кылычтан үткәрелә. Бу хәлгә ярсыган ата, авыл һәм тирә-якта яшәүче ир-атларны җыеп, зур көрәшкә күтәрелә. Сугыш канлы һәм аяусыз була, Нырсуар елгасы кан булып ага. Шәһид киткәннәрне бик зурлап «Изгеләр зираты»на күмүләре турында сөйли иде Олы Нырсы авылында туып-үскән әбием Сәлимә Гыйльметдинова.

Зөлхи ата әлеге вакыйгадан соң моннан күчеп китәргә карар кыла. XVII гасырның икенче яртысында йомышлы татарлар Кама елгасының сул як ярларына аяк баса һәм әүвәлге Нугай Урдасы биләгән мәйданны үзләштерергә керешә. Зөлмөхәммәт үзе хәзерге Әлки районындагы Яңа Чаллы авылына нигез сала, биредә аның кабере бар. Башкортстанда табылган Юрматы шәҗәрәсендә «Чүлкә ата» кабере янына Шыголе бине җирләүләре дә искәртелә. *«Аларның Зәй, Чишмә, Идел елгалары буйларында, Биләр шәһәре тирәләрендә күчеп йөргәндә «Чүлкә ата» кабере янында туктаулары хакында хәбәр сакланган. Шунысы кызык: Яңа Чаллы авылына нигез салучылар арасында Алатырь Камкасыннан килгән кенәз Юнәли Мостафин да була. Идрис хафизның да шушы нәсел кешесе булуы бик мөмкин»*, – ди галим М.Әхмәтҗанов.

Идрис хафиз Зөлмөхәммәт улы – атаклы суфи, күрәзәче, дин белгече, халык



1357 елда вафат булган Сөләйман улы Шәех каберенә куелган таш. Һ.Йосыпов фотосы

медицинасы нигезендә дәвалаучы. Аны авыл кешеләре Хәлфә бабай дип тә йөрткән. Риваятьләрдә Бичер халкының Хәлфә бабайны еш очратуы турында әйтелә. Ул бертуган апа-сеңелләре каберен зиярәт кылырга килгәндә, Бичер мулласы белән күрешми китми. Бередә исә Идрис хафизга «Шәкерт бабай» дип эндәшкәннәр, халык аның килгәнен көтеп алган. «Шәкерт бабай» үзе дә дәваланырга килүчеләрне алдан ук сизә торган булган, аларны: «Хәзер ерактан кеше килә, самавырны куйыйк», – дип каршы алган. Миссионер Мещеряков та Мәшләк төбәгендә Идрис Зөлмөхәммәткә дәваланырга килгән халыкның меңәрләгән метр чиратка тезелүен күреп гаҗәпкә кала. Ул хәзерге Балык Бистәсе районының Тәберде Чаллысы авылында яшәгән, Бичердәге мулла йортында сырхауларны кабул иткән.

Бередәге саф, сихәтле чишмәләр суының шифасы күпләргә мәгълүм. «Изгеләр зираты» янәшәсендәге өч чишмәнең суы белән халык бүген дә күз, колак, тән авыруларыннан сихәтләнә. Күрәсең, Идрис хафиз авыруларны чишмә суы, җиләк-җимеш һәм Коръән сүзе белән дәвалаган. Сихәтләнүләре турында исә беркемгә дә әйтергә кушмаган, чөнки бу чорда патша хөкүмәте татар халкын төрле юллар белән көчләп чукындыру сәясәтен алып барган. Ә Идрис хафиз шул чорда атаклы суфиларның берсе булган.

Зөлмөхәммәтнең тагын бер улы булуы билгеле. Ризаэддин Фәхреддин үзенең «Асар» дип аталган мәшһүр библиографик хезмәтендә **Касыйм бине Ибраһим эл-Казаный (Касыйм шәех)** турында яза һәм аның Яңа Чаллы авылында яшәүче **Юныс бине Зөлмөхәммәт**нең бер мөриде булуы турында әйтә. Шуннан чыгып, без Юныс Зөлмөхәммәт улының да танылган суфи, күпләрнең рухи остазы икәнлеге турында әйтә алабыз. Зөлмөхәммәт, аның уллары Идрис һәм Юныс – шул чорның атаклы суфи шәехләре булып, халык аларны газиз, изгеләр дәрәҗәсенә күтәргән.

ИЗГЕ ЧИШМӘЛӘР

«Изгеләр зираты» янәшәсендә җир куеныннан, үләннәр, ташлар арасыннан юл ярып, өч чишмә ага. Аларны җирле халык изге чишмәләр дип атый. Халык җир астыннан ургып аккан саф суны, шул су кебек үк чиста, нурлы дөньяның, изгеләргә генә ачык булган галәмнең, оҗмахның бер өлеше, дип кабул итә. Чишмәләрнең изгелегенә ишарә булган тагын бер фал – «Изгеләр зираты»на якын булуы. Аларның берсеннән – тән авыруларыннан, икенчесеннән – күз, өченчесеннән колакка шифалы су чыга. Бу суларның дәвалау куәте риваять кенә түгел. Ни гаҗәп, бердәй көчле басым белән, бер үк катламнан ургып чыккан әлеге чишмәләрнең су составы да сизелерлек аерыла, әлеге үзенчәлек тәмдә үк сизелә.

Әүвәлге заманнан бер гадәт калган: нindidер авыр каза, сынауга дучар булган кеше, шуны уңышлы кичү хакына, хәер-садака бирү белән беррәттән, «Изге чишмә»гә килә һәм бу урындагы корылмаларны яңарта, чишмәләрне чистарта, кечкенә инеш аша салынган басманы рәтли, бәдрәфне төзекләндерә яки шуларны эшләрмен, дип адарына. Су ияләренә хәер йөзеннән чишмәгә бакыр, көмеш акча салу гадәте дә бар. Язмыш сынавына дучар булган кешеләр шушы изге чыганактан яклау, юаныч, сихәт таба. Садака итеп элеп калдырган яулык, сөлге, чүмеч, чынаяклар – авырлыктан соң җиңеллек, куаныч кичергән кешеләрнең рәхмәте, баш июе... Шунда барган кайбер кешеләргә чишмә буенда нindidер серле чаткылар да күренгәли, диләр. Су иясеме, әллә шушындагы изгеләрме? Әмма алар яхшы кешеләргә генә күренә, начар күңеллеләр аны белми-сизми, дип сөйли халык.

1920-1930 еллар зилзиләсендә мәчетләрнең манарасы киселеп, дин, иман белән бәйле күп нәрсә инкарь ителгән чорда да хаҗ гыйбадәтен үтәүдән мәхрүм калган аксакаллар, шушы изге урынга килеп, күңелләрен пакьләгән, яшьләрне хак юлга өндәгән... Замана ничек кенә булса да, хәтер, күңел аклыгы, иман ныклыгы чишмәләрнең саф, пакь суы белән буыннан-буынга күчә килгән.

Әби-бабаларыбыз электән үк бу җирдә «изгеләр ашы» уздыра. Әлеге йола хәтта сугыш вакытында да тукталмый. Мал юк чагында тавык булса да суйганнар, еллар иминләшкәч, Коръән укып, Аллаһы Тәгаләдән саулык-сәламәтлек сорап, тынычлык теләп, сарык чалганнар. Бу көнне зиратта авылның барча кешесе җыела торган булган. Әби-бабаларыбыз сөйләвенә караганда, зират янында алты фляга аш әзерләнгән. Калган ашны, әрәм итмичә, авылдагы кешеләргә таратканнар. Сарык тиресен сатып, садака итеп мәчеткә тапшыру, тавык йонын күмеп калдыру гадәте булган. Бирегә килгән халык шушы чишмә суында пешкән һәм учак төтене исе килеп торган ризыктан авыз итәргә ашыккан. Монда узган минутларны һәр кеше бик озак сагынып искә ала. Дус-ишләренә күргәннәрне иң күңелле, хикмәтле вакыйга итеп сөйли. Бер тапкыр бу ризыклардан авыз иткән кешеләр бирегә икенче елда да әйләнеп килгән. Хәзерге заманда да авыл халкы, әлеге йолага тугры калып, «изгеләр ашы»н ел саен уздырырга тырыша.

ХАЛЫККА ФАЙДАСЫ ТИЯР КЕШЕ – ИЗГЕ КЕШЕ *(хәдис)*

«Изге чишмә» һәм зиратны карап, төзекләндереп торучы кеше булган. Узган гасырның 60-70 нче елларында Башкортстанның Уфа шәһәреннән Теләче районының Олы Нырсы авылына **Нурмөхәммәт Маннанов** кайтып урнаша. Лаеклы ялга чыккан Нурмөхәммәт бабай (җирле халык үз итеп аңа шулай эндәшә) килгәндә, коммунизм төзергә ашкынып йөргән халык изгеләр турында, әлбәттә, уйламый, «Зөлката» зиратында тәртипсезлек, агачлар ауган, үтеп керә алмаслык чытырманлык, су аркылы чыгарга басмалар начар була. Бабай язгы ташу вакытында суга төшкән пычрак, агач ботаклары, ләм һәм вак ташлардан чишмәләрне чистарта, «Изгеләр зираты» эче картаеп ауган агачлардан арындырыла. Нурмөхәммәт бабай берүзе, беркемнән дә ярдәм сорамыйча, зират тирәли баганалар утыртып, койма тота. Кешеләр биргән хәер-садака акчасына ул буяу сатып ала һәм зиратның киртәләрен буяп чыга. Нырсы урманыннан үсентеләр алып төшеп, зират эченә рәт-рәт итеп агач утырта. Бу агачлар бүген дә җеп белән сузып утыртылган кебек. Ни гаҗәп, үзенә игътибар иткән өчен рәхмәт белдергәндәй, зират көннән-көн матурлана, кошлар сайрый, кыр үрдәкләре очып килә. Авыл халкы Нурмөхәммәт бабайга тирән рәхмәтен белдерә.

Дөрестән дә, тәрбияле, тыныч холыклы, дини белемле бу бабай: «Әйдәгез, бала-

лар, шифасы булсын, әйдәгез! Болай итеп карыйк әле. Аллаһының кодрәте киң», – дип, ярдәм сорап килгән авыруларны өшкерә торган була. «Изгеләр чишмәсе»нең көмештәй чиста суы белән авыру кешеләрнең күз, колакларын сыпырып һәм тәннәрен юдыртып, Аллаһтан аларга тәүфыйк, бәхет, сәламәтлек сорый. Аннан соң, авыруны зиратка алып менеп, җиде тапкыр әйләндерә. Зират янында Нурмөхәммәт бабай кечкенә генә йорт та төзеп куя. Гыйбадәт кылу өчен җыйнак кына, бик чиста һәм тыныч урын була ул.

Нурмөхәммәт Маннанов чыгышы белән Балык Бистәсе районының Югары Тегермәнлек авылыннан. 1 кыз һәм 4 ир бала тәрбияләп үстерә. Хәзерге вакытта балалары Мәскәү, Уфа шәһәрләрендә һәм Төркиядә яши. Әтисенең диндар булуы, Коръән сүрәләрен яттан белүе турында улы **Рәшид Маннанов** та искә ала. *«Коръән сүрәләрен укып кына калмыйча, аның мәгънәсен дә белүен һәм башкаларга да шуның асылын җиткерергә омтылганын хәтерлим. Уфада яшәгәндә, дини бәйрәмнәрдә әти еш кына мулла кебек өстәл түрендә дога укый иде. Бәйрәмгә килгән кунакларга, туганнарга шул догаларның мәгънәсен аңлата. Аннан соң, бергә-бергә тәмле ризык ашап, тәм-томнар белән күңелле итеп чәй эчә идек»*, – дип, күңел түрендәге хатирәләрне барлый ул.

Нурмөхәммәт абый яшь чагында мәдрәсәдә белем алган. Бу гыйлем аңа гомер буе гарәби китапларны укырга мөмкинлек биргән. *«1962-1963 нче елларда без, пароходка утырып, гаиләбез белән Балык Бистәсенә кайттык. Әти авыр тимер чардуганны иң өстенә салып кайтты. Олы Нырсы зиратындагы каберлекләрне әйләндереп алу өчен иде алар. Хәзер аларның күпме булуын төгәл генә әйтә дә алмыйм, әмма коймаларның 30-40тан да ким секциясе булмагандыр. Гаиләбез өчен бу бик зур чыгым торса да, әнкәй әтигә карышмас иде»*, – дип сөйли Рәшид ага. Нурмөхәммәт абыйның олы улы Мәлик тә, әтисенең Нырсы зираты белән 1960 еллар башында ук кызыксынуы турында әйтә. Биредәге «Изгеләр зираты»нда сугыш корбаннары – борынгы бабаларыбыз җирләнүе хакында, әлеге урынның хөрмәткә лаек булуы турында Нурмөхәммәт абый, әлбәттә, яхшы белгән.

Олы һәм Кече Нырсы, күрше Бичер авыллары халкы Нурмөхәммәт бабайны үз иткән. Гомере буе Нырсы ипиханәсендә эшләгән **Әлфия апа Гәрәева**ның сөйләвенә караганда, Нурмөхәммәт бабайның яшәгән йорты бик чиста, төзек һәм пөхтә булган. *«Авылга кайтып төшүгә, ул, һәр көнне эшкә барган сыман, «Изгеләр зираты»на юл тота иде. Зират тирәләрен чистартты, яшелләндерде, чишмәләрен тернәкләндерде. Бар көч-кодрәтен, мөмкинлеген изгеләргә багышлады. Әле күптән түгел генә «Изгеләр зираты»на машина белән барып кайттык. Нурмөхәммәт абыйның зират янәшәсендә салган өен төзек, чиста күреп сөендек. Шәһәр өе кебек матур ул... Анда кыйммәтле намазлыклар, затлы тәсбих, йомшак мендәрчекләр бар, хәтта утырып торырга уңайлы бүкәннәр дә куелган... Без – абыстайлар бүген дә «Изгеләр зираты»н тәрбияләгән, чишмәләрен караган Нурмөхәммәт абый рухына дога кылабыз»*, – дип сөйли Әлфия апа.

Нурмөхәммәт абый үзе турында беркайчан да сөйләмәгән. Аның тормышында авыр вакыйга булган, шуннан котылу максатыннан адарынып, үзен шушы изге зиратка багышлаган, дигән фикер генә бар. Нурмөхәммәт бабайның рухи ныклыгына сокланып, кешеләр аны да изге дип таный. Бабай 1988 елда вафат булгач, «Изгеләр зираты»на күмик, дигән фикер дә әйтелә, әмма, васыяте буенча, туган авылында җирләнә. «Зөлката» зираты авыл советы карамагында кала.

Нурмөхәммәт Маннановның кылган изгелеге юкка чыкмый. Чишмә янына килгән һәркем, суга гына түгел, зиратка, кабер ташларына, шаулап утырган агачларга карап, мөхтәрәм татар картын да искә ала... ■

Ленин хөкүмәтенең мөселманнарга мөрәҗәгате һәм госманлы матбугаты

Надир Дәүләт

Большевикларның мөселманнарга мөрәҗәгате Төркиядә иң элек «Вакыт» газетасының 1918 елгы 2 гыйнвар санында дөнья күрә. 14 гыйнварда ул «Танин», 15 гыйнварда «Ати» газеталарында, бу юлы Гаяз Исхакый тарафыннан Мәскәүдә чыгарылган «Ил» газетасының 9 гыйнвар саныннан алынып, кабат бастырыла.

«Иптәшләр! Туганнар!

Россиядә бөек вакыйгалар дәвам итә. Канлы сугышның азагы якыная. Дөнья халыкларын коллыкка төшергән ерткычларның хакимлеге җимерелә. Рус инкыйлабы һөҗүме астында золым һәм коллыкның иске бинасы какшый һәм чатный. Изү һәм башбаштаклык дөньясы соңгы көннәрен яши. Яңа дөнья – эшчәннәр һәм иреккә чыгучылар дөньясы туа. Бу инкыйлабның башында Русия эшчеләр һәм крәстияннәр хөкүмәте – Халык Комиссарлары Советы тора. Бөтен Русиядә эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советы саны күбәйгәннән-күбәя. Илдәге хакимият халык кулында. Русиянең эше халкының бер генә теләге – шәрәфле солыхка ирешү һәм дөньяның изелгән халыкларына ирек яулауда ярдәм итү теләге бар.

Русия бу изге эшендә ялгыз түгел. Рус инкыйлабының бөек азатлык шигарен һәм Көнбатыш, һәм Көнчыгыш хезмәт ияләре күтәреп чыга. Көнбатышның эшчеләре һәм

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

солдатлары социализм байрагы астында тупланып, империализм ныгытмаларын штурмлауны дәвам иттерәләр. Аурупаның «мәгърифәтле» ерткычлары тарафыннан гасырлар буена изелгән Һиндстан шулай ук баш күтәреп, депутатлар Шуралары оештырып, үзен каһәрле коллыктан азат итә, Көнчыгышның башка халыкларын көрәшкә һәм азатлыкка чакыра.

Без бу бөек вакыйгалар алдында сезгә – Русиянең һәм Көнчыгышның мөселман хезмәт ияләренә мөрәҗәгать итәбез.

Надир Дәүләт

Русия мөселманнары, Идел һәм Кырым татарлары, Себер һәм Төркестан кыргызлары (казакълар) һәм сартлары (үзбәкләр), Кавказ арты төрек татарлары (азәриләр), Кавказның чеченнары һәм таулылары! Сезнең мәчетләрегез һәм гыйбадәтханәләрегез Русия патшалары тарафыннан җимерелгән, динегез һәм гореф-гадәтләрегез мыскыл ителгән.

Моннан соң динегез һәм гореф-гадәтләрегез, милли һәм мәдәни оешмаларыгыз ирекле һәм кагылгысыз дип игълан ителә. Милли тормышыгызны ирекле һәм киртәсез шартларда җайлагыз. Сезнең моңа тулы хакыгыз бар. Белегез ки, Русиянең бөтен халыкларының хокуклары кебек үк, сезнең хокукларыгыз да инкыйлабның бөтен көчекуәте һәм Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советлары тарафыннан яклана.

Көнчыгыш мөселманнары, фарсылар һәм төрекләр, гарәпләр һәм индуслар! Аурупаның комсыз ерткычлары сезнең башларыгыз һәм милекләрегез, азатлыгыгыз һәм ватаныгыз белән гасырлар буена сату иткәннәр, илләрегезне бүләргә теләгәннәр.

Ачыктан-ачык белдерәбез ки, тәхеттән төшерелгән патша кул куйган һәм куылган Керенский раслаган Истанбулны басып алу турындагы яшерен килешүләр, ертылып, чүплеккә ташланды. Русия җөмһүрияте һәм аның хөкүмәте булган Халык Комиссарлары Советы чит илләрне яулап алуга каршы. Истанбул мөселманнар кулында калырга тиеш.

Без белдерәбез ки, Иранны бүлү турындагы килешү, ертылып, чүплеккә ташланды. Хәрби хәрәкәтләр бетүгә, гаскәрләр Ираннан чыгарылачак, Иран халкына исә үз язмышын үзе билгеләү хокукы тәэмин ителәчәк.

Без Төркияне бүлү турындагы килешүнең ертылып читкә атылуын игълан итәбез. Төркиядән көнчыгыш вилаятьләрне аеруны күздә тоткан яшерен шартнамә дә юк ителде...

Илләрегезне басып алган ерткычларны куып җибәрегез. Бөтен дөнья илбасар империалистларга каршы нәфрәт ялкыны белән яна, хәтта һинд мөселманнары да яулап алучыларга каршы баш күтәрә. Бу шартларда дәшми калу мөмкин түгел. Вакытны әрәм итмичә, илләрегезне басып алган оккупантларны җилкәгездән алып ташлагыз! Үз илегезгә үзегез хуҗа булыгыз! Сезнең моңа хакыгыз бар, чөнки язмышыгыз үз кулларыгызга тапшырылган...

Русия мөселманнары! Көнчыгыш мөселманнары! Дөньяны яңарту юлында сездән теләктәшлек һәм яклау көтәбез.

Халык Комиссарлары Советы рәисе
В.Ульянов (Ленин)
Милли эшләр буенча халык комиссары
Джугашвили-Сталин
«Вакыт», 1918, 2 гыйнвар».

Бу мөрәҗәгать төрек газета укучыларына ни дәрәҗәдә тәэсир иткәндер – аны-сын белмибез. Әмма Русиядәге төрки мөселманнарга, хосусан, яшь зыялыларга мөрәҗәгатьнең йогынты ясавы шиксез. Патша хөкүмәте һәм аның дәвамчылары милли азчылыкларга һичбер яхшылык кылмаган хәлдә, большевистик хакимият шактый нәрсәләр вәгъдә иткән. Төрек матбугатында мөрәҗәгатькә карата һәм уңай, һәм тискәре караучылар да була. Мәсәлән, Җәләл Нури «Ати» газетасында (1918, 15 гыйнвар) болай яза: *«Социализмга да, әһле исламга да дошман күзе белән караган Аурупа империалистлары, колониалистлары, капиталистлары иде... Социализм, ислам галәменә булсын яки турыдан-туры безгә булсын, ярдәм күрсәтә...»*

Ләкин большевикларның мөселманнарны да җәбер-золымга дучар итүе турындагы хәбәрләр килә башлагач, большевиклар мөрәҗәгатенә каршы язулар да күренә башлый. «Вакыт» газетасының 1918 елгы 20 февраль санында түбәндәге хәбәр чыга: *«Большевикларның Милли эшләр буенча халык комиссары (Сталин) мөселман эшләре буенча бюро төзегәч, күренекле мөселманнарның бик күбесе анда катнашу тәкъдимен кабул итмәгән, шуңа күрә [бу яңа органга] хәрәмләшүе белән танылган Ехан Галичев (Солтангалиев) исемле кырым татары куелган».*

Бу хәбәрдә Солтангалиевкә хәрәмләшүче сыйфаты бирелүе бер яктан тенденциоз булса, икенче яктан ул Русия мөселманнарының киләчәгенә карата шикләнүне белдерә. Солтангалиев кырымлы түгел, казан татары иде. Ул елларга хас буталчыклык шартларында мондый хаталар ясалуы табигый. Биредә без: «Мондый гына кимчелек мулла кызында да була ул», – дип әйтү белән чикләнеп калабыз.

1918 елның азагына кадәр төрек матбугатында Русия белән бәйле хәбәрләр яки мәкаләләр әллә ни күп чыкмаган, чөнки ул вакытта Госманлы дәүләтенең үз проблемалары да шактый булган. Әлбәттә, Русия, Төркиягә дошман булганлыктан, кызыксынусыз калмый, тик андагы эчке вакыйгалар турындагы мәгълүмат фәкать чит ил матбугатыннан гына алына. Дөрес, төрек матбугаты ул яктан хәзерге вакытта да әллә ни үзгәрмәгән, ләкин, мәгълүмат технологияләренең ифрат алга китүе сәбәпле, без дөньядагы хәлләр хакындагы хәбәрләрне чит ил хәбәр агентлыкларыннан минуты-секунды белән ала алабыз. Шулай да телевидениебез каналлары һәм газеталарыбыз чит илләрдә бик аз корреспондентлар тоталар: алар бармак белән санарлык кына. Бары мөһим бер вакыйга чыкканда гына конкрет урынга хәбәрче җибәрелә. Ул очракта да хәбәрче, барган илне юньләп белмәгәнлектән, җибәргән хәбәре дә өтегрәк була. Боларны исәпкә алсак, 93 ел элек төрек матбугатында Русиягә кагылган хәбәрләрнең аз чыгуы гаҗәпләнерлек түгел.

Госманлы матбугатында большевизм куркынычы турында беренче язучылардан Зыя Гөкалпны күрсәтергә кирәк. «Йени меҗмуа» исемле журналның 1918 елгы 21 март санында ул «Ике куркыныч» атлы мәкалә бастыра. Гөкалп болай дип яза: *«Инглизләр пропагандасы аркасында куерган «кара куркыныч» илне реакционерларга тапшырачак, Русиядән киләчәк «кызыл куркыныч» исә «кара»сыннан да ким булмаячак».* Әхмәт Җәүдәт тә «кызыл куркыныч» турында Гөкалпның карашын уртаклаша. 28 мартта шул ук журналда Зыя Гөкалпның ярдәмчесе Нәҗметдин Садыйк (Садак) «Большевистик куркыныч» исемле мәкаләсен бастыра. Бу язмада Русиядәге вакыйгалар сөземтә рәвешендә бирелә. Автор Русиянең инкыйлаб дулкыны узган урыннарында һичбер офицер калмау, Кара диңгез флоты матрослар карамагында булу, язучыларның, укытучыларның, гомумән, уйлый-фикерли белгән бөтен кешеләрнең башлары киселү, чират байларга җитү, университет һәм мәктәпләрнең ябылуы, өйләр һәм гыйбадәтханәләрнең талануы турында яза.

Зыя Гөкалп 1918 елның 4 апрелендә чыккан «Йени меҗмуа» битләрендә гәрчә:

«Әйе, бүген Русиядәге кардәшләребезнең әбәди суръттә бәйсезлек алу заманыдыр», – дип язса да, «Төрек Йорты» журналының 15 май санындагы «Иреккә чыгу көннәрендә кардәшләр әңгәмәсе» исеме куелган мәкаләдә: «Без мәгънәви берлек корыйк, телләрне берләштерик, сәяси берлекне башкалар уйласын», – дигән фикерне алга сөрә.

Мәсьәләгә мондый караш Төркиядә 93 елдан соң да үз көчен югалтмый. Бер төркем төрки кавемнәрнең 1991 ел ахырында мөстәкыйльлеккә тиенеп, бәйсез дәүләтләр төзүеннән соң хәтта «телләрне берләштерү» идеясенең дә хыялдан башка нәрсә түгеллеге аңлашылды. Хәер, дөнья төркиләрен сәяси яктан берләштерү, яңа чикләр билгеләү, моның өчен кирәкле инфраструктура әзерләү темасы һич югы нәзари (теоретик) рәвештә булса да каралмады һәм кәгазьгә дә төшерелмәде. Ихтимал, 1918 елда, ягъни төрки халыклар әле уртак әлифба кулланган заманда уртак әдәби тел булдыру җиңелрәк булгандыр. Тик хәзерге вакытта, гәрчә «төрки телле дәүләтләр һәм халыклар» гыйбарәсе еш кабатланса да, әлеге идеяне гамәлгә ашыру һич мөмкин түгел, чөнки аның реаль җирлеге юк.

1918 елның маенда Истанбул матбугатында күренеп алган Русия турындагы чикле микъдардагы хәбәрләрнең зур өлеше андагы мөселманнар тормышына бәйле була. «Сабах»ның 23 май санында Бакуда мөселманнар белән большевиклар арасындагы бәрелештә 3 меңнән артык кеше һәлак булганлыгы һәм Төркестанда бер совет җөмһүрияте игълан ителгәнлеге хәбәр ителгән. 21 июньдә «Ати» газетасы, алман чыганакларына нигезләнеп, Русиядә мөселманнар белән руслар арасында килеп чыккан каршылыкта 159 мең (!) кеше үтерелде, дип язып чыккан.

1918 елның 4 июлендә исә «Сәбилеррәшад» журналында Русиянең күренекле мөселманнарыннан Муса Җаруллаһ (Бигиев) хаты урнаштырыла. Хатта Русия мөселманнарының киләчәге кара төсләргә буялып бирелә. Шул ук журналда 18 июльдә Гаяз Исхакыйның хаты да нәшер ителә. Автор, большевик юлбашчылары үз милли, мәдәни һәм дини хокукларын саклап калырга теләгән мөселманнарны реакционерлар һәм инкыйлаб дошманнары итеп күрәләр, мондый шартларда бердәнбер өмет большевистик режимны җимерүгә кайтып кала, дип яза. «Сәбилеррәшад»ның шул ук санында күренекле татар дин галиме һәм иҗтимагый эшлеклесе Габдерәшит Ибраһимов язган мәкалә дә урын ала. Ибраһимовның мәсьәләгә карашы Исхакыйныкына караганда уңайрак, оптимистиграк күренә: аның фикеренчә, мөселманнар, элек ясаган хаталарыннан арынган тәкъдирдә, уңышка ирешәчәкләр, чөнки рус инкыйлабы әле тәгалләнеп җитмәгән.

Ахыр чиктә, өч авторның юраулары да юш чыга. Большевизм җимерелмәгәнгә күрә Русия төркиләре көткән үзгәрешләр чынга ашмый, алар арасындагы бердәмлеккә дә ирешелми кала.

Брест-Литовскида шартнамә имзаланганнан соң, 1918 елның 2 августында «Сабах» газетасында чыгышы Русиядән булган социалист Зиннәтулла Нуширәван «Большевиклар һәм Брест-Литовск шартнамәсе» дигән мәкаләсендә: «Милләтләр үз язмышларын үзләре билгеләү хакына ия, большевикларның башкаларны да көчләп большевиклаштырырга тырышуы ачыктан-ачык золым», – дип язып чыга. Тик бу мәкалә авторы, бераз соңра фикерен үзгәртеп, Төркия Коммунистлар партиясенә керә.

Большевиклар белән мөселманнарның мәнфәгатьләре бер-берсенә капма-каршы килүләре хакындагы тәүге турыдан-туры хәбәр 14 августта «Вакыт» газетасында басыла. Нури паша армиясе сафларында Көнчыгыш фронтында төрек җирләрен азат итү операциясендә катнашкан Әхмәт Агаев (Агаоглу) бу хәбәрдә большевикларның

сугыш барган төбәктә яшәүче халыкка начар мөгамәлә күрсәтүен тасвирлый. Шул ук көнне башка газеталарда: «Большевиклар җиңелде һәм Бакы алынды», – дигән сөенечле хәбәрләр бирелә.

Җәләл Нури кебек мөселманнарга эсерлар белән хезмәттәшлек итәргә киңәш биргән яки Әшрәф Әдип кебек большевиклар белән уртак эшләр башкарырга тәкъдим иткән төрек авторлары белән Русиядә яшәп, вакыйгаларның турыдан-туры шаһитлары булган Муса Бигиев һәм Гаяз Исхакыйлар арасында, әлбәттә, җитди фикер аермалыгы бар иде.

1918 елда большевизмга каршы чыккан төрек журналистлары һәм зыялылары, 1919 ел урталарында азатлык сугышы башлангач һәм большевиклардан ярдәм килү ихтималы күренгәч, элекке фикерләреннән баш тарталар. Төрек матбугатында без, шулай ук, Мондрос атышуны туктату килешүеннән соң инглиз һәм француз хәрби кораблары бугазлардан үтеп, Кара диңгезгә чыктылар һәм ак гвардия генераллары Деникинга, Колчакка, Юденичка ярдәм китерделәр («Ати», 1918, 15 ноябрь), 25 ноябрьдә яңадан 16 сугыш корабы Кара диңгезгә керде («Хадисат», «Сабах», 1918, 25 ноябрь), дигән хәбәрләр очратабыз.

1918 елның 1 ноябреннән башлап төрек хөкүмәте матбугатта цензура режимы кертә. Яңа таләпләр буенча Антанта дәүләтләренең хәрби хәрәкәтләрен яктырту тыела. Шуның өчен Истанбул газеталары Әрзерум, Сивас корылтайлары, Төркия Бөек Милләт мәҗлесенең ачылуы кебек хәбәрләрне дә бирми. Ул заманда газеталардан башка хәбәр чыганагы булмау сәбәпле, цензура шартларында халыкны агымдагы вакыйгалардан хәбәрдар итү мөмкинлеге калмый. Хәзерге заманда да хөкүмәтләр теге яки бу рәвештә матбугатта цензура элементларын кертә ала. Мәсәлән, алар кайбер Интернет сайтларын, блогларны яптыралар, газета хуҗаларын өркетеп куялар.

Шулай да 1918-1919 елларда, кайбер очракта цензура рөхсәте белән, башка очракта цензурадан качу нәтиҗәсендә, газеталарда кызыклы гына хәбәрләр басыла барган. Мисал өчен, «Сабах» газетасының 17 декабрь санында 15 һәм 25 ноябрьдә Истанбул бухтасыннан чыккан Антанта флотының Одесса портында ләңгәр (якорь) салуы, 5 мең француз солдатының шәһәргә керүе, акгвардиячеләр белән берләшеп большевикларга каршы сугышуы һәм 10 декабрьдә Одессаны алуы турында хәбәрләр урын ала.

1919 елның беренче өч аенда төрек матбугатында атна саен диярлек Алманиядәге радикаль социалистлар һәм инкыйлабчылар хәрәкәтенә караган хәбәрләр чыгып тора. Бу хакта бигрәк тә «Вакыт», «Икъдам», «Истикъләл», «Хокукы бәшәр» һәм «Галәмдар» газеталарында языла. Шул ук 1919 елда Истанбул газеталарында Русиядәге эчке сугышка, икътисади вазгыятькә һәм югары дәрәҗәдәге большевиклар арасындагы каршылыкларга караган мәгълүматлар шактый еш күренә. «Истикъләл» газетасы үзенең 1919 елгы 9 гыйнвар санында басылган «Русия Ленин идарәсе астында» исемле язманы Һолландиянең Петроградтагы илчесенең чыгышына таянып әзерли. Мәкаләдә иҗтимагый сыйныфларның торышы, ачлык һәм михнәт турында языла.

«Галәмдар» газетасының 1919 ел, 24 июль, 24, 28 һәм 29 октябрь саннарында большевикларның хәрби уңышсызлыгын, акгвардиячеләрнең исә уңышларын тасвирлаган антибольшевистик хәбәрләр урын ала. 7 ноябрьдә «Төрек Йорты» журналында большевикларның инкыйлаб судлары хакында хәбәр басыла. «Йенигүн»дә исә (16 ноябрь саны) Дәүләт Думасының элекке әгъзасы, Рус социалистик партияләр берлеге рәисе Григорий Алексинский белән әңгәмә урнаштырыла. Бу

әңгәмәне төрек журналистикасының шактый ук зур уңышы дип бәяләргә мөмкин.

1920 елда Госманлы дәүләте тулысынча Антанта дәүләтләре контроле астына керә, Русиядә эчке сугыш ялкыны әле сүнми. Бу вакытта госманлы матбугаты Русия эчендәге вакыйгаларны яктыртуга аз урын бирә, ләкин, икенче яктан, Төркиянең милли көчләренә булышлык иткән большевиклар хөкүмәте белән кызыксынуын яшерми. Польша белән Русия арасындагы сугыш турында да хәбәрләр бирелеп тора.

Шуннан соңгы айларда төрек газеталарында большевиклар ирешкән уңышлар турында хәбәрләр бөтенләй диярлек күренми, чөнки Антанта дәүләтләре урнаштырган цензура режимы тагын да катылана. Ниһаять, 1920 елның 6 апрелендә Анадолуда (Анатолиядә) «Анадолу агентлыгы» исемле мәгълүмат оешмасы төзелә, шулай итеп, Антантага каршы көрәшүче төрек көчләре үз мәгълүмат органына ия булалар. Билгеле ки, бу агентлык дөньяның һәр төбәгенә хәбәрчеләрен юллый алмый, бюджеты да мактанырлык булмый, әмма ул еллардагы юклык һәм сугыш шартларын игътибарга алганда, аның әһәмиятенең зурлыгы тагын да аңлашыла төшә.

«Анадолу агентлыгы»ннан тыш, «Ачык сүз» һәм «Анадолуда йени гүн» газеталары чыга башлый. Мәсәлән, «Ачык сүз»нең 1920 елгы 6 март санында, «Debat» исемле француз газетасыннан алынып, «Анадолуда милли хәрәкәт һәм большевиклар» дигән материал урнаштырыла. Анда большевиклар белән милли азатлык өчен көрәшүчеләр арасында хезмәттәшлек ихтималы турында языла.

«Анадолуда йени гүн» газетасының беренче саны 1920 елның 9 августында Әхмәт Әмин (Йалман) редакторлыгында Әнкарада дөнья күрә. 18 августта газетада «Үзәк Аурупада большевиклар хәрәкәте ничек үсә» исемле хәбәрдә большевикларның уңышлары бәян ителә. «Йени гүн»дә моныңише материаллар август буе басылып килә. Шундыйлардан, күренекле большевик, Кызыл Армияне оештыручы Троцкийның 1920 елның 1-8 сентябрендә Бакуда үткәрелгән Беренче Шәрекъ халыклары корылтаенда нотык сөйләве, нотыгын тәмамлагач, бик каты алкышлануы турындагысы дикъкатькә лаек. 5 октябрьдә «Хакимияте миллийә» газетасы «Большевик сәфарәте» дигән язмада Әнкарада Совет илчелеге ачылу хәбәрен бирә.

Истанбул матбугатында һаман әле большевикларның проблемалары һәм уңышсызлыклары турында язылса да, аларның җиңүенә «җанлы» дәлилләр булып, Истанбулга килә башлаган рус мөһаҗирләре хакындагы хәбәрләргә дә урын бирелә башлый. «Икъдам» газетасының 1920 ел, 19 ноябрь санындагы бер язмада «рус мөһаҗирләре белән тулган 35 пароход Истанбул бухтасында тора, тагын 11 мең мөһаҗир килер дип көтелә», дип языла. Шул ук газетада Якуп Кадри (Караосманоглу) «70 мең мөһаҗир»нең киләчәген белдерә. «Пәяме сабах»та «рус мөһаҗирләре агылып килә. Кичә бухтабызга 10 меңе килеп җитте»,дигән хәбәр басыла. Ун көн узганның соңында «Вакыт» газетасы «100 меңнән артык рус күчкене [Кырымдагы акгвардияче гаскәрнең яубашчысы генерал] Врангель «рубльләре» белән килделәр», дигән яңалыкны белдерә.

1920 елның 23 апрелендә Әнкарада Төркия Бөек милләт мәҗлесе ачыла, Госманлы хөкүмәте вәкилләре исә 10 августта Севр килешүенә кул куялар. Үзгәчә әйткәндә, төрек сәясәтчеләре ике лагерьга бүленә: бер якта Севр килешүе шартларын танымаган Мостафа Кәмал җитәкчелегендәге халык булса, икенчесенә дошман басып алган Тракия төбәгендә яшәп, Истанбул хөкүмәтенә буйсынган төрекләр эләгә.

1918 елның 13 ноябрендә басып алынган Истанбул бары тик 5 ел диярлек

Садри Максуди

вакыт үткәч, 1923 елның 6 октябрендә генә азат ителә. Измир һәм аның тирә-юне исә 1919 елның 15 маенда оккупацияләнә һәм 3 елдан соң, 1922 елның 9 сентябрендә ирек ала.

1921 елда Совет хөкүмәте эчке сугыштан җиңүче булып чыга һәм Төркия җөмһүрияте белән рәсми мөнәсәбәтләр төзүгә керешә. Шул вакытта Мәскәү ярдәм күрсәткән Төркия Коммунистлары фиркасе һәм аның юлбашчысы Мостафа Сөбхи Истанбулда да, Анадолуда да үзләренә тарафдарлар эзләп табарга тырыша.

Әнкара хөкүмәте, большевиклар булышлыгына өмет итеп, 1921 елда Мәскәү белән мөнәсәбәтләрен шактый активлаштыра төшә. 28 июньдә «Анадолуда йени гүн»дә СССР илчесенең Әнкарада ышанычнамә (верительная грамота) тапшыруы турындагы хәбәр, Ленин һәм Мостафа Кәмал портретлары бирелеп, киң урын ала. Шул ук газетаның 11 июль санында Троцкийны кулга алу турында язылa. Тагын бер көннән соң аның битләрендә «Төркия белән Русия арасындагы кардәшлек һәм тынычлык шартнамәсе» Бөек милләт мәҗлесендә тавыш күпчелеге һәм алкышлар белән кабул ителде», дигән хәбәр басыла.

Истанбул газеталарыннан «Вакыт»та 30 августта русларның Инеболу һәм Самсун бухталарына 30 очкыч, 250 йөк аты, туплар, снарядлар, телефоннар һәм башка кирәк-ярак китергәннәрен яза. Шулай итеп, ул большевикларның Анадолу гыйсъянчыларына ярдәм күрсәтүен фаш итә булып чыга.

«Анадолуда йени гүн» газетасының 14 һәм 21 декабрь саннарындагы «иптәш» Фрунзе Әнкарага килеп ТБММдә чыгыш ясады һәм тыңлаучылар тарафыннан бик каты алкышланды, дигән хәбәре аеруча игътибарга лаек. Күрәсең, ул вакытта әле большевикларның Анатолиядә идеологияләрен тарату һәм төрекләрне үзләренә тарафдар итү буенча эшчәнлеге Әнкара белән Мәскәү арасын бозып өлгермәгән була. Әнкара хөкүмәте Русиянең матди һәм хәрби ярдәменә мохтаҗ була, чөнки ансыз гына грек гаскәрен җиңү икеле күренә. Ләкин Мостафа Кәмал белән иптәшләренең большевизмга мөнәсәбәтләре һич тә уңай булмый. Алга таба Мостафа Сөбхи тирәсендәге вакыйгалар нәкъ шуны исбатлаячак әле.

Баштарак Истанбул журналистлары исламият белән коммунизм арасында уртак нокталар табарга тырыша, әмма күп тә үтми, мондый иҗтиһадтан баш тарта.

Хәзерге Башкортстан Республикасының башкаласы Уфада 1917 елда төзелгән «Эчке Русия һәм Себер мөселман төрки-татарлары Милләт мәҗлесе» рәисе Садри Максудиның Париждагы «Le Temps» газетасы журналисты белән әңгәмәсе 1921 елның 29 апрелендә басыла. Бу әңгәмә 4 майда «Вакыт» газетасында һәм «Сәбилеррәшад» журналының майда чыккан 481 санында төрек теленә тәрҗемә ителеп бирелә. Максуди анда, аерым алганда, болай ди: «*...мин мөселманнар большевикларны кабул итәрләр, дип уйламыйм... Моның, ягъни большевикларның*

мөселманнар тарафыннан сөелмәве дәлиле – аларның бөтен губерналарда да большевикларга каршы торулары, аларга баш имәүләре».

«Сәбилеррәшад»ның шул ук санында ТБММ депутаты Хуҗа Шүкрүнең «Мөселманлык белән коммунистлык бер-берсен алыштыра аламы?» дигән мәкаләсе басыла. Ул мондый сүзләр белән башлана: *«Юлдан чыгып, адашып йөрүче эшлексез сөрхәнтәй Мостафа Сөбхи һәм кулдашларының алдашуларына диндәшләребез ышанмасын иде! Шуның өчен коммунистлык белән исламият нигезләре турында язуны үзебезнең бурычыбыз дип беләбез».*

Икенче яктан, большевиклар хөкүмәте белән Төркия хөкүмәте арасында җылы мөнәсәбәтләр урнаша. Төркиягә Советлардан шактый ук микъдарда корал, төрле хәрби җиһазлар һәм матди ярдәм килә. 1920 елның мартында башланган ярдәм акцияләренең өченчесе башкарылу нәтиҗәсендә 8 сентябрьдә Трабзон портына алты әрҗә корал, 9 сентябрьдә 1 миллион алтын тәңкә һәм 17 сентябрьдә 1,5 миллион алтын тәңкә китерелә.

Ул арада Мостафа Сөбхи иптәшләре белән Карс шәһәре аша Төркиягә килә, шул сәбәпле, Төркия Бөек милләт мәҗлесендә коммунизм мәсьәләсе буенча яшерен утырыш оештырыла. Төркия Коммунистлар фиркасе һәм яшел армия турында шик- шөбһәләр арта, 1921 елның 27 гыйнварында коммунистлар кулга алына, алар арасында Зиннәтулла Нуширәван да була. Коммунистларның басма органы «Әмәк» газетасы яптырыла. Әнкара хөкүмәтенең эчке эшләр министры урынбасары Аднан Бәй Әрзерум вәлиенә (губернаторына) коммунизмга ничек караулары турында сорап телеграмма җибәргәч, вәли: «Мостафа Сөбхи куылды. Төркия Коммунистлары партиясе таркала башлаганына күрә, коткычылыкның сәбәбе юкка чыкты. Тыныч булыгыз!» –. дип, аңа җавап юллый. Бөтен бу вакыйгалар Әнкара хөкүмәтенең Советлар белән хезмәттәшлек кылырга мәҗбүр булуын, ләкин коммунистик идеологиянең Төркиядә җәелүенә каршы чыгуын күрсәтә иде.

1921 елның февралендә Төркиянең Мәскәүдәге беренче илчесе Али Фуат паша һәм Мәскәүнең Төркиядәге тәүге илчесе Буду Мдивани вазыйфаларын башкара башлый. Шул ук айда Мәскәүдә 1920 елның 24 августында расланган шартнамә нигезендә рәсми сөйләшүләр башлана. 1921 елның 16 мартында Төркия белән СССР арасында дуслык һәм ярдәм килешүе имзалана. Әнкара хөкүмәте өчен бу зур бер уңыш була, чөнки Азәрбәйҗан белән Грузия кебек совет химаясендәге хөкүмәтләрдән башка яңа Төрек хөкүмәтен таныган һәм аңа булышлык иткән бүтән зур мәмләкәт булмый. Антанта дәүләтләре патша Русиясен кабат торгызырга теләсәләр дә, уңышка ирешә алмыйлар. Коммунистик идеологияне үзенә сеңдергән Яңа Төрек хөкүмәтенең Советларның көченә таянуы, аның белән якынлашу сәясәте Көнбатыш илләрен тирән уйга калдыра.

1921 елның апрелендә Инеболу һәм Гиресун бухталарына корал төялгән совет кораблары килә. Мондый ярдәм күрсәтү төрле юллар белән дәвам итә. Апрель аеның ахырында Төрек хөкүмәте вәкиле Йосыф Кәмал бәйгә Мәскәүдә 4 миллион алтын тәңкә бирелә.

Башка илләрдән ярдәм алу мөмкинлеге булмаган Әнкара хөкүмәте өчен Мәскәүнең бу булышлыгы гаять әһәмиятле була. Мәскәүнең позициясенә килгәндә исә, ул, ярдәм күрсәтүне дәвам иттереп, Төркиянең совет режимын кабул кылуына исәп тота. Икенче тарафтан Төркиянең көнбатыш илләренә каршы булуын яхшы белеп, аны үзенең берлектәше (союзнигы) итеп саный.

Төрекчәдән ***Рәшид Кадыйров*** тәрҗемәсе. ■

ИСЕМЕҢ ҺӘМ ҖИСЕМЕҢ

(XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ИСЕМНӘРЕ ТЕЗМӘСЕНӘ БЕР КҮЗӘТҮ)

Әлфинә Сибгатуллина

Әле генә өйләнешкән мөселман рухлы татар гаиләләрендә туган балаларга бүген ислами исемнәр кушу күренеше популярлашып бара. Яшьләр, бик яратып, совет чорында «онытылган» яки «искергән» дип саналган Исмәгыйль, Йосыф, Ибраһим, Гомәр, Госман, Камил-Камилә, Мәлик-Мәликә, Гадел-Гадилә, Гөлзәйнәб, Гөлмәрьям, хәтта Ризаэддин, Җамаледдин кебек исемнәрне җәмгыятебезгә «кире кайтара» башлады һәм, ни гаҗәп, моңа бу гаиләләрнең шәһәрләрдә урыслар белән ут-күрше булып яшәве дә инде «комачау» итми. Хәер, урыс яшьләре арасында да балаларга Марк, Лука, Матвей, Софья кебек «иске» христиан исемнәрен бирү үзенә күрә бер модага әйләнеп бара.


ф-223-41

وعظ نامه رساله سی

ایرونلرگه هم خاتونلارغه اسم برلهن بیان ایدلگانلر

ناشرلری : برادران کریموفلر

کریموفلر مطبعه سی قزانده .

۱۹۰۹

КАЗАНЬ

типографія т. д. „Бр. Каримовы“

1909

Әлеге күренешләр турында уйланулар XX гасыр башында басылып чыккан бер чыганакны киң әйләнешкә кертеп җибәрү теләген уятты. 1909 елда Казанда бертуган Кәримовлар матбагасында чыккан «Вәгазьнамә рисаләсе»[1] исемле бу китапның төп өлешен татарча «исемлек», ягъни ул заманда татарлар арасында киң кулланышта булган исемнәр тезмәсе тәшкил итә. Әсәрнең шигъри формада, җиңел рифма белән язылуы аның «вәгазьчел» эчтәлеген, дидактик рухын кабул итүдә укучыга шактый кулайлыклар тудыра. Аноним автор, үзенең тел гыйлеме өлкәсендәге тәҗрибәсе белән беррәттән, матур гына поэтик табышларын да күрсәтә белә, гомумән, авторның теле һәм язу өслүбе Габделҗәббар Кандалыйныкы кадәр җор, үткен, кыю, урыны-урыны белән хәтта бераз «усал» һәм тупас, урыны-урыны белән «эротик» та дияргә була. Автор, рухани әһеленнән үк булмаса да, дин кануннарын үтәргә чакыруы, мөселман этикасы, җәннәт-оҗмах темаларына кагылуы белән беррәттән, милли гадәтләребезне, халкыбызның шул чор тормыш-көнкүреш шартларын чагылдыруы белән дә Кандалыйны хәтерләтә.

Рисаләдә татарлар арасында шул заманда иң еш кушыла торган ике йөз егермедән артык ир-ат һәм бер йөздән артык хатын-кыз исеме бирелгән. Һәрбер исемгә бер яки ике юл (бәет) аерылып, күпчелек очракта, бу исемне йөртүче кешегә мөрәҗәгать итеп,

[1] Вәгазьнамә рисаләсе. Ирәнләргә һәм хатынларга исем берлән бәян иделгәндер. Нашире: борадарән Кәримевләр. Кәримевләр матбагасы. – Казан, 1909.

берәр төрле нәсыйхәт бирелә, шәригать кануннарын үтәп яшәргә чакырыла, тик еш кына бу акыл бирү юнәлешендәге юлларны укыганда, һич көтелмәгән «борылышлары», пассажлары белән автор укучысын елмаеп куярга яки милли мәдәният тарихына караган белемнәрен искә төшереп, уйланырга да мәҗбүр итә. Кайбер бәетләрдә автор үзенең ислам тарихын яхшы белүен һәм гарәп-фарсы лингвистикасы, этимология фәннәреннән дә хәбәрдар булуын шундый оста рәвештә күрсәтә ки, аның яхшы гына бер мәдрәсә бетергәнлегенә шик-шөбһә калмый. Әйтик, түбәндәге юлларда:

«Биктаһир, син тәһарәтсез йөрмәгел,
Гыйбадәттән башканы күб белмәгел», –

дип, автор Бик+таһир исемендәге таһир белән тәһарәтнең бер үк «чисталык» мәгънәсендәге *thр* тамырыннан килүенә басым ясый.

Яки Хәмидуллаһ (Хәмид+Аллаһ) исеме белән «мактау» мәгънәсендә *хәмд* сүзенең «бертуганлыгын» матур гына беркетеп куя:

*«**Хәмидуллаһ**, **хәмед** иткел Аллаһа,*
Җиһат ит үзеңне юлга салмага».

Киләсе юлларда исә язучының сүз уйнату сәләте, җорлыгы ачык күренә:

*«**Низамеддин**, бел шәригать низамын (кагыйдәсен),*
Сату кыйлсаң, тугры булсын мизаның (үлчәвең)».

Автор кеше исемнәрен «әлиф кафиясе», «би кафиясе», дип, баш хәрефләргә күрә гарәп әлифбасы тәртибендә биреп бара. Әгәр бу тәртипне сакламыйча, исемнәрнең төзелеше яки семантикасы, мәгънәләре буенча карасак, кызыклы гына төркемчәләр барлыкка килүен күрергә була. Әйтик, ир-ат исемнәре арасында иң күп очраган төр булып, **теофор**, ягъни Аллаһ исемнәре кергән вариантлар тора. Билгеле булганча, 1917 елга кадәр татар һәм башкортлар арасында *–улла(һ)* компоненты белән ясалган, бүгенге көндә безнең фамилияләребезгә «күчкән» исемнәр аеруча популяр булган:

*«**Хәйруллаһ**, син дәхи күб ятмагыл,*
Нәселеңнең яман атын сатмагыл.

***Рәхмәтуллаһ**, рәхәт улсын гүрләрең,*
Илля тотгыл Аллаһның әмерләрен.

***Гарифуллаһ**, гайбәт итмә кемсәне,*
Диндә бул гайрәтле, Хак сөяр сине.

***Төхфәтуллаһ**, тик ятарга син оял,*
Ахмак улма, олылардан гыйбрәт ал.

***Хәбибуллаһ**, хыянәт кыйлма, дустым,*
Ахирәтне уйла, куй дөнья эшен» һ.б.

Икенче бер теофор исем вариантын беренче компоненты *Габд-* белән ясалган Габде+ Рахман, Габде+Рәхим, Габде(л)+Җәббар кебек исемнәр тәшкил итә. Ул «Аллаһ колы» мәгънәсенә туры килүче «Габд» сүзенә «Әсма-и хөснә»дән, ягъни Аллаһының затын һәм сыйфатларын олылаучы 99 «матур исемнәре» («Исме әгъзам») җыелмасыннан алынган Рахман, Рәхим, Җәббар, Җәлил, Җәлал, Бакый, Вәли, Гали, Гани, Гафур һ.б. исемнәр ялганып ясалган:

*«**Габдерәхим**, һәр кешегә рәхим ит,*
Яхшылыгың әҗере сиңа була бит.

***Габделгафур**, дөнья-ахирәт булма хур,*
Хәрәм эшләп, гөнаһыңны кыйлма зур.

***Габделҗәббар**, җәй буе җомгага бар,*
Бәрәкаллаһ, яхшы эшләр бик ярар».

Монда авторның шигъри тоемлау сәләтен дәлилләүче тагын бер күренешне ассызыкларга кирәк: ул да булса, аллитерация дигән филологик термин белән белдерелүче, бертөрле тартык авазларның бер бәеттә еш бирелүе. Ул үзенә күрә поэтик бер осталык дип санала. Мәсәлән, бу юлларда *р,х,м* тартыклары кабатлана:

*«**Габдерахман**, раҗи кыйл Хак рә**хм**әтин,*
*Рә**х**әт ит**м**ә, чик гыйбадәт зә**хм**әтен».*

Ә биредә исә *г, җ* һәм б тартыкларының кабатлануы күренә: Габдел*җ*әббар, *җ*әй буе *җ*омгага бар ...

Гел *г, х* тартыкларыннан «гыжылдап-хышылдап» торган бу юллар да авторның телгә осталыгына бер мисал була ала:

*«**Бибигалимә**, гыйлем кыз, галим улсын хәләлең,*
Дөнья-ахирәт рәхәт улыр чөнки синең хәлләрең».

Гарәпчәдән кергән «Габд»нең татарча эквиваленты булган «кол» сүзе белән ясалган исемнәрне дә теофор исемнәр төркеменә кертеп карап була. Дөрес, бу китапка Колшәриф, Колмөхәммәд кебек *кол* компоненты беренче торган исемнәр кермәгән (димәк, XX гасырда бу исемнәр әллә ни популяр булмаган, дип фаразларга мөмкин), ләкин икенче компонент буларак, «Әсма-и хөснә» исемнәренә ялганып ясалган исемнәр юк түгел:

*«**Рахманкол**, һәм калма мәхрүм, кыйл намаз,*
Кумагыл дөньяны, гомрең калган аз.

***Рәхимкол**, сән комганың ал кулыңа,*
Куалаганны көтмә, бара тор юлыңа».

*Шул ук исемнәрне –**җан** компоненты белән дә яратып кулланган татарлар:*

*«**Рәхимҗан**, һәм җаһил улма, сүзеңне тот,*
Биш намазны укысаң, пешермәс ут».
(Пешермәс ут – җәһәннәм утында янмассың).

Монда шуны да әйтергә кирәк: *-кол, -җан* компонентлары белән ясалган исемнәр чиста төрки онимнар булып тора, гарәпләр һәм иранлылар арасында бу төр исемнәр очрамый. Шулай ук, *бик-*, *бай-*, *биби-* кебек саф төрки компонентлар белән ясалган *Биккол*, *Биктимер*, *Байтимер*, *Байморза*, *Бибигайшә*, *Бибиҗамал* һ.б. исемнәр дә халык арасында еш кулланылганын текстта күрми мөмкин түгел:

*«Тагы, **Тимербай**, базардан ал кашык,*
Һәм тәмугтан курык, намаз укырга ашык.

***Баймөхәммәд**, бар мәчеткә, кыйл намаз,*
Нәкас (пычрак) улыб яту бер дә ярамас.

Бибикамал, күркең артыр Аллаһка кыйлсаң тәгать,
Кадерен белсәң иреңнең, аерылма бер сәгать. һ.б.»

Рисаләдә язучы «илаһи» исемнәрнең икенче компоненты *–дин* булган очракларына да шактый күп үрнәк бирә:

*«**Җәлаледдин**, җыйма дөнья малыңны,*
Динеңне тот, уйла ахирәт хәлеңне.

__Җәмаледдин__, җаның улса, җиһат ит,
Җәннәт эстәсәң, Ходайга тәгать ит.

__Хәйреддин__, син хәбәрсез ятма күб,
Кәсебеңне туктатып, мәсҗедкә кит» һ.б.

«Вәгазьнамә рисаләсе»ндә, икенче зур бер исем төркемчәсе буларак, пәйгамбәр исемнәре килә. Пәйгамбәрләр тарихы – «Кыйссасел-әнбия» китабын яратып укыган татар халкы, исламгача яшәгән бик күп пәйгамбәрләрнең гыйбрәтле язмышын яхшы белә, шуңа күрә автор да, нигездә, бу кыйссаларга ишарәт итеп яза. Пәйгамбәрләргә хас төп сыйфатларның берсе – сабырлык, язмышыңа язылган авырлыкларга түзеп, инанычтан аерылмау. Атасы Ибраһим (г.с) пәйгамбәрнең аны Тәңрегә корбан итәргә теләвенә карышмаган улы Исмәгыйль (г.с.), абыйлары тарафыннан кол итеп сатылган Йосыф (г.с.), тәнендәге үлекле шешләрдән интеккән Әюб, зур балык тарафыннан йотылган Йуныс, Исхак, Идрис, Ильяс, Сөләйман, Муса, Дауд (г.с.) һәм башка пәйгамбәрләр...

Язучы, бу пәйгамбәр исемнәрен йөртүче гади мөселманнарга эндәшеп, исемнәренә лаек эшләр кылырга чакыра:

«Әй, __Исмәгыйль__, укы һәр дәмдә Коръән,
Башыңны кыйл Хода юлында корбан.

Әй, __Ибраһим__, сүземне дыңлагыл һәм,
Мөселман исәң, иманың булсын мәхкәм (хөкем итүче).

__Сөләйман__, син дәхи улмагыл яман,
Яхшы улсаң, һәр эшең булур тәмам.

Шушы ук төркем эчендә Мөхәммәд галәйһиссәламнең 99 исеме һәм сыйфатлары булган «Әсма-и нәбәви»гә кергән исемнәрне дә карарга була. Болар арасында иң билгеле булганнары – *Мостафа* һәм *Әхмәд*. Татарлар арасында Әхмәд компоненты кергән исемнәрнең аеруча күплеге күзгә ташлана: *Әхмәдвәли*, *Әхмәдгали*, *Әхмәди*, *Әхмәдсәгыйрь*, *Әхмәдҗан*, *Әхмәдша(һ)*, *Әхмәдуллаһ*, *Хаҗиәхмәд*, *Галиәхмәд* һ.б.

«Әй, __Әхмәдуллаһ__, хәмед иткел Ходага,
Савап иткел хезмәтең ата-анага.

Әй, __Әхмәтҗан__, тәнеңдә гәр булса җан,
Гамәл кыйлгыл, табарсың дөрре-мәрҗан».

Аерым бер төркем итеп, ислам динендәге изгеләрнең, тарихи шәхесләрнең, Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең хәлифәләрен, гаилә әһелләренең исемнәрен күрсәтергә кирәк:

«__Әбүбәкер__, башыңда булса фикер,
Мөселман улганыңа әйлә шөкер.

Гамәлгә бик җиһад кыйл дәһи,
__Госман__, гыйбадәтне кыйлырга Тәңре кушкан.

__Гомәр__ булсаң, озын булсын гомерең,
Гамәл кыйл, күп булыр атың, сыерың.

__Гали__ булсаң, гадәт кыйлгыл шул эшкә,
Гашыйклык тотмагыл алтын-көмешкә.

Хәсрәт йотмагыл һәр дәм син, ***Хәсән****,*
Намазың кыйл, һәр эшең булгай асан».

Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) гаиләсенең әһелләре булган Хәдичә, Фатыйма, Гайшә, Зәйнәб кебек хатын-кызларның исемнәре дини китапларда еш очрый, ди автор:

*«****Гайшә****, һәм синең исмең тулмыш иркән һәр китаб,*
Гәрчә ирең разый булса, дөнья-ахирәт йөзең ак.

Фатыйма*, һәм күб китапта синең атың укылыр,*
Иреңне үпсәң кочаклаб, урының оҗмахта булыр.

Хәдичә*, исмең ушандак һәр китапта язылыр,*
Ирне разый әйләгәннәр дөнья-ахирәт шат улыр».

Китапта гарәп теленнән кергән хатын-кыз исемнәре арасында «анасы» мәгънәсендәге *Өмме-* сүзе белән башланган исемнәр дә шактый гына китерелә:

*«****Өммегөлсем****, син матур кыз, тот Ходa әмерене,*
Татлы телләрең әйләнсен, разый кылгыл иреңне.

Өммекамал*, һәм галим кыз, кямил улсын эшләрең,*
Телә Хакдин бер галимне яхшы Кадер кичләрен» һ.б.

Төзелеше ягыннан кушма булган хатын-кыз исемнәре арасында-*җамал* (матур): *Әсхабҗамал, Хөсниҗамал, Гайниҗамал, Бәдигылҗамал, Хәбибҗамал, Сәхибҗамал, – камал* (камил) сүзе белән ясалган исемнәрне очратабыз: *Шәмсикамал, Гайникамал, Миңлекамал* һ.б:

*«****Бәдриҗәмал****, дәхи синең йөзләрең мисле кояш,*
Тор иреңнең каршысында мисле сайрар сандугач.

Гыйльмиҗәмал*, дәхи синең ике битең ай кебек,*
Кияүеңнең кочагында ары сары май кебек.

Шәфкыйҗәмал*, шатлык илән үтсен озын көннәрең,*
Гәрчә ярың булса шәкерт, кыска булыр төннәрең.

Гайникамал*, гомрең озын әйләсен Аллаһ синең,*
Сиңа шәкерт насыйб улсын, нәфис икәндер тәнең.

Миңнекамал*, кемнән ишеттең сөешү савап икәнен,*
Ул савап диндә олугдыр, бел, гыйбадәт икәнен» һ.б.

Икенче компоненты *-җан,- җиһан, -ниса, -бану* булган исемнәрнең дә татар хатын-кызларына еш куелганлыгы күренә:

*«****Хөсниҗан****, холкың гүзәлдер, дәхи күркәм йөзләрең,*
Ник сине сөймәсен ирең, татлы балдан сүзләрең.

Хәерниса*, хәйран улма, белгел ирнең хөрмәтен,*
Кыямәт көн сән ашарсың оҗмахының хөрмәсен.

Сәгъдәбану*, һәр сүзеңне әдәп илән сөйләгел,*
Ирдән рөхсәт алмаенча, дәхи коймак измәгел.

Азагы бар ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

МӨСЛИМ – ТАРИХИ ХӘТЕРЛЕ ТӨБӘК

Альберт Әхмәтҗан

Тарихчылар – ТР ФАнең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты археологлары, ТР Милли музее хезмәткәрләре белән берлектә һәм Мөслим район хакимияте, җирле музей хезмәткәрләре һәм районның төбәкне өйрәнүчеләре ярдәмендә, Мөслим төбәкне өйрәнү музеен реконструкцияләүдә һәм аның фондларын яңартуда катнашты. Музей тупланмасына күптән түгел төбәк археологиясенә һәм тарихына караган яңа материаллар керде.

***

Татарстанның Мөслим районында соңгы елларда төбәкнең социаль-икътисади үсеше өлкәсендә күп эшләр башкарылды. Җитештерү-хуҗалык, торак һәм мәдәни объектлар төзекләндерелә һәм яңалары да төзелә. Төбәк җитәкчелегенең һәм халкының бу казанышлары турында Мөслим һәм Көнчыгыш Татарстанның аңа чиктәш районнарына сәфәрләре вакытында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов та билгеләп үтә килде. Районгдагы әлеге үзгәрешләргә Мөслимдәге август киңәшмәсе вакытында республикабызның мәгариф системасы хезмәткәрләре дә игътибар итте.

Районда мәдәният, мәгариф һәм спортны үстерү өлкәсендә дә зур эшләр башкарыла. Мәктәпләр, клублар, спорт комплекслары, төбәкне өйрәнү музее, район мәдәният йорты, мемориаль комплекслар, һәйкәлләр, мәдәният парклары һ.б. объектлар төзекләндерелде һәм яңалары ачылып килә.

Район үзәгендә күптән түгел генә кабатланмас Җәмигъ мәчете ачылды. Район хакимияте башлыгы Рамил Хәмзә улы Муллин бу мөһим эшләрне башкару барышында Казанның, республикабызның һәм илебезнең төрле тармак галимнәрен, мәдәният һәм мәгариф хезмәткәрләрен җәлеп итә. Һәм әлеге эшләр тиз арада башкарылып, яхшы нәтиҗәләр бирә.

2014 елдан башлап, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре һәм төбәкне өйрәнүчеләр тәкъдиме белән, район төбәкне өйрәнү музее фондларын өйрәнү һәм саклау эшләре башланып китә һәм үткәрелә. 2015 елның җәендә беренче мәртәбә, ТР ФА Тарих институтының фәнни отряды (җитәкчесе – А.Борһанов) тарафыннан, киң күләмле тарихи-төбәкне өйрәнү тикшеренүләре үткәрелде. Аларның барышында элегрәк билгеле булган һәм яңа ачыкланган археологик, эпиграфик, архитектура һәм сәнәгать объектларының урнашу урыннарына төгәллек кертелде һәм хәзерге торышы ачыкланды, торак пунктлар һәм авыл мәктәпләрендәге музей почмаклары тупланмалары турында яңа мәгълүматлар җыелды.

Элеккеге һәм яңа алынган мәгълүматлар нигезендә, ТР Милли музее хезмәткәрләре һәм Тарих институты галим-археологлары ярдәме белән, 2015 елның августында Мөслим төбәкне өйрәнү музееның яңа бинасы ачылды. ТР хөкүмәте рәисе урынба-

ТР ФА Тарих институтының Татар-болгар цивилизациясе тарихы бүлеге мөдире Альберт Борһанов (сулда) һәм Мөслим муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рушат Җәүдәт улы Солтанов төбәкне өйрәнү музеенда. 2015 ел

сары – мәгариф һәм фән министры Энгель Нәвап улы Фәттахов әлеге тантана вакытында бу музейның республикабыздагы иң яхшы музейларның берсе булуын, районда яшәүчеләрнең аның белән горурланачагын һәм Мөслимнең мөһим брендына әйләнүен билгеләп үтте.

Районда 2017 елда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре төркеме – археографлар, фольклорчылар һәм эпиграфистлар эшләде. Алар районның тарихи яктан кабатланмас булуын һәм төбәкне өйрәнү музееның төбәктә яшәүчеләр тормышында мөһим роль уйнавын билгеләп үтте.

Музей тупланмасы 2016-2017 еллар аралыгында җирле төбәкне өйрәнүчеләр һәм Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының галим-археологлары тапшырган яңа экспонатлар белән даими рәвештә тулыланып килде.

Мөслим төбәкне өйрәнү музее директоры С.Я.Җаббарова фикеренчә, ТР ФА Тарих институтының Татар-болгар цивилизациясе тарихы бүлеге мөдире А.Борһанов, ТР Милли музее хезмәткәрләре һәм җирле төбәкне өйрәнүчеләр ярдәме белән, музей күпкә баерак һәм кызыклыракка әйләнде. Җирле һәм килгән туристларның саны артты. Безнең музей Мөслим районының горурлыгына һәм брендына әйләнде. Музейга аеруча зур ярдәмне район җитәкчелеге күрсәтә, дип белдерде ул.

Археология һәм табигать бүлеге бирегә килүчеләрдә аеруча зур кызыксыну уята. Музейда Этнография, Хәзерге заман тарихы (XX-XXI гасырлар) һәм сәнгать бүлекләре дә эшли. Музей коллекциясе, моннан тыш, җирле осталар агачтан, керамикадан, металлдан, шулай ук башка материаллардан ясаган үзенчәлекле эшләнмәләр исәбенә дә байый. Музейга төрле чараларга килгән кунаклар һәм катнашучылар гына түгел, мәктәп укучылары, районның төрле авылларында һәм Көнчыгыш Татарстанда яшәүчеләр дә еш килә.

Альберт Борһанов фикеренчә, 2013 елда Рамил Хәмзә улы Муллинның җитәкчелеккә килүе Татарстанның ерактагы авыл районында яшәүчеләрнең тормы-

шын кискен үзгәртте. Хәзер бередә тормыш кайный, күпләр инде бу актив тормыш рәвешенә ияләшә дә башлады. Монда күп кенә республикакүләм чаралар уздырыла, мәдәният өлкәсендә дә күп нәрсә үзгәрде. Мөслимнең төбәкне өйрәнү музее бу яктан караганда районның брендына әйләнде, шуңа күрә без район һәм музей коллективы белән бик теләп хезмәттәшлек итәбез, дип билгеләп үтте ул.

Мөслим районы борынгы мөһим цивилизация үзәкләренең берсе булып тора, әмма ул фәнни яктан аз өйрәнелгән. А.П.Шокуров, Е.П.Казаков, П.Н.Старостин һәм Р.С.Габяшовларның 1950-1970 нче елларда ук үткәрелгән тикшеренүләрен исәпкә алмаганда, киң күләмле эшләр алып барылмаган. «ТАССРның археологик карталары һәм А.А.Борһановның яңа материаллары» буенча, районда ерак үткәндәге (таш гасыр, бронза, иртә тимер дәвереннән алып урта гасыр азакларына кадәр) 60лап объект ачыкланды. Аларның күпчелеге Ык һәм аның кушылдыклары бассейнында урнашкан.

Борынгы торак урыннарының эзләре Рус Шуганы, Олы Чакмак, Мазино, Табын, Мәлләтамак, Тамьян һ.б.авыллар, шулай ук Көнчыгыш Татарстанның күрше районнарында билгеләп үтелде. Әмма Ык елгасы, юлын даими үзгәртеп торып, борынгы кешеләр яшәгән урыннарны, каберлекләрне һәм курганнарны, торак эзләрен һәм шәһәрлекләрне юып юкка чыгара бара...

Хуҗалык корылмаларын һәм торак төзегәндә, елгаларның ярларны юуы нәтиҗәсендә, җирле халык металлдан, керамикадан, сөяктән һәм таштан эшләнгән кабатланмас әйберләр таба. Аларның күбесе, сатылып, шәхси тупланмаларда кала, кайсылары хәтта республикабыздан читкә дә чыгарыла. Мөслимлеләр табылган әйберләрнең бер өлешен районның төбәкне өйрәнү музеена тапшыра һәм борынгы чорларны өйрәнүдә Татарстан галимнәре белән хезмәттәшлек итә. Шундый фидакарь һәм милләтпәрвәр шәхесләрнең берсен – авыл хуҗалыгы ветераны Развит Галиевне билгеләп үтәсем килә. Ул галимнәргә һәм музейга күп кенә уникаль әйберләр тапшырды. Аларның күбесе А.Борһанов кулы аша узды һәм җентекләп өйрәнеп эшкәрткәннән соң, ул әлеге ядкәрләрне музей фондына тапшырды. Музейга килүчеләр әле дә бу бәһасез табылдыкларны карап хозурлана. Мәсәлән, галим 2016-2017 еллар аралыгында төбәкне өйрәнү музеен Табын, Ташлыяр, Рус Шуганы, Керәш-Шуран, Салавыз Мухан, Тамьян, Иске Чакмак һ.б. авыллар янында табылган шундый 620дән артык экспонат белән баетты. Алар арасындагы аю тешеннән эшләнгән бөти, казылма акула тешләре, йомырка сыман формадагы керамик ядрә (аның эченә яндыргыч сыекча тутырылып, ату коралы буларак кулланылган) бирегә килүчеләрдә зур кызыксыну тудыра.

Табылдыкларның төп өлеше – төрле калку орнаментлар белән бизәлгән, әвәләп һәм станокларда ясалган савыт-саба ватыклары. Аларның күбесе бронза һәм иртә тимер дәверенә карый. Керамик савытларның кайберләре Идел Болгарстаны, Алтын Урда, Казан ханлыгы һәм Нугай Урдасы чорларына нисбәтле, арада XVII-XIX гасырларга караганнары да бар.

Табылдыклар арасында киемнең металл элементлары, бизәнү әйберләре һәм төсле металлдан эшләнмәләр дә шактый. Мәсәлән, бронзадан ясалган һәм б.э.га кадәр III-б.э.ның III гасырларына караган эполет сыман формадагы берничә бизәлгән прәшкә ачыкланды. Тагын күкрәккә тага торган һәм кыңгырау рәвешендәге бизәнү әйберләре, колаксалар һәм медальоннар да табылды. Асылташлардан, керамикадан, пыяладан, сөяктән, металлдан эшләнгән муенсалар да байтак.

Табылдыклар арасында ук очлары (X-XIV гасырлар), скиф төрендәге акинак (б.э.га кадәр VI-IV гасырлар), тимер балталар, сөңге очлары, гарпуннар, металл кискечләр, кадаклар, йозаклар һәм ачкычлар да очрый.

А.Борһановның фәнни төркеме соңгы елларда авыл зиратларында да булып, кабер

ташларын өйрәнде. Бу эштә җирле халык та зур ярдәм күрсәтте. Аяныч ки, тамгалы һәм язулы күп кенә кабер ташлары, табигать шартлары йогынтысында, ватыла яки җиргә иңә бара. Моннан тыш, патша һәм совет чорларында кабер ташларын бина нигезләренә дә салып калдырганнар. Мәсәлән, совет чорында Катмыш авылы янында терлекчелек комплексы корганда аларны төзелеш материалы сыйфатында файдаланалар. Биредә ватылмаган 9 таш ачыклана.Тугаш авылы янындагы ике зиратта уникаль ташлар сакланып калган. Ул зиратларның берсе шактый борынгы һәм анда төрбә һәм 4 борынгы кабер бар. Тойгелде авылының иске зиратында А.Борһанов тарафыннан 26 кабер ташы өйрәнелде. Алардан күп мәгълүмат алырга була. Мәсәлән, ул кеше кем булган, нәрсә белән шөгыльләнгән, туганнары кем һ.б.

Безнең мәгълүматлар буенча, Олы Чакмак авылы зиратында 17, Тамьянда – 12, Метрәйдә – 10, Тугашта 18 уникаль таш сакланып калган. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: кайбер зиратларда бик кызыклы нәсел каберләре бар. Тугаштагы һәм Олы Чакмактагылары фәнни яктан аерым кызыксыну тудыра.

Күп кенә зиратларда ташлар җиргә иңеп беткән яки иңә, киләчәктә моны булдырмаска иде. Аксакалларга зиратларны карау һәм төзекләндерү мәсьәләсендә яшьләр белән тиешле эш алып барып, аларга халкыбыз һәм илебез тарихына, мәдәниятенә зур өлеш керткән мәрхүм якташларыбыз – әби-бабаларыбыз хакында бәһасез бай мәгълүмат биргән кабер ташларын кадерләп сакларга кирәклеген аңлатырга кирәк. Зиратларның торышы – әби-бабаларыбызга мөнәсәбәт, авылның мәдәнилеге күрсәткече.

Күп районнарда, шул исәптән Мөслимдә дә кызыклы архитектура һәйкәлләре сакланып калган. Әмма шунысы аяныч, Олы Чакмак авылындагы мәдрәсә бинасы (1894 ел), Салавыз Мухандагы тарихи иске бина ташландык хәлдә. Татарстан Республикасының тарихи һәйкәлләрне саклау органнары, җирле хакимият һәм биредә яшәүчеләр аларны төзекләндерү һәм карап тотуга игътибар бирсен иде. Бу хәл итә алмаслык мәсьәлә түгел, аларны, торгызып, төбәк туристлык объектлары системасына кертергә кирәк.

Мөслим районында уңай хәл ителгән тагын бер проблема күп кенә төбәкләр өчен актуаль булып тора. Оптимизация шаукымына эләгеп, авыл мәктәпләре һәм клублары ябылганга яки статусы төшкәнгә күрә, музей табылдыклары юкка чыга. Кайбер экспонатлар, шәхси тупланмаларга эләгеп, районнан һәм хәтта республикабыздан да читкә чыгарыла, ягъни фән өчен эзсез югала, чөнки алар яшерен сәүдә системасына эләгә (шул исәптән, «кара казучылар» кулына да).

Аерым алганда, мәктәпкә, балалар бакчасына беркетелеп мәйданнары кыскартылгач, озак вакытлар хуҗасыз хәлдә яткан археологик экспонатлар Олы Чакмак мәктәбеннән авыл клубына тапшырылды. Салавыз Мухан мәктәбендә озак еллар буе б.э.га кадәр III-б.э.ның III гасырларына караган күп кенә археологик табылдыклар, XVII-XIX гасырларга нисбәтле татар һәм рус мәдәнияте предметлары сакланды. Мәктәпнең статусы төшкәнче, мәктәп директоры Д.Н.Мәгалимов һәм аның коллективы тырышлыгы белән, алар уңышлы сакланып килде. Шундый кыйммәтле табылдыклар башка мәктәп музейларында да бар.

Безнең тәкъдим буенча һәм район хакимияте башлыгы Р.Х.Муллинның күрсәтмәсе нигезендә, барлык мәктәп музейларының тупланмалары исәпкә алынды һәм табылдыкларның бердәм исемлеге төзелде, аеруча кыйммәтле экспонатлар исә Мөслимнең төбәкне өйрәнү музеена тапшырылды. Әлеге табылдыклар галимнәр һәм музей белгечләре тарафыннан җентекләп өйрәнелеп, музейга килүчеләргә аларга карап соклану мөмкинлеге туды. ■

Фәнни-фәһемле китап

Гүзәлия Хаҗиева,
филология фәннәре кандидаты, ТФАнең Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре

Халкыбызның телен, әдәбиятын, халык иҗатын, музыкаль һәм тасвирый сәнгатен барлап, теркәп, эзлекле фәнни яссылыкта тикшереп, шулай ук үткән һәм бүгенге көн ноктасыннан якын килеп өйрәнгән фәнни хезмәтләргә ихтыяҗ һәрдаим үзен сиздереп килә һәм әлеге хезмәтләр киләчәк буынга тапшыруда, нәсел җепләрен барлауда әйтеп бетергесез әһәмияткә ия. Татарстан Фәннәр Академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында төрле төбәкләргә сибелеп яшәгән, шул исәптән, Татарстанда яшәүче, төрле локаль культурага караган татарларның этник, мәдәни мирасын бөртекләп җыюга, системага салуга аерым игътибар бирелә. Институтта татар диалектологиясе һәм татар фольклористика мәктәбе традицияләрен дәвам итеп, Татарстан Республикасының Актаныш, Чүпрәле, Кукмара, Апас районнарына, чит төбәкләрдән исә Мари-Эль, Удмуртия Республикасы, Түбән Новгород, Курган, Омск, Томск, Самара кебек татарлар күпләп яшәгән төбәкләргә экспедицияләр оештырылып килә. Экспедицияләрнең нәтиҗәсе буларак, «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядән китаплар дөнья күрде һәм бу эштә Тел, әдәбият һәм сәнгать институты җитәкчесе, филология фәннәре докторы, профессор Ким Миңнуллинның өлеше бик зур. Әлеге сериядән чираттагысы – Мамадыш төбәге татарларының милли гореф-гадәтләрен, локаль культурага хас үзенчәлекләрне туплап, Мамадыш ягын борынгы тарихлы төбәкләрнең берсе итеп таныткан «Милли-мәдәни мирасыбыз. Мамадыш» хезмәте аерым игътибарга лаек.

Аңа 15 фәнни мәкалә кергән. Әлеге китап – Мамадыш төбәгенең эпиграфик язмаларын (М.Әхмәтҗанов), борынгы кульязмаларын (А.Гайнетдинов) барлаган, төбәк топонимиясен, гидронимиясен (Ф.Гарипова), антропонимикасын (Г.Хаҗиева), диалектологиясен (Д.Рамазанова, А.Хөсәенова), этнолингвистикасын (Ф.Баязитова), фольклорын (Л.Мөхәммәтҗанова), мифологиясен (И.Ямалетдинов) этрафлы тикшереп, агач сәнгате (Л.Шкляева), музыкаль һәм тасвирый сәнгать (Э.Каюмова), ювелирлык сәнәгате (И.Фәррахова) үзенчәлекләрен чагылдырган, халкыбызның рухи, милли-мәдәни мирасын туплау һәм өйрәнүгә йөз тоткан саллы хезмәтләрнең берсе.

Мамадыш районы – керәшен татарлары күпләп яши торган төбәкләрдән. Татар халкының бай тарихлы әлеге этник төркеменең мәдәни мирасына, үткәне һәм бүгенгесенә әлеге китапта аерым игътибар бирелә. Татарларның төрле этник төркемнәрен өйрәнү юнәлешендә дә бу китап нәтиҗәле эш буларак саналырга хаклы.

Гүзәл табигатьле Нократ елгасы буенда урнашкан Мамадышның һәм аның эчкерсез, киң күңелле, уңган-тырыш халкының бүгенгесен һәм үткәнен чагылдырган, гореф-гадәт үзенчәлекләрен, сөйләменә хас булган аһәңен, фольклор бизәкләренең матур үрнәкләрен үз эченә туплаган әлеге җыентык – бүгенге тел белеменең актуаль мәсьәләләрен эзлекле фәнни нигездә тикшереп, нәтиҗәләре галимнәр өчен дә, киң катлау укучылар өчен дә кызыклы һәм файдалы булган максатчан эшчәнлекнең күркәм бер үрнәге һәм киләчәк буынга тапшырылырга тиешле саллы хезмәт! ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

ХӘТЕР
ҺӘМ ТУГАН ТЕЛ

Журналыбызның узган санында шул исемдәге «түгәрәк өстәл»дән репортаж биргән идек. Шуның дәвамы буларак, әлеге сөйләшүдә катнашкан Татарстанның халык шагыйре ***Равил Фәйзуллинның*** *өстәмә язмасын тәкъдим итәбез.*

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН: «КҮП ТЕЛЛӘР БЕЛҮ – ЗЫЯЛЫЛЫК, РУХИ ӨСТЕНЛЕК БИЛГЕСЕ»

Күп гасырлар буе, нинди генә авыр чорлар, вакыйгалар булмасын, Телебез, милләтнең җаны буларак, сакланып кала алган. Халыкның рухи ныклыгы, чыдамлыгы нәтиҗәсе бу. Хәзерге чорда да без янә яңа сынауларга дучар. Безнең алда татар телен мәктәпләрдә ничек укыту (яки укытмау?) мәсьәләсе килеп басты. Кайберәүләр карашынча, мәктәпләрдә татар телен укыту рус телен ныклап өйрәнүгә комачау итә, шуңа күрә аны теләгән кеше – укысын, теләмәгән – укымасын, имеш. Сүз Татарстан Республикасының дәүләт телләре турында барганда, мондый фикернең канатлануы сәер хәл, әлбәттә. Әгәр тел өйрәнүне теләү-теләмәүгә китереп терибез икән, моның тупик юл икәне һәркемгә мәгълүм. Һәр фәнне, һәр предметны укыту – мәҗбүрилек, программа белән бәйле. Уку ул – хезмәт. Хезмәт – дисциплина таләп итә. Ә дисциплина исә үзе мәҗбүрилекнең бер формасы. Конституция буенча тигез саналсак та, Россия халыклары телләренә караш төрле. Урысча әйткәндә, двойной стандарт. Бер тел, әйдә, көчәйсен, икенчесе – бетсә дә ярый! Яшерен-батырын түгел, соңгы елларда татар телен өнәмәүчеләр, хәтта аңа нәфрәт белән караучылар ишәйде. Ни кызганыч, андыйлар чыгышы белән татар булган милләттәшләребез арасында да бар. Нигә алай килеп чыкты соң?! Юкса, татар теле, ЮНЕСКО экспертлары фикеренчә, дөньядагы абруйлы һәм кирәкле ундүрт телнең берсе булып санала түгелме соң?! Озын тарихлы, сүз запасы буенча бай, төрки халыклар арасында иң камил телләрнең берсе. Шул телдә язылган әдәби мирас мең еллар белән исәпләнә. Россия тарихыннан азмы-күпме хәбәрдар кеше белә булыр, заманында татар теле халыкара аралашу, дипломатия теле дә булган... Хәер, ерак барасы түгел, **Бөек Ватан сугышы елларында гына да төрле фронтларда 16 татар газетасы чыккан! Димәк, ул телнең кирәге булган. Уртак Ватан азатлыгы өчен безнең телебез дә көрәшкән, җиңүгә өлеш керткән.** Гомумән, телләр белү, ул нинди генә тел булмасын – үзе бер бәхет, үзе бер байлык бит. Һәрхәлдә, тәрәккый илләрдә ул шулай исәпләнә. Күптеллелек хәзерге заманда норма булырга тиеш. Күп телләр белү – зыялылык, рухи өстенлек билгесе. Шунысын да искәртик, Россиядә азчылыкны тәшкил иткән халык вәкилләре, гадәттә, ике (шуның берсе урыс) яки өч телдә иркен сөйләшә.

Марсель Бадыкшин фотосы

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Балтач балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр белән

«КАЙДА СОҢ УЛ БЕЗ ЛАФ ОРЫП МАКТАНА ТОРГАН ТОЛЕРАНТЛЫК?»

Бу көз айларында милли телләр мәсьәләсе буенча җәмәгатьчелекнең зур бер өлешендә киеренкелек сизелә башлады. Мәктәпләргә дә үтеп керде ул тынгысызлык дулкыннары. Татар телен укытуга каршы активист төркемнәр барлыкка килде. Алар имзалар җыя, хатлар оештыра, югары оешмаларга мөрәҗәгатьләр юллый. Бу «эшчәнлек» милләтара татулык файдасына түгел, билгеле. Мондый шартларда мәктәпләрдәге татар теле һәм әдәбияты укытучыларының хәлен аңлап була: әйләнә-тирәндә, тырышып укытып йөргән фәнеңнең кирәксезлеген расларга маташып, пикет-җыеннар оештырып йөрсеннәр әле! Тел өйрәнү мәсьәләләрендә прокуратураның катнашып йөрүе үзе гайре табигый хәл. Кайда соң ул без лаф орып мактана торган толерантлык? Шунысы аяныч: еш кына югары мөнбәрләрдән закон-кануннарга сыешмаган күрсәтмәләр бирелә. Дәүләт телләрен укытуны ничек ихтыяри-теләккә әйләндерергә мөмкин, ди! Юкса, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләрендә телләрнең тигез хокуклылыгы турында ап-ачык язылган ләбаса. Халык ышанычлылары тарафыннан илкүләм парламентларда кабул ителгән законнарны сәке асты дәрәҗәсенә төшермәскә иде бит! Кануннар бозылган яки үтәлмәгән илдә гражданлык җәмгыяте оеша алмый, билгеле. Бу уңайдан әле күптән түгел генә атаклы журналист Максим Шевченконың журналистлар алдында (Казанга ул «Многоликая Россия» конкурсы йомгакларына багышланган тантанага килгән иде) ясаган чыгышы хәтергә килде. **«Әгәр телегезне яклап көрәшмәсәгез, заводларыгызны да, нефть ширкәтләрегезне дә тартып алачаклар,** – диде ул. – **Чынлыкта дөнья «алып булганның барысын да ал!» дигән принципка нигезләнгән. Минемчә, рейдерлык явы һәрвакыт теоретик мәсьәләләрдән башлана».** Кисәтүле һәм бик тә тирән мәгънәгә ия сүзләр бу.

Килешәбез, телләрне укыту системасында (сүз татар телен укыту турында гына бармый) кимчелекләр җитәрлек. Сыйфатсыз дәресләр, архаик ысул-методлар, формаль хисап-отчетлар, өстәп язылган купшы саннар... Әлбәттә, укыту дәрәҗәсе түбән булганда, уңай нәтиҗәләр була алмас. Ә бит монда галиҗәнап Телнең гаебе юк. Гаепнең

байтак өлеше үзебездә дә. Әгәр максатыбызга – яхшы нәтиҗәләргә ирешергә телибез икән, иң әүвәл кешеләрдә, бигрәк тә яшьләрдә, балаларда теге яки бу телгә ихтирам, аны ярату хисе тәрбияләргә тиешбез: телнең байлыгын, аһәңен, матурлыгын, кирәклеген бүтәннәргә расларга, күңелләренә сеңдерергә тиешбез. Үзаңы, милли хисе һәм горурлыгы булган һәр кешегә кагыла бу. Беренче чиратта, әлбәттә, укытучыларга, мөгаллимнәргә. Фәкать талантлы укытучы гына балада теге яки бу фәнгә, шул исәптән телгә дә чын кызыксыну һәм мәхәббәт уята ала. Бу нисбәттән, хөрмәтле Камәрия Зиннур кызы Хәмидуллина җитәкләгән 2 нче татар гимназиясе укытучылары бик яхшы үрнәк була ала, минемчә.

«ҮЗ ДӘҮЛӘТЕҢ БУЛМАГАЧ, БЕЗГӘ ГЛОБАЛЬ СӘЯСӘТКӘ ҖАЙЛАШЫРГА ТУРЫ КИЛӘ»

Һәрнәрсә пропагандалауга мохтаж, шул исәптән тел үзе дә. Миңа калса, телнең зурлыгын, бөеклеген дөньяга күрсәтү һәм раслауның иң ышанычлы һәм кулай юлы – шул телдә иҗат ителгән бөек әсәрләрне халыкка җиткерү. Әйтик, Кол Гали, Кандалый, Тукай, Җәлил, Такташ, Тинчурин, Еники әсәрләре аша. Шагыйрь Наҗар Нәҗминең «Татар теле» дигән мәшһүр шигыре бар. Эчке җегәре көчле булган тәэсирле публицистик шигырь. (90 нчы елларда шул бер шигыре өчен шагыйрьгә Г.Исхакый премиясе тикмәгә генә бирелмәде). Кодрәтем җитсә, ул шигырьне мин һәр татар кешесенә яттан өйрәтер, урам-чатларга, диварларга плакат итеп эләр идем. Телебез өчен һәркемдә горурлык хисе уятыр, рухыбызны турайтыр иде ул!

Әле бу арада гына (20 сентябрь, 2017 ел) минем өчен телебезгә бәйле бер сөенечле вакыйга булды: Камал театрының кече залында, «Калеб» оешмасы инициативасы белән, «Әлиф» дип исемләнгән хореографик спектакль куелды. Анда биюче Нурбәк Батулла сәгатькә якын сәхнәдә биеп, бер гасырда өч имля-графика (гарәп, латин, кириллица) алыштырырга мәҗбүр булган «Туган тел»ебезгә пластик-сыгылма хәрәкәтләрдән үзенчә һәйкәл салды! Биюе белән һәр хәрефнең сурәтен тудырырга тырышты ул. Искиткеч идея һәм шәп башкару. «Афәрин!» дияргә генә кала. Тамашачы аягүрә басып озак-озак алкышлады яшь иҗатчыны. Телнең бөеклеген, үлемсезлеген менә ничек итеп тә тасвирлап, раслап була икән!

Тагын бер күркәм тамаша булды әле бу көннәрдә: 9 октябрьдә Тинчурин театрында «Сәхнә» журналына багышланган кичә узды. Шул кичәдә Казан шәһәренең 6 нчы гимназия укучылары «Беренче театр» пьесасы буенча спектакльдән өзек күрсәттеләр. Күп мәртәбәләр уйналган һәм куелган спектакль бит инде. Әмма... Җыелган халыкны әсир итте балаларның уены. Туган телебезнең җегәре-куәте көчле яңгырады ул кичәдә. Горурлык хисләрен бүләк итте балалар безгә! Гомумән, әдәбиятта булсын, сәнгатьнең бүтән төрләрендә булсын, әгәр без – иҗатчылар замана сынауларын үтәрлек чын әсәрләр иҗат итә алабыз икән, димәк, телебезне саклауга, аның үсешенә үз өлешебезне кертәбез дигән сүз. Шулай ук, соңгы дистә елларда яшьләр арасында ил-тел язмышы өчен янып йөрүчеләрнең ишәюе дә сөендерә. Бөтендөнья татар яшьләре форумнары, «Идел» яшьләр үзәге, «Калеб» – яңа буын» иҗат төркеме һәм башка оешмаларның эшчәнлекләре дә җанлана төште. «Балтам суга батты», – дип утыра торган чак түгел. Хәрәкәтләнергә, эшләргә, иҗтиһад итәргә кирәк! Һәммәбезгә дә мәйдан җитәрлек. Әлбәттә, бүгенге вазгыять күпләребезне бик нык уйландыра. Чын мәгънәсендәге үз дәүләтең булмагач, безгә глобаль сәясәткә җайлашырга туры килә. Туган тел язмышын хәл итүне дә кемнәрдәндер сорап, бүтән телдә язып мөрәҗәгать итәсең, өметләнәсең... Әмма... «Аллага ышан, үзеңә таян!» –диләрме әле? Күп нәрсәләрдә безгә үзебезгә генә ышанырга, үзебезгә генә таянырга кала. Бергә булыйк, бердәм булыйк! Хәзерге вакытта бигрәк тә!.. ■

«КУТАДГУ БИЛИК» – затлы мирас

(МАТБУГАТ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ)

*19 сентябрьдә **«Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы**, «Безнең мирас» журналының турыдан-туры катнашында, дөнья мәшһүре **Йосыф Баласагунның «Кутадгу билик»** әсәренә нисбәтле матбугат конференциясе уздырды. Чарада катнашучыларның фикерләре белән журнал укучыларыбызны да таныштырырга булдык.*





Ләбиб Лерон, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире:
«БАЛАСАГУНИНЫҢ ӘЙТКӘННӘРЕ – НӘКЪ БҮГЕНГЕБЕЗ КӨЗГЕСЕ»

Дөнья әдәбиятының иң гүзәл әсәрләреннән берсе булган «Кутадгу билик»не тормыш китабы, белем һәм тәрбия китабы, дип атар идем. Бер генә мисал:

«Бу дөнья кануны шул: кусаң, кача,
Үзе юл ача ул, барсаң уртача», –

дип яза автор.

«Кутадгу билик»та моныңише акыллы киңәш-гыйбарәләрнең чуты юк:

«Теге дөнья эше уеңда булсын,



Уең мәңге яшәү турында булсын...»
Яки:
«Дөрес яшим, дисәң, һәрнинди хәлдә,
Ашың хәләл булсын, акыллым, тәүдә...»
Яисә:
«Белексез кешедән, зинһар, ерак тор,
Алардан саклану отышлырактыр...»

XI гасырда язылган бу мәшһүр әсәр безнең барчабызның өстәл китабы булырга тиеш. Баласагуниның әйткәннәре – нәкъ бүгенгебез көзгесе. Бу китапны укып чыккан кеше сабак та, гыйбрәт тә ала. «Кутадгу билик»не, һичшиксез, озын-озакка сузмыйча, затлы һәм һәркемгә барып ирешә алырлык китап итеп чыгарырга кирәк.

Рифкать Әхмәтҗанов, филология фәннәре докторы, профессор:
«УРЫСЛАРДА XI ГАСЫРДА МОНДЫЙ ӘСӘРНЕҢ ЭЗЕ ДӘ БУЛМАГАН»

«Кутадгу билик» әсәре – борынгы төрки телдә иҗат ителгән язма ядкәрләрнең бүгенге көнгә килеп җиткәннәреннән иң зурысы һәм күренеклесе. Урысларда XI гасырда мондый әсәрнең эзе дә булмаган. Бу хезмәтнең төрки халыкларның дөнья үсешенә, прогресска керткән өлеше гаять зур. «Кутадгу билик» – бәхетле булу гыйлеме. Баласагуни: *«Кем дә кем бәхетле булырга теләсә, минем китапны укысын»*, – ди. Әсәр зур, күләмле, укыганда ялыктыра, дип әйтүчеләр бар. Бу XI гасырның затлы мирасы икәнен онытмыйк. Әдәби әсәрнең тарихи әһәмиятен билгеләгәндә, чорның да үзенчәлекләрен истә тотарга кирәк.

Татарлар революциягә кадәр бик күп китап чыгарган. Ни кызганыч, «Кутадгу билик»не нәшер итү турында уйламаганнар. «Татарский энциклопедический словарь»ның 1999 елгы басмасында ул, «электән киң таралган әсәр», дип тә күрсәтелә. Әмма «Безнең мирас»та тулаем басылганчы, аерым өзекләрне исәпкә алмаганда, әсәрнең татарча нәшер ителгәне юк иде.

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы, профессор:
«КУТАДГУ БИЛИК» – 14 МЕҢГӘ ЯКЫН ШИГЪРИ ЮЛ»

Төрки-татар әдәбияты меңелдан артык тарихка ия. Кайсы чорны алма – анда халкыбызны бизәрлек әдипләр, ядкәрләр бар. Әмма боларның башында Йосыф Баласагуни һәм аның шаһ китабы – «Кутадгу билик» – бәхет китабы, идарә итү турындагы китап тора. Әсәр Караханилар дәүләтендә – хәзерге Урта Азиянең, Көнбатыш Кытай-Кыргызстан, Казакъстанның зур өлешен алып торган төбәктә язылган. Кыргызларга рәхмәт: Бишкәктә Баласагунига зур һәйкәл куйганнар.

«Кутадгу билик» – гади әсәр генә түгел, ә синкретик хезмәт. Монда фәлсәфә дә, социология һәм педагогика да бар. Әсәр үзеннән соңгы әдәбиятның үсешенә искиткеч зур йогынты ясый, аның традицияләрен Хисам Кятиб, Мөхәммәдьяр, аеруча Утыз-Имәни һәм башка авторларның иҗатында табарга була.

Кызганыч, әсәрнең оригиналы сакланмаган, берничә күчерелмәсе генә билгеле. Бер нөсхәсен 1796 елда австрияле фон Хаммер-Пургшталь Истанбулда таба һәм Вена китапханәсенә бүләк итә. Каһирә нөсхәсен XV гасыр башында Алтын Урдада күчергәннәр, дигән фикер бар. Аннары, мәмлүкләр белән тыгыз элемтә урнашкач, кулъязманы Каһирәгә алып киткәннәр. Нәмәнган нөсхәсен 1913 елда Зәки Вәлиди табып ала.

Әсәрне беренче мәртәбә Г.Вамбери немец теленә тәрҗемә итә. В.Радлов 1891-1910 елларда ике томда транскрипциясен һәм рус теленә тәрҗемәсен нәшер итә. Рәшит Рәхмәти Арат әлеге әсәрне төрек телендә бастырып чыгара. Гадәттә, без Ильминскийны сүгәбез, ә ул, тюрколог буларак, «Кутадгу билик»не өйрәнгән белгечләрнең берсе. 1983 елда С.Н.Иванов әлеге мирасны «Благодатное знание» исеме белән Мәскәүдә урысчага тәрҗемә итеп чыгарды. Шагыйрә Лена Шагыйрьҗан да шул урысчасыннан, аерым кисәкләрен татар теленә тәрҗемә кылып, «Мәдәни җомга»да бастырган иде.

Бу эшне гадәти тәрҗемәче генә башкара алмый, монда телне, шул чордагы үзенчәлекләрне белергә кирәк. Аны Рифкать Әхмәтҗановның тулысынча тәрҗемә итеп, «Безнең мирас»та бастыруын гаять мантыйкый гамәл дип саныйм. Мөхтәрәм Рифкать әфәнденең шигъри куәсе дә бар – ул Мәҗит Гафури нәселеннән.

«Кутадгу билик»не тәрҗемә итү – биниһая зур хезмәт. 14 меңгә якын шигъри юл. Бу әсәрне безнең Татарстан китап нәшриятында, дәүләт акчасына затлы китап итеп чыгарырга кирәк. Әсәр урыс, төрек, үзбәк телләрендә күптән басылып чыкты. Әмма китап буларак хәзергә кадәр татар телендә дөнья күргәне юк.

Ләйлә Минһаҗева, филология фәннәре докторы, профессор:
«СТУДЕНТЛАРЫБЫЗГА АКЫЛ-ФИКЕР БИРЕРДӘЙ ӘСӘР»

«Кутадгу билик»нең журналда басылып чыгуы – зур шатлык. Мин студентларга еш кына: «Әгәр дә тормышыгызда нинди дә булса проблема килеп туса, сез Каюм Насыйриның «Китаб-әт-тәрбия»сен алып укыгыз, чөнки аның һәр бүлегендә киңәш бирердәй фикер әйтелгән», – дим. Шул ук фикерне «Кутадгу билик»кә нисбәтле дә әйтергә мөмкин. Юкка гына бу китап «бәхет китерүче белем» түгел. Димәк, бу – студентларыбызга акыл-фикер бирердәй әсәр. Моны укып чыгу безгә бик күп кыйммәтләр турында

уйланырга җирлек булдырачак, шунлыктан, аны университет программасында да бик иркенләп өйрәнербез, дип уйлыйм.

Хатыйп Миңнегулов:
«БАЛАСАГУНИ ҮЗ УКУЧЫЛАРЫНА ДӘРЕС, ГЫЙБРӘТ БИРӘ»

Миңа, «төркиләрдә дәүләтчелек» темасы белән шөгыльләнгәндә, Кытай, Һиндстан, Борынгы Греция әсәрләренә мөрәҗәгать итәргә туры килде, әмма үзәк чыганакларның берсе итеп «Кутадгу билик»не алдым. 2014 елда «Идея государственности в тюрко-татарской литературе VII-XVIвв.» исемле китабым дөнья күрде. Дәүләтчелек, хөкемдарлык идеясе безнең әдәбиятыбызда ничек чагыла? Бабаларыбыз дәүләтле булуны яшәеш зарурилыгы дип санаган. Кол Гали, Котб, Мөхәммәдьяр, дәүләт башында кем торырга тиеш, дәүләт нинди булырга тиеш, дип уйланган. Йосыф Баласагуниның «Кутадгу билик» әсәре – дәүләтчелек идеяләренең әдәби гәүдәләнештәге күркәм бер үрнәге. Әгәр дә хакимнәр үзләренә йөкләнгән бурычны башкарса, ил, дәүләт һәм халыкның тормышы яхшы булачак.

Белем, мәгърифәт – әсәрнең үзәгендә. Баласагуни гыйлемне күккә чөя. *«Сүз арыслан кеби, авызыңнан чыкса, башыңа җитәр»*, – ди. Баласагуни сабырлык, түземлек, ярдәмчеллек кебек матур әхлакый сыйфатлар турында яза. Хакимнәргә мөрәҗәгать итеп: *«Шагыйрьләр кеше күңеле төпкеленнән, диңгездән энҗе җыйган кебек, хәзинәләрне табалар. Син аларны яхшылык белән тот. Алар әйткән сүз мәңгелеккә кала. Әгәр дә аларның күңелен күрмәсәң, яманатың белән тарихка кереп калырсың»*, – ди. Й.Баласагуни төрле тармаклар буенча үз укучыларына дәрес, гыйбрәт бирә.

Рифкать Әхмәтҗанов:
«ӘСӘР ТУГАН ТЕЛЕБЕЗНЕҢ БАЙЛЫГЫН ТОЕМЛАРГА МӨМКИНЛЕК БИРӘ»

Без урыс телендәге һәм урыс теленнән булган тәрҗемәләр белән мавыгырга тиеш түгел, ә үзебезнең телне белергә кирәк. «Кутадгу билик» – бөтен төрки халыкларның уртак мирасы, төрки телебезнең хәзинәсе. Һәр милләт аннан үзендә генә булган сүзләрне, гыйбарәләрне таба ала. Дөрес, урысча тәрҗемәләр белем бирә, әмма алар буенча әлеге мирас турында дөрес күзаллауны тудыру кыен. Әсәр туган телебезнең байлыгын тоемларга мөмкинлек бирә, татар теленә хөрмәт уята.

Хатыйп Миңнегулов:
«ТӨРКИ-ТАТАР ТЕЛЕ ИСКИТКЕЧ БАЙ, БЕЗ ШУЛ БАЙЛЫКНЫҢ 80 ПРОЦЕНТЫН ФАЙДАЛАНМЫЙБЫЗ»

Әсәрдә хәзерге укучыга аңлашылмаган сүзләр бар. Күпләр Кол Гали, Мөхәммәдьярлар авыр тел белән язган, укырга авыр, диләр. Дусларым, алар авыр тел белән түгел, ә шул чордагы укучыларның теле белән язылган. Без ул телне белмибез, төп гаеп үзебездә. Төрки-татар теле искиткеч бай, шул байлыкның 80 процентын файдаланмыйбыз, зур мирас читтә кала, шуңа күрә дә борынгыларның әйткән сүзләре, әсәрләре аңлаешсыз тоела. Кызганыч, «Кутадгу билик» кебек байлыгыбызны күрсәтә, гавамга җиткерә алганыбыз юк иде. «Безнең мирас» журналы редакциясе, бу ядкәрне халкыбызга ирештереп, игелекле гамәл кылды.■

Йосыф Баласагуниның «Кутадгу билик» әсәрен ***http://beznenmiras.ru*** *сайтыннан укырга, матбугат конференциясенең видеоязмасын* ***http://tatar-inform.tatar*** *сайтыннан карарга мөмкин.*

«ШЫГЫРДАН ТӨЕНЕ»Н ЧИШКӘНДӘ

Фатих Кутлу

(Кайтаваз-юльязма)

ШЫГЫРДАНДА

Июнь азагы иде. Рамазан гаете белән котларга, дип, Ләбиб абый Леронга шылтыраттым. Әңгәмә барышында ул миннән: «Шыгырданда булганың бармы?» – дип сорады. Тискәре җавап ишеткәч: «Минем дә булган юк. Вакыт тапсаң, синең «Шыгырдан төене» язмасы урнашкан сан дөнья күргәч , әйдә, бергә барып кайтабыз?» – дип өстәде. Бу һич көтелмәгән тәкъдим иде. Мин аны бик теләп кабул иттем. Хәтердә мәкаләмнең соңгы җөмләсе яңарды: «Минем үз гомеремдә Шыгырданда булганым юк. Ләкин хәзер, баштан мондый вакыйгалар кичкәч, анда бармый калу ярамас. Фидания апаның да анда барасы килә. Киләчәктә морадыбызга ирешергә насыйп әйләсен иде!»

Теләгем фәрештәләрнең «Амин!» дигән чагына туры килгән, күрәсең, дип куандым.

Шул минуттан башымда төрле ниятләр корыла башлады. Беренче чиратта мәрхүм остазым, Шыгырданның сөекле улы Мөнир абый Нигъмәтнең (Нигъмәтуллов) кендек каны тамган нигезен, уйнап үскән җирләрен, якын туганнарын күрү, әти-әнисенең каберенә барып, рухларына дога кылу кирәк. Аннан, Ркаил абый Зәйдулланың әнисе Гөлинә апаның туган йортында булу. Һәм иң дулкынландыргыч өлеш: «Шыгырдан төене» язмасында төп урынны биләгән Фидания апаның 1951 елгы фотосына төшкән җиде кыз укучысын (бүген алар, билгеле, әби булырга тиешләр) табу, һич югы, исемнәрен ачыклау, алар белән күрешү. Шуңа өстәп, Фидания апаның хезмәттәшләрен дә табып-барлап карыйсы иде... Сүтелеп киткән хыял йомгагы шулай бик еракка тәгәрәде.

Мин, Фидания апага шылтыратып, аны да сәфәргә чакырдым. Бик барасы килсә дә, Чаллыдан Чуашстанга ук юл чыгарга базмады: «Тәкъдимең өчен мең-мең рәхмәт сиңа. Шыгырданымны гаять күрәсем килә. Шулай да, яшем сиксән сигездә. Ерак юлда ни булмас? Без киләчәктә улым белән акрын-акрын, юлда туктый-туктый барып кайтырбыз әле, боерса!» – диде ул. «Амин!» – шулай була күрсен, дигән теләктә калдым.

Йә, хуш, «Безнең мирас»ның җиденче саны дөнья күрде. Минем Шыгырданга барганчы ук фоторәсемдәге җиде укучыны ачыклый башлыйсым килә иде. Гөлинә апага шылтыратып сорашырга керештем. (Журнал аның хозурына ирешкән иде инде.) Сурәттәгеләрнең өчесе мәңгелеккә күчкән... Ул бер-ике кешенең генә исемен хәтерли алмады. Фидания апа белән бергә утырып Миңгали Карама Шыгырданда Гөлинә апаларның ут күршесе булган икән. Үзе вафат, ди, инде. Төп нигездә килене Фидания гомер кичерә.

---

[1] «Шыгырдан төене» мәкаләсе «Безнең мирас» журналының 7 нче санында дөнья күрде. Вакыйгалар һәм исемнәр күңелегездә төгәл тәртиптә урнашсын өчен, әлеге язманы яңадан карап чыгарга киңәш итәбез. – **Редакция.**

Фидания Әхмәтҗанова укучылары белән. Беренче рәттә сулдан уңга: Алия Айзатуллова (вафат), Фидания Әхмәтҗанова (укытучы), Сәгадәтбану Якушова; икенче рәттә сулдан уңга: Мөнирә Шәрәфетдинова (вафат), Сания Йосыпова (Кучатова), Таһирә Борчаклы (Йосыпова), Минзадә Әюпова (вафат), Камалия Вәлиуллина (Шәпәева). Шыгырдан авылы, 1951 ел

Гөлинә апаның туган йортында бертуганы Памир абый торганга, аңа да шылтыратмый кала алмадым. Мәкаләдә игътибарга алынган Зыятдин Сираев Мөнир Нигъмәтнең агасы булган Дамир абыйның күршесе булып чыкты. Үзе үлгән, хатыны гына исән. Мин Дамир абыйга да, Памир абыйга да озакламый Шыгырданга килеп чыгу теләге барлыгын әйттем. Алар «Шыгырдан төене» язмасы белән танышмаган иде әле...

Әүвәл 16 июльдә юлга чыгасы идек. Кайбер сәбәпләр аркасында сәфәребезне бер көнгә кичектерергә туры килде. «Йә, Раббым, сәяхәтебез күркәм рәвештә үтсен иде!» – дип теләк теләп кузгалганнан соң гына игътибар иттем: баксаң, юлга 17.07.2017 көнне 7.00 сәгатьтә чыкканбыз икән...

Кичен генә Фидания апа белән сөйләшкән идем. Ул, дулкынланып-хисләнеп: «Яшьлегемнең, укытучылык чорымның иң беренче һәм иң гүзәл еллары шунда үтте, – дип, истәлегенә чумды. – Анда халык бик яхшы. Укучыларым булсын, ата-аналар булсын – берсе дә рәнҗетмәде. Беркемгә дә хәтерем калмады. Хәнифә әбидә тордым. Бик диндар әби иде. Аны да һич онытмыйм. Шыгырдан – минем җәннәтем. Шыгырдан – шифам, дәвам. Шул авылны уйлаганда сәламәтләнәм, гомерем озая. Тәүге ярым да Шыгырдан егете булды... Беренче мәхәббәтен кем онытсын?» «Сер булмаса, исемен әйтмәссезме?» – дип сорадым, кыенсына төшеп. «Сер түгел, Фатих, аны Шыгырдан халкы да, балаларым, җәмәгатем дә белә иде, – диде. Аннары сүзен дәвам итте: – Ун сыйныф тәмамлаган, мәктәптә бер үк вакытта география укытучысы да, китапханәче дә булып эшләгән Мәннаф Немакаев исемле егет иде ул. Дөрес, 1953 елдан соң без бер тапкыр да күрешмәдек, хатлар алышмадык. Ләкин ул минем күңелемдә якты истәлек булып калды. Ирем Азат исән чакта Шыгырданга барып чыгарга, гаиләләребез белән танышырга теләгән идек. Насыйп булмады». Мин Фидания апаны хәйран калып тыңладым. Мәхәббәтнең нинди кодрәтле булуына тагын бер кат инандым.

Мөнир Нигъмәтнең туган нигезендә. Сулдан уңга: Фатих Кутлу, Дамир Нигъмәтуллов, Ләбиб Лерон. 2017 ел

Дүшәмбе көнне җиде тулганда «ТАТМЕДИА» бинасы каршында очраштык. Ләбиб абый бер туплам «Шыгырдан төене»н әзерләп куйган иде. Нәкъ вакытында юлга чыктык. (Аңарчы машинаның номерына күз төшердем: 725. Җидегә башлана, ике белән бишне кушкач, янә җиде килеп чыга.)

...Унынчы яртылар тирәсендә Шыгырданга барып җиттек. Иң әүвәл күзгә ташланганы шул булды: монда капка-коймаларны гаять биек коралар икән.

Дамир абый безне Тукай урамының 27 нче йорты алдында каршылады. (Шагыйрь урамы, шагыйрь яше! Анда да 7 саны бар...) Кул биреп күрешүгә үк «Безнең мирас»ның җиденче санын тоттырдым һәм хәзер үк «Шыгырдан төене»н укып чыгуын үтендем. Чөнки бу мәкаләне укымыйча аңа сәяхәтебезнең төп максаты аңлашылмаячак иде. Мин күккә терәлгән йортка бактым: шушы нигез – Мөнир абый Нигъмәтнең кендек каны тамган урыны лабаса!

Соңыннан Дамир абыйдан: «Мәннаф Немакаев исемле кеше Фидания апаның беренче мәхәббәте булган. Кем ул?» – дип сорадым. Дамир абый, ихлас елмаеп: «Беләбез ул тарихны... Мәннаф абыйның әтисе белән минем әти бертуган», – дигәч, телсез калдым. Ул: «Безнең әти Нигъмәтуллов фамилиясен алган, алар – Немакаевны, – дип ачыклык кертте. – Әтинең кабер ташында Нигъмәтуллов янәшәсенә Немакаев фамилиясе дә язылган».

Дамир абый һәм аның гомер юлдашы Әлфинур апа безне табынга дәште. Башта чәй эчтек, аннан ашка күчтек. (Мишәрләрдә тәртип шундый.) Аннары чират «Шыгырдан төене»ндәге фоторәсемгә җитте. Безнең бәхеткә, исәннәрнең дүртесе дә Шыгырданда тора булып чыкты. Кызлар бит, ничек төрлесе-төрле якка таралмаган?! Шулай да, 1840 хуҗалыгы булган 6000 кешелек авылда ул дүрт «укучы»ны табу җиңел эш түгел иде. Рәхмәт яусын, Дамир абый: «Борчылмагыз, барысын да үзем табып бирермен», – дип, көне буе безгә рәһбәрлек итәргә (юл күрсәтергә) алынды.

Әүвәл иң якын күршеләре, өч ел элек мәңгелеккә күчкән Зыятдин Сираевның хатыны Нәҗия апа белән дә танышасыбыз, мәрхүмнең фотосын сорыйсыбыз килде. Нәҗия апаны чакырдылар. Журналны аңа да бүләк иттек. Ул Зыятдин абыйның фотосын без киткәнче хәстәрләп куярга сүз бирде.

Алга таба язма җиңелрәк кабул ителсен өчен, бу урында, вакыйгаларны беркадәр ашыктырыбрак булса да, «Безнең мирас» журналының 7 нче санында басылган фотосурәттәге укучыларны санап китик. Болар, беренче рәттә сулдан уңга: Алия

Айзатуллова (вафат), Фидания Әхмәтҗанова (укытучы), Сәгадәтбану Якушова; икенче рәттә сулдан уңга: Мөнирә Шәрәфетдинова (вафат), Сания Йосыпова-Кучатова, Таһирә Борчаклы-Йосыпова, Минзадә Әюпова (вафат), Камалия Вәлиуллина-Шәпәева.

Иң элек Сания апаларга юл тоттык. Җөмләдән, аның олы улы Мирхәйдәр белән Дамир абый баҗайлар да икән әле.

Фоторәсемдә – 16 яшьлек Сания туташ. Шул вакыттан алтмыш алты ел гомер үткәч, шыгырданлы Мөнир Нигъмәттән сабак алган һәм «Шыгырдан төене» исемле мәкалә бастырган төрек кешесе, кулына «Безнең мирас» журналын тотып, Сания карчыкның капкасын кагарга бара...

Сания Йосыпова-Кучатова. 1951 һәм 2017 ел

Камалия Вәлиуллина-Шәпәева. 1951 һәм 2017 ел

Йортка уздык, утырыштык. Мин Сания апага текәлдем: Раббем, картайса да, кешедән яшьлектәге чалымнары китми икән! Бер сүз әйтмичә, Сания апаның алдына «Шыгырдан төене»н ачып салдым. Фоторәсемне күрүгә үк, иң беренче итеп: «Сәгадәтбану бит бу!» – дип аваз салды. Ләбиб абый аңа үзен күрсәтеп: «Ә бусы кем?» – дип елмайды. «Бусы – Сания», – диде ул, көлемсерәп. Фидания апа турында сөйли башлагач: «Исәнме ул?» – дип, гаҗәпләнүен яшермәде. Җавап урынына мин Фидания апаның телефон номерын җыеп, төребкәне Сания апага суздым. Башта каушап калган әби тиз арада исенә килде. Гәпләшә башладылар: «Исәнмесез, Фидания апа! Мин 82 яшьтә генә бит әле. Ирем 86 яшьтә. Балаларым, оныкларым бар. Син бик матур идең. Без үзара сине «Матур апа» дип йөрттек. Әйтмәгез дә инде, каян булды бу?! Мин дә шундый кинәндем. Сабан туйларына кайтыгыз, кунак булырсыз. Рәхмәт!»

Безнең күрешәсе кешеләр бихисап иде әле. Журналны бүләк итеп, фотога төштек тә, саубуллашып, Камалия Вәлиуллина (Шәпәева) йортына юнәлдек. Рәһбәребез Дамир абый булганга, безнең алда барлык йортларның ишеге ачылды.

Хуҗалар аптыраулы караш белән безне Камалия әби бүлмәсенә озаттылар. Әбине күрүгә: «Бер тамчы да үзгәрмәгән. Мин аны урамда очратсам да таныр идем», – дип уйлап куйдым. Ул, безне күргәч, гаять дулкынланып: «Кем соң сез?» – дип сорады. Дамир абый: «Хәзер белерсең», – дип елмайды. Камалия әбинең янына утырдым да баягы язманы ачып җибәрдем. Теге фоторәсемне күрүгә, тетрәнеп: «Ай-яй! Минем белән бергә укыган кешеләр бит болар!» – дип шаккатты. Аның гаҗәпләнүе соң чиккә җиткән иде. Ул безгә фотодагы кешеләрнең барысын да исемнәре белән санап чыкты. (Аңарчы Таһирә Борчаклы белән мәрхүмә Мөнирә Шәрәфетдинованы

Ләбиб Лерон, Памир абый, Фатих Кутлу. 2017 ел

Миңгали Карама

ачыклый алмаган идек әле.) Фидания апаны фамилиясе белән атады. Мин, елмаеп: «Фидания апа хәзер кайда икән?» – дип сорашкан булдым. «Ул Татарстаннан иде, Шыгырданнан түгел», – дигән җавап ишеттем. «Исәнме икән?» – дидем. «Кем белә инде? Мин дә сиксән өчтә бит. Мине укытканны, белмим, белмим...» – дип, тел төбендәгесен гомуми сүзләр артына яшерде. «Сезне хәзер үк аның белән сөйләштеримме?» – дигәч, бөтенләй өнсез калды. Берничә мәртәбә кайтып сорагач кына һушына килде: «Аңламый торам, сөйләштер, ай!» Әңгәмәдәшен күз алдына китерү җиңелрәк булсын өчен, Фидания апаның хәзерге фоторәсемен дә күрсәттем. Ул: «Фидания апа бик матур тора. Татарстандагылар матурлар», – диде. Шылтыраттым. Исәнләштеләр, сөйләштеләр. Камалия апа сүзен болай җөпләде: «Хозурына тулы иман белән күчәргә язсын! Шыгырданнан күп сәламнәр!»

Без, журналны калдырып, китәргә рөхсәт сорадык.

Иртәдән бирле Памир абый көтә иде. Вакыт өйләгә якынлашты. Килүебезгә табын җәйгәннәр. Өстәл янында сөйләшеп утырдык. Памир абый авылның аксакалы, тарихчысы икән. Ул барыбызга да үзе язган «Шыгырдан» исемле саллы хезмәтен бүләк итте. Миңа дигән китапны Фидания апа исеменә язып бирүен үтендем. Бу аңа – ерак Чаллыдагы якын танышыма көтелмәгән бүләк булачак иде!

...Миңгали Карама алты ел элек вафат булган. Фоторәсемен сорарга һәм журнал калдырырга, дип, аның килене яшәгән капканы кактык. Безне Фидания апа үзе каршы алды. Биредә фотолар карадык, берничәсен үзебезгә төшереп алдык.

Сәгадәтбану Якушова. 1951 һәм 2017 ел

Шуннан Сәгадәтбану апаларга кузгалдык. Алар Таһирә апа Борчаклы белән бер урамда торалар. Сәгадәтбану апаның энесе каршылады. «Апа хәтерләмәс, бик картайды», – дисә дә, Сәгадәтбану апа фоторәсемдәге кешеләрнең барысын да фамилияләп искә төшерде. Телефоннан

сөйләшергә генә рәте юк иде. Журнал калдырып, ары юнәлдек.

Таһирә апа бу көннәрдә Казанда, кызы янында булып чыкты. Журналны киленнәренә тапшырдык. Бәгырьне үкенеч талкыды: «Эх, насыйп булмады! – дип уйладым. – Без Казаннан килдек, ә ул Казанга киткән»...





Мәннаф Немакаев (Фидания Әхмәтҗановага туган көнендә үзе бүләк иткән фото). 1951 ел

Шулай итеп, Таһирә апа Борчаклыдан кала, фоторәсемдәге исәннәрнең барысы белән дә күрештек. Боларга бәрабәр, Фидания апа белән бергә укыткан мәрхүм Зыятдин Сираевның хатынын, Миңгали Караманың киленен күрдек.

Минем тагын Мәннаф Немакаевнең, һич югы, фотосын күрәсе килә иде. Ләкин аның хатыны белән балаларының Канашта яшәве ачыкланды. Нишләргә белми баш ватканда Мәннаф мәрхүмнең бертуган энесе Рифкать абыйның Шыгырданда торуын белдек. Берәр фотосы табылмый калмас, дип, аларга юл тоттык. Түрдән уздык, утырыштык. Дамир абый мине: «Фатих, Мөнирнең шәкерте», – дип таныштырды. Рифкать абыйдан: «Фидания Әхмәтҗанованы беләсезме?» – дип сорагач, озак вакыт сынап багып торды. Сүземне дәвам итеп: «Энесе булгач, ул вакыйга Сезгә билгеледер?» – дигәч кенә, йомшарып: «Билгеле инде, мин аларны күреп, карап үстем», – дип җөпләде... Тиз арада Мәннаф мәрхүмнең яшьлек фотосын табып бирделәр. Чыннан да, бик чибәр егет булган. Табын янында беркадәр сөйләшеп утыргач, журнал калдырып, китәргә рөхсәт сорадык.

Зыятдин Сираев

Шыгырданга сәфәребезне йомгаклап, остазымның әти-әнисе каберенә дога кылырга бардык. Зиратта иң элек әнкәсенең каберенә тап булдык. Шәрифҗан кызы Вагыйзә Нигъмәтуллова – Мөнир агабызны тудырган, үстергән, кеше иткән ана!.. Рухына дога кылып, әчкәрәк үттек. Остазымның әтисе Хабибулла улы Миңнулла Нигъмәтуллов/Немакаев (шулай авыш сызык аша язылган) каберенә җитеп, монда да Коръән аятьләрен укыдык. Урыннары җәннәттә булсын! Амин!

Аннары иң элек кергән йортка кайттык. Наҗия апа мәрхүм ире Зыятдин Сираевнең фоторәсемен әзерләп куйган икән. Аны Дамир абыйның оныгы барып алды. Чәйләп канәгатьләнгәч, кузгалырга рөхсәт сорадык. Шыгырданга сәфәребез шуның белән тәмамланды. Эшләрен ташлап, вакытын кызганмыйча, көне буе безнең белән йөргән Дамир абыйга да, безне сыйлап-туендырып җибәргән җәмәгатенә дә бик күп, бик күп рәхмәтләр яусын, дидек!

Ахыры киләсе санда ■

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

Омск күренеше. XX гасыр башы

ОМСК ШӘҺӘРЕ

Омск Себернең хәрби мәркәзе булып тора. Монда һәрвакыт күп санда рус солдатлары тупланган була. 1838 елда хөкүмәт Омск шәһәрен хәрби мәркәз итәргә һәм биредә хәрби көч тупларга, дигән карар кабул иткән.

Шәһәрнең биналары да бик үк иске түгел. Башта – 1716 елда – бу урында кечкенә генә бер авыл барлыкка килә, ләкин кешесе бик аз була. Шуңа күрә бирегә Дон казаклары мәҗбүри күчереп утыртыла. Болар исә дала кыргызларының һөҗүмнәренә каршы тору өчен ныгытма кебек итеп кулланылалар. Ул заманнарда юллар юк, елгаларда пароходлар юк. Патша армиясендә хезмәт биш елга сузыла. Шул сәбәпле солдатлар, теләсәләр-теләмәсәләр дә, хезмәт иткән җирләрендә яшәп кала торган булганнар. Шуңа да карамастан, 1782 елда Омск кечкенә генә шәһәрчек хәленә килә алган. Тирә-ягы

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

бөтенләе белән дала. Күчмә тормыш белән яшәүче кыргызлар, җәй җитүгә күчеп китеп, төрле якка таралалар, кыш кергәч кенә кайтып утыралар. Омск 1824 елда губернага әйләнгән. Әле ул вакытларда да биредә җирле мөселманнардан һәм солдатлардан башка беркем дә яшәмәгән.

Бүгенге көндә исә, бу җирләрдән Себер тимер юлы үтте, Омск та гаять төзек шәһәргә әйләнде. Җитештереп чит төбәкләргә чыгарыла торган товар кыйммәтенең күләме 10000000 сумга җиткән.

МӘГАРИФ

Александр I заманында биредә хөкүмәт тарафыннан бер мәчет салына. Тик моннан әле ун еллап элек тә, мөселманнар өчен бер генә башлангыч мәктәп тә юк иде. Биш ел элек ике мәктәп ачылган, аларда бүгенге көндә йөздән артык укучы белем ала.

Омск мәктәпләренең биналары гаять дәрәҗәдә төзек, шулай ук уку-укыту эшләре дә бик яхшы тәртипкә салынган.

Биредә мөселман сәүдәгәрләр күп түгел. Беренче дәрәҗәле сәүдәгәрләр арасында бәлки бер мөселман кешесе табылыр. Ләкин шундый кечкенә генә җәмгыять үз тырышлыгы белән бу кадәр мәктәп ача алган икән, бу бары тик берничә кешенең күңел киңлеге, иман ныклыгы нәтиҗәсе булып тора.

Хөкүмәт тарафыннан руслар өчен ачылган ике гомум лицей һәм бер хәрби лицей да бар. Моннан тыш, дала кыргызларының балаларын аулау өчен миссионер мәктәбе дә ачылган.

СӘҮДӘ

Омск шәһәре Себернең зур хәрби үзәге булганга күрә, биредә яшәгән халыкның күп өлешен хәрбиләр тәшкил итә. Офицерлар һәм түрәләр бик күп, ә һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр чагыштырмача аз. Омск шәһәренең әйләнә-тирәсе дала, ә далада яшәүчеләр бөтенләе белән күчмә тормыш итүче кыргыз-казахлар булганга, хөкүмәт бу җирләрне һәрвакыт хәрби командующий идарәсе астында тота. Генерал-губернатор гадәттән тыш хәлләр командующие да булганга, бу җирләр һәрвакыт кырыс идарә һәм кайчакларда хәрби идарә астында да була. Шул сәбәпле, биредә сәүдәгәрләр өчен тормыш итү кыен.

Шуңа да карамастан, Омск шәһәрендә чит ил сәүдәгәрләре дә бар, бигрәк тә Дания, Бельгиядән килгән сәүдәгәрләр күп. Боларның сәүдәсенең күп өлеше – Тобольск губернасына караган Себер авылларында атланмай сатып алып, Англиягә җибәрү. Омск базарында ел да 3000000 сумлык май Англиягә җибәрү өчен сатып алына һәм соңгы елларда бу май сәүдәсе гомум товар әйләнешендә гаять зур урын биләп тора икән.

Омск шәһәреннән Томск шәһәренә кадәр поездда мин Омск шәһәрендә бары ике көн кундым да, аннан Томск шәһәренә юл тоттым.

Омск вокзалына килдем. Дусларымның берсе – Омск имамы мулла Ниязи әфәнде Сөләйманов җәнаплары – безне озатырга, дип, бирегә кадәр килгән иде.

Кассага барып, һәрвакыттагыча икенче класслы билет сорадым. Алары беткән булып чыкты, шул сәбәпле, беренче класслы билет алырга мәҗбүр булдым. Ләкин кесәдәге акча җитәрлек түгел. Әле дә ярый янымда Ниязи әфәнде бар иде, малына бәрәкәт бирсен, билет алырга булышты.

Томск шәһәренә кадәр юл 890 чакрым. Беренче класслы билетның бәясе 19 сум 35 тиен иде. Беренче класслы вагонда махсус купеда берүзем бардым.

Себер тимер юлында вагоннар бик яхшы, төзек. Бигрәк тә беренче класслы вагоннар яхшы, боларда һәр кешегә купе дип атала торган аерым бүлмәләр бар.

Мулла Ниязи әфәнде белән бик самими саубуллаштык, ул арада поезд да кузгалып китте. Көннәр бик суык тора иде, ләкин вагоннар бик яхшы булганга, биредә һич суык түгел, теләгәнчә чишенеп утырырга мөмкин иде.

Себер тимер юлы гаять озын, поезд исә сәгатенә бары тик 25 километр юл үтә. Вагонда, гел бер урында утырып барырга туры килгәнгә, кешенең бераздан эче поша башлый, шул сәбәпле, юлчылар, теләсәләр-теләмәсәләр дә, бер-берләре белән танышып, сөйләшергә мәҗбүр булалар.

Омск станциясендә алган газеталарның һәммәсене дә игъланнарына кадәр укып чыктым. Башка бер эш тә юк. Бераз Корьәнне тилявәт иттем[1].

Ул арада янымдагы купеның ишеге, үзеннән-үзе булса кирәк, кинәт кенә ачылып китте. Анда, күршемдер, мөгаен, иреннәре арасына сигара кыстырган бер ир-ат басып тора. Ишек ачылуга, минем күрше:

– Гафу итегез, – диде, – мин ишеккә һич кагылмадым, ләкин ул миңа яхшылык эшләде. Мин үз-үземнән, күршем кем икән, нәрсә укый, нинди телдә сөйләшә, дип сорап кына бетергән идем. Шул мизгелдә ишек ачылды. Бу кадәр йөгерек ни укыйсыз, кулыгызда китап та юк? Купеның ачкыч тишегеннән карарга мәҗбүр булдым. Ләкин ишеккә кагылмаган идем, үзе ачылып китте, вагон чайкалып киткәндер, мөгаен.

– Мин үзем дә, күршем кем икән, бу хуш сигара исе кайдан килә икән, дип уйлаган идем, – дидем.

– Ай, кабул итсәгез, Сезне дә сигара белән сыйлыймчы, – диде дә, кесәсеннән кап чыгарып, нәзакәтле итеп миңа сузды.

– Безне Рамазан аебыз дәвам итә, – дидем. – Көндез берни ашамыйбыз, эчмибез. Югыйсә, сыегызны кире какмас идем.

– Сез кем, кайсы милләт кешесе? – дип сорады. Татар булуымны әйттем.

– Бик яхшы, – диде. – Мондый очраклылыкка рәхмәтлемен. Сез төрки асыллысыз, димәк. Әйтегез әле, зинһар, Сез хәзерге көндә Төркиядә барган инкыйлабка (революциягә) ничек карыйсыз? Газеталарыбызда басылган хәбәрләрнең дөреслегенә ышанасызмы?

– Сәясәт белән һич шөгыльләнмәдем, андый хәбәрем дә юк. Бу хакта берни әйтә алмыйм, кичерегез, – дидем.

– Сезнең Төркиядә булганыгыз бармы? Төрекләр сәләтле халыкмы, түгелме, белмисезме? Бер дә таныш түгелмени Сез? – дип сорады.

– Кешенең күргән булуы да, таныш булуы да мөмкин. Ләкин әгәр аның сәяси белеме булмаса, мондый җитди мәсьәләләрдә ул берни әйтә алмас, – дип җавап бирдем дә, сүземне шул рәвешле дәвам иттем. – Безнең кебек мәктәп тәрбиясеннән мәхрүм милләтләрнең сәясәт өлкәсендә мәгълүматчы булуы, бигрәк тә кимүгә, бетүгә дучар милләтләрнең бөек дәүләтләрнең дипломатларын да аптырашка салган мәсьәләләрдә фикер әйтүе – йомырка сатучының кыйммәтле ташлар турында фикер әйтүе кебек булыр иде.

– Сүзләрегез хак, фәкать... – дип дәвам итте күршем. – Төркия мәсьәләсе – тарихтаише булмаган мондый инкыйлаб дип әйтү, бәлки, тагын да дөресрәк булыр – Сезнең кебек дини һәм милли бәйләнышлары көчле булган кешеләрне ничек кызыксындырмасын икән, хәтта безнең кебек, төрекләргә һич катнашы булмаган милләтләрне дә кызыксынырга мәҗбүр итте. Биредә безнең христианнар, гади халык: «Кан кардәшләребез – болгарларның хәлләре ничек булачак?» – дип борчылалар, укый-яза белмәгәннәре дә, аксакаллар оешмасына килеп: «Болгарлар белән төрекләр сугышмыйммы?» – дип сорыйлар. Сезнең шундый уй-хисләрегез генә дә юкмы? Бигрәк тә Сезнең кебек кешеләрнең? Татарлар арасында танылган кеше булуыгыз аңлашылып тора. Беренче класслы вагонда барасыз, янызда берничә газета бар. Билгеле булганча, солтан Абделхәмид үзен бөтен дөнья

[1] Корьәнне тилявәт итү – Корьәнне бөтен шартларын китереп, көйләп уку (тәрҗ. иск.)
[2] Лодз – Польшада бер шәһәр (тәрҗ. иск.)

Яңа бистәдәге мәчет. Омск. XX гасыр башы

Шәһәргә керү капкасы. Омск. XX гасыр башы

Вокзал. Омск. XX гасыр башы

мөселманнарының хәлифәсе дип игълан итте. Безнең Лодзда[2] бер төрек бар, бик бай кеше. Ара-тирә күрешеп сөйләшә торган идек. Сүз җае килгән саен: «Безнең мөселманнар 400000000 кеше!» – дип горурлана, мактана иде. Ничек инде Сез бу кадәр салкын канлылык күрсәтә аласыз? Сезгә карап аптыраашта калдым.

– Гафу итегез! – дип сүз башладым. – Сез Лодз шәһәреннән, димәк. Сезнең төрек дустыгыз да Лодзда яши, дисез. Лодз исә – Аврупаның үзәгендә урнашкан әһәмиятле җир. Мин дә Лодзда яшәсәм, ихтимал, Сезнең кебек үк сәяси мәсьәләләр белән шөгыльләнер һәм фикерегезгә дә кушылган булыр идем. Тик мин себер татарымын, безнең мәмләкәткә почта атнага бер тапкыр килә, башкала газеталары безгә килеп җиткәндә инде 15-20 көнгә соңарган булалар. Шулай булгач, мәсьәлә чынбарлыкта ничек кенә мөһим булса да, безгә килеп ирешкәнче, аның әһәмияте бермә-бер кими, чөнки хәбәре ул булып беткәннән соң гына килеп җитә. Мондый тиз арада булган вакыйгалар турында вакытында хәбәр алу түгел, әле безнең авыл агайлары айлар буе барган Япон сугышы турында да булып беткәннән соң гына ишеттеләр.

– Мин Сезнең бу кадәр дә «күрмәдем, белмим», диюегезгә тора-торып гаҗәпләнәм. Бигрәк тә бу, бүгенге Төркия мәсьәләсе – Шәрык мәсьәләсе дигән сүз – бөтен мөселманнар өчен яшәү мәсьәләсе. Алай булгач, Сезнең карашыгызда, яшәү һәм үлем бертигез, ахрысы? Шәхси фикере булган кешеләр өчен Сезнең бу вазгыятегез шаккаткыч. Бу сүзләрегез, һичшиксез, мин өмет иткән сүзләр түгел һәм Төркия инкыйлабыннан да сәеррәк. Тик әле генә башыма килде: Сез, мөгаен, саклык йөзеннән минем белән болай сөйләшәсездер. Менә хәзер мин инде үтенергә мәҗбүр булам: зинһар өчен, мине шпионлыкта гаепләмәгез, андый кимсетүне кабул итә алмаячакмын. Мин – сәүдәгәр улы сәүдәгәрмен. Шулай булса да, бөтен дөньяның фикерен мәшгуль иткән Төркия инкыйлабы һәм Аврупа дәүләтләренең моңа начар ка-

рашлары минем җаныма тынгы бирми. Шуңа да, икеләнмичә, ышанып әйтә алам: Сез бу мәсьәлә белән миннән артыграк кызыксынасыз, – дигәннән соң, сүзен шулай дәваам итте: – Мине, ә бәлки бөтен кешенедер, гаҗәпләндерә торган бернәрсә бар: Шәрыктә күзәтелгән шаккатыргыч хәлләр. Беренчедән, Төркия инкыйлабының тизлеге. Бер тамчы кан коймыйча, ягъни берәүнең дә хәтта борыны гына да канамыйча, тиранлыкны тамырыннан йолкып ату аз нәрсә түгел. 30 ел буе дәвам иткән бу дәһшәтле көчкә каршы торып, бер төркем кеше мәйданга чыга һәм шул рәвешле инкыйлаб ясала. Бу – дөресен генә әйтик, кеше әйтеп, кеше ышанмаслык хәл. Икенчедән, Аҗәм илендә (Иран) буталчыклыклар инде еллар буе дәвам итә. Дөресен генә әйткәндә, мондый ныклык Шәрыккә хас нәрсә булса кирәк, шулай ал кан эчендә каршылык, ныклык күрсәтү бөтен милләтләрнең дә кулыннан килә торган эш түгел. Безнең Русиядә әнә ике-өч ай акырыштылар-бакырыштылар да, хөкүмәтнең көчен күрүгә тындылар, һәммәсе дә сүзсез калуны өстенрәк күрде.

– Сезнең фикерегезгә һәр ике мәсьәләдә дә кушыла алмыйм. Төркия инкыйлабының кыска вакыт эчендә башкарылуы төрекләрнең сәләтенә бәйле түгел. Киресенчә, бу инкыйлабка Ревальᶾ киңәшмәсенең йогынтысы күбрәк хезмәт иткән булырга мөмкин. Моннан тыш, Русия һәм Англиянең нотасы[4] солтан Абделхәмидне дә уйланырга мәҗбүр иткәндер. Бүгенге көндә комитет – хөкүмәткә, хөкүмәт исә комитетка әйләнде булса кирәк. Тиз генә үзара берләшеп, Реваль карарын юкка чыгара алырлар, тик барыбер Аврупа сәясәтчеләренең фикере үзгәрмәс, – дидем дә сүземне түбәндәгечә дәвам иттем: – Аҗәм иле мәсьәләсенә килсәк, ул да – Русия-Англия сәясәтенең нәтиҗәсе. Ил һәм халык кан дәрьясына батты. Әгәр анда золым, газап булмаса, мондый вәхшәткә юл куелмас иде.

Күршем тәнкыйть иткән кебек болай диде:

– Сез сәясәт белән шөгыльләнергә һәвәс түгеллегегезне әйткән идегез, инде ап-ачык итеп, шәхси фикергә ия булуыгызны белдерәсез. Тик мин, Төркия мәсьәләсенә Шәрык мәсьәләсеннән чыгып карамаганга, иртәме-соңмы, Төркиядә сугыш кабынып китеп, ул шул сугышта җимичә торып, үз кадер-хөрмәтен саклап калуга ирешә алмаячак, дигән фикердә торам.

– Төркия греклар белән булган соңгы сугышта зур җиү казанды, ләкин аңа кадер-хөрмәтен сакларга ирек бирмәделәр. Төркия әгәр үзен Аврупалыларга чын-чынлап танытырга теләсә, тәре һәм ярымай сугышы булачак, – дидем.

Күршем, көлеп, болай диде:

– XX гасыр цивилизациясе! Ха-ха-ха!

– Мөселманнар кыргый ла, тәрегә каршы барулары бик ихтимал! Тик менә Аврупалылар ул җирләргә кадәр китмәсләр, дип уйлыйм, – дидем.

– 3 нче октябрьдә Мәскәүдә Октябрист партиясе әгъзалары җыелышларында генерал Комаровский, Шамшовлар тарафыннан белдерелгән фикерләрне игътибарга алсак, коралга тотынмаслар да бәлки, ләкин уй-фикерләре белән тәре сугышына таба хәрәкәт итүләре аңлашыла. Әйе, егерменче гасыр цивилизациясеннән барын да көтәргә мөмкин.

Шул арада поезд бер станциягә килеп җитте. Карадым: бу Чулым станциясе икән. Кич җитеп килгәнгә, мин, чәй пешереп эчәр өчен, кайнар су алдым. Юлдашым кичке аш ашарга дип китте.

*Төрекчәдән **Асия Рәхимова** тәрҗемәсе.* ■

[3] Реваль – Таллин шәһәренеңСкандинавия халкы һәм немецлар тарафыннан кулланылган иске исеме. Руслар Ревель дип әйткәннәр. (тәрҗ. иск.)

[4] Нота – бер дәүләт тарафыннан икенче дәүләткә нинди дә булса дөньякүләм мөһим вакыйга белән бәйле рәвештә җибәрелгән хат. (тәрҗ. иск.)

«Таҗеддин Ялчыгол». Рушан Шәмсетдинов рәсеме

ТАҖЕДДИН ЯЛЧЫГОЛ

(Шул исемдәге әсәрдән өзек)

Рөстәм Галиуллин

– Мин, Таҗеддин Ялчыгол улы, илле җиде яшьтәмен. Бөгелмә өязенең Чалпы авылында туганмын...

–Тәк! – Кара чалбардан, шинельдән, башына күн картуз кигән тар җилкәле, түгәрәк кечкенә башлы өтек кенә Казанцев – дворяннар утырышчысы – түзмәде: урыныннан торды да бүлмә буйлап әрле-бирле йөренергә тотынды. Олпат гәүдәле, ак күлмәктән, яңа җиләннән, башына түбәтәй кигән Таҗеддин хәзрәтнең үзен тыныч тотуы, күзгә туры карап сөйләшүе, ни гаҗәп, аның күңелендә болытлар куерта иде. Юкса, киресенчә булырга тиеш түгелме соң? Шикаятьне бит Казанцев өстеннән түгел, менә бу хәсрәт хәзрәт өстеннән язганнар! Ул исә, утыра әнә, һич югы, башын түбән исен иде бераз!

Казанцев, бүлмәсенең буен-аркылысын үлчәгәндәй, тагын бер йөренеп алды. Бу алымы, гадәттә, бик еш «ата» иде аның: аркалы урындыкта артык горур утыручыларның да сабыр касәсе түкәнеп, бик еш телләре ачыла иде.

Таҗеддин хәзрәтнең исә Казанцевта эше юк: кечкенә башына авыр кибән бастырып куйгандай күренгән картузына күзе төшүгә үк, аны чебен гөмбәсенә охшаткан иде, түгәрәк кара күзенең йөгереклеген күргәч исә, бу дворяннар утырышчысы белән булачак мизгелләрнең мәгънәле үтмәячәген, борчаклары пешмәслеген чамалады. Мондыйлар, гадәттә, дөньяга ачулы була. Инде рәсми өстенлек аның ягында булып, хөкүмәт кешесе дә саналгач, утырып торган кеше янында баскан килеш булса да өстән карарга тырышачак!

Казанцев, әллә кайчаннан бирле сагалаган чыпчыгы җиргә кунгач, аның янына атылган мәче җитезлеге белән, күтәртеп куелган урындыгына килеп чүмәште.

– Бу сөйләшүнең Минзәлә земство суды тәкъдиме белән уздырылуын аңлаттым. Шуңа күрә җавабың төгәл булсын! Шылдымы? – Ул, аннан-моннан йолкынгандай сыек кашын кабартырга тырышып, күзен чекерәйтеп Таҗеддин хәзрәткә карады һәм шул мизгелдә үк карашын читкә күчерде. Казанцев канәгатьсезлек белән йөзен җыерды һәм каләмен карага манып алды да Таҗеддин хәзрәтнең бая әйткән җөмләсен кәгазьгә төшерде.

– Өстеңнән шикаять бар, – диде Казанцев язудан туктап, шактый эшлекле төстә. Кыяфәтенә җитди төсмер чыгарырга тырышты ул. Бар булмышы белән Таҗеддин хәзрәтнең язмышын хәл итүче түрә итеп күрсәтергә тырышты үзен.

Таҗеддин хәзрәт тыштан тыныч булса да, эчтән борчылырлыгы юк түгел иде. Йөз чакрымнан артык юл үтеп, Минзәлә кадәр Минзәләгә чакырулары шикләндерә. Таң атканчы ук юлга кузгалып, көч-хәл белән килеп җитте ул. Әле Кызыл Чапчакка кайтып җиткәнче тагын ярты тәүлек юл узасы бар. Күңелдә купкан дулкыннар шавын бары шунысы баса: Таҗеддиннең бер генә гаебе дә юк. Күрше-тирә авылларның берсендәге мәхәллә халкы сөймәгән, әмма үзе дан-шөһрәт яратып, шуңа мохтаҗ хөсетле мулла-мунтагай эшедер, мөгаен.

– Ай-һай, Таҗеддин хәзрәт, синең вәгазьләреңнән соң каз тәне чыга. Бер сүзеңне дә калдырмый, кем әйткәндәй, керфегемне дә какмый тыңлыйм, мәчеттән чыкканда чәч төпләремә хәтле юпь-юеш була, – дигән иде аңа бервакыт Нугайбәкнең улы

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

Хөрмәкәй кантун. Ул кайчак җомга намазларына Кызыл Чапчак мәчетенә килеп чыга, аның чакыруы буенча, Таҗеддин хәзрәтнең дә Чалпы белән Урсайдагы Аллаһ йортларына килгәне бар. Ул вакытта Таҗеддин хәзрәт Чалпы мәчетенә барган иде.

– Мәчеттә һава тынчурак иде, тирләткәндер, – дип шаяртты аны Таҗеддин хәзрәт.

– Хикмәт анда түгел! – Хөрмәкәй кантун бармак янады. – Синең сүзләрең шулай көйдерә. Әтидән шундый сүзләр ишеткән саен җаным урынымнан куба иде. Хәзер менә син вәгазьләрең белән тынычлыгымны алдың. Ирләрнең яше-карты авыз ачып тыңлый бит үзеңне, хәтта сулыш алганың да сизелми. Тагын шунысы яхшы: һәрнәрсәне крәстиян аңларлык итеп төшендерәсең. Инде сиздерми-нитми генә үз дәүләтебез булган заманнарга күчкәч, аркадан шабырдап тир ага башлый. Даның бик ерак китте, хәзрәт! Көнче күбәләк мулла-мунтагайлар башыңны ашамасыннар иде, дим! Атам Нугайбәк сиңа терәк булырга, ни булса да якларга, янәшәңдә торырга васыять әйтте!..

– Ни өчен син... – Казанцевның нечкә сыек тавышы Таҗеддин хәзрәтне кабаттан кояш нурлары яктысында тузан бөртекләре биешкән кечкенә бүлмәгә кайтарды. – Ни өчен син... – Казанцев кирәкле сүзен таба алмый изалана иде. – Тәк! Тәртип буенча җавап бир! Вазыйфаң нидән гыйбарәт?

– Кызыл Чапчак авылы мәчетендә имам һәм өлкән мөдәррис булып торам.

– Хөкем ителгәнең булдымы?

– Юк, беркайчан да хөкем ителгәнем булмады.

– Авылдан кайларга барып йөрисең?

– Күп вакытым Кызыл Чапчакта үтә.

– Башка җирләрдә, әйтик, Чалпыда нишләп йөрдең?

«Имәндә икән чикләвек!» – дип уйлап куйды Таҗеддин хәзрәт.

Казанцевның кечкенә түгәрәк кара күзләре сызыкка калды. Хәзер алар, шатлыктандыр, күрәмсең, сумала сылагандай чем-кара, өстәвенә, шөкатьсез ялтырыйлар иде.

– Мин Чалпы авылына уникенче кантон хуҗасы Хөрмәкәй Нугайбәк улы чакыруы буенча килдем.

– Ни өчен чакырды инде ул сине – Кызыл Чапчак мулласын? – Казанцевның кырыла башлаган кәефе күзгә күренеп рәтләнә төште. Инде күн итекле аягын өстәлгә куеп сөйләшкәнен үзе дә сизми бугай.

– Мин анда вафат булган кешеләрне тиешенчә җирләүдә ярдәм итәр өчен бардым.

– Күпме булдың?

– Өч ай саен барам.

– Чалпыда кайда яшәдең?

– Хөрмәкәй кантун йортында.

– Күпме вакыт тора идең?

– Якынча ике атна..

– Тәк!.. – Казанцевның кыска аяклары кабаттан идәнгә төште. Ул күзен кәгазь буйлап йөгертте – укыганы аның күңелендә канәгатьләнү хисе тудырмады булса кирәк – ач яңаклары уйнаштыргалап алды.

– Ни өчен сине чакыра әле ул Хөрмәкәй кантун? Үз авылында мулла юкмы?

– Мин Чалпы авылында тудым, дип әйткән идем. Хөрмәкәйне күптән беләм...

– Бу берни дә сөйләми. Аның әтисе Нугайбәк старшина белән таныш идеңме син?

– Әйе, таныш идем.

– Аның Пугачев полковнигы икәнен беләидеңме?

– Юк, белми идем. Без ул чакта әтием Ялчыгол белән хаҗ сәфәрендә идек. – Аллаһ Тәгалә үзе ярлыкасын, Таҗеддин хәзрәт ялганга күчәргә мәҗбүр иде.

– Тәк!.. Менә монда гаҗәп хәлләр бар! – Казанцевның тузан кунган күн итеге кабаттан өстәлгә күтәрелде. – Ни өчен нәкъ менә фетнә вакытында хаҗга чыгып киттек икән?

– Минем атам Ялчыгол хәзрәт, урыны оҗмахның түрләреннән булсын, аңа кадәр үк сигез тапкыр хаҗда булган изге зат иде. Тугызынчы сәфәргә ул берничә ел әзерләнде, безнең хаҗ кылуыбызның фетнәгә бернинди дә катнашы юк.

– Ни өчен ул кире Чалпыга кайтмады? – Казанцев, башын кыегайтып, горур кыяфәттә утыра, инде үзен җиңүче саный, әйтерсең, мәче тырнагына эләккән чыпчыкның соңгы тыпырчынуын ләззәтләнеп күзәтә.

– Ул нәкъ менә Чалпыга кайтып килгәндә, юлда вафат булды.

– Тәк!.. – Казанцев, аякларын янә төшереп, ишеткәннәрен үзенчә язып куйды. Бераздан эшен тәмамлады, кәефе кабат кырылган иде, төксе генә сорап куйды: – Хаҗ сәфәре күпме вакытка сузыла?

– Аның төгәл вакыты юк. Һәркемнеке үзенчә була.

– Сезнеке күпме булды?

– Ун елдан артык...

– Ун елдан артык? Тәк!..

Казанцев, түзмәде, торып басты да, кабаттан кыска адымнары белән әрле-бирле йөренә башлады.

– Төгәл әйтсәк? – ул Таҗеддин хәзрәт утырган урындыкның аркасына таянды.

– Унөч елдан артык...

– Унөч елдан артык?! Ай-яй!

Казанцев тагын өстәл янына йөгереп килде дә каләм алды.

– Ни эшләп йөрде инде шул гомер ата белән ул хаҗ сәфәрендә?

– Әтинең бу соңгы сәфәре бик авырга туры килде. Юлда акчабыз бетеп, Дагыстан якларында берничә ел балалар укытып, мая юнәтергә мәҗбүр булдык.

– Шуннан?

– Аннан хаҗ сәфәрендә атам хастага калды.

– Шуннан?

– Берничә ел Госманлы мәмләкәтендә яшәдек, әти аягына баскач, илгә кайттык.

–Нинди акчага яшәдегез?

– Балалар укыттым, – Таҗеддин хәзрәт шик-шөбһә тудырмый торганрак җавапларны эзләргә тырышты.

– Тәк!.. – Казанцев тагын ак кәгазьне буяп алды. – Шикаятьтә әтиеңнең Пугачев яклы булуын язганнар. Нугайбәк Хәсәнов белән халыкны ияртүчеләр, дигәннәр... – дворяннар утырышчысы, кылычы белән соңгы тапкыр селтәнгән яугир сыман, Таҗеддин хәзрәткә текәлде.

– Анысын шикаять язучы дәлилләсен. Булмаган нәрсәләр турында әйтә алмыйм. Ул чакта без сәфәрдә идек.

Казанцевның йөзе караңгыланды. Бу тәкәббер имамнан туйды ул, карашын бер ноктага төбәгән дә утыра, юньсез! Эченнән генә аты-юлы белән сүгенеп алды: шулкадәр тырышуының нәтиҗәсе күренмәде бит. Хәзер кайтарып җибәреп, янәдән шикаятьләр өстәп, йөз чакрымлык юлда тинтерәтеп йөртеп алҗытсаң – теле чишеләр иде дә. Хөрмәкәй Нугайбәков, ул иң укымышлы мулла, галим, үзе табиб та әле,

данынннан көнлиләр, шикаятьләргә игътибар бирмәгез, тынычлыкта калдырыгыз, дип кисәтте аны.

«Хөрмәкәй кантун!» – Шушы исемне эченнән атау белән, Казанцевның күңелендә тагын икеләнүле уйлар кыбырсып куйды. Бу уникенче кантун хуҗасын үзен дә тимер рәшәткә артына утыртып куйсаң шәп булыр иде! Сөйми аны Казанцев, гомумән, ул килеш-килбәте матур, олпат гәүдәле, акыллы кешеләрне өнәми. Өстәвенә, бу Хөрмәкәе, татар гына булса да, өяздә әллә кем булып йөри. Өяз хуҗасына да теләгән вакытында керә ала, дигән булалар үзен, шуңа, сөймәсә дә, аңа кагылып булмый иде.

– Табиб булып йөри, дигәннәр шикаятьтә, әүлия дип йөртәләр икән үзеңне... – Казанцевның тавышы дөньяга өмете сүнгән кешенеке сыман тонык чыкты.– Кайдан килә бу?

– Беренчедән, атам да кешеләрне дәвалый иде. Аннары, Госманлы мәмләкәтендә чакта серләренә төшендем. Андагы мәдрәсәләрдә табиблыкка да өйрәтәләр.

– Җомга намазында, Чалпыда чакта, безгә үз дәүләтебезне кайтарырга кирәк, дигәнсең... Кызыл Чапчактагы мәчетеңдә дә һәр җомга намазы саен: «Без кайчандыр дөньяда иң алга киткән дәүләтле халык булганбыз. Шуңа да телебезне, динебезне җуймыйча сакларга, Аллаһ Тәгаләдән әмер булу белән, яңадан үз көнебезгә үзебез хуҗа булып яши башларга тиешбез», – дип әйтәсең икән.

– Мин андый сүзләр әйтмәдем. Бу – нахак гаеп, яла ягу...

Госманлы мәмләкәтенә күчеп, төрле гаепләүләр тагарга җирлек бар иде барын, әмма Казанцев бу горур имамнан тәмам туйды. «Тизрәк котылырга моннан!» – дип уйлады ул эченнән генә. Бу сөйләшү аңа берни бирмәде. Файда турында әйткән дә юк, ичмасам, рухи бер рәхәтлек тә кичерә алмады. Гадәттә, аның яклавын сорап, тезләнәләр, аягын үбәләр иде. Һич югы, елап җибәрә, юньлесе акча сонар иде кулына. Ә бу?! Моннан берсе дә юк!

– Тәк!.. Сөйләшү тәмам. Әлегә кайтып тор. – Ул аңа кәгазь сонды. – Менә монда тамгаңны куй.

Таҗеддин хәзрәт кесәсеннән «Таҗеддин Ялчыгол улы» дигән кара төстәге шәхси мөһерен чыгарды. Аны күргәч, Казанцевның болай да төкәнгән сабырлыгы бөтенләй бетте:

– Кире тык кесәңә! Үз кулың белән төшер!

Таҗеддин хәзрәт аның боерыгын карышмый үтәде һәм эре-эре атлап чыгып китте.

Ул күздән югалуга, Казанцев бар ачуын сүгенеп түкте. Юк, кире чакырмаячак аны Казанцев! Бу мулланы аның күрәсе дә килми! Әмма шикаятьчеләрне кисәтәчәк: күзәтсеннәр үзен, алай-болай тагын вәгазьләрендә батырайса, шундук хәбәр юлласыннар!

– Аннары!.. – ниһаять, болай да ач яңагы тәмам суырылган Казанцевның битенә сыек кына алсулык йөгерде. – Бу мулланы авылыннан кудыртырга, башка җиргә олактырырга кирәк. Түрәләр янында үзен ничек тотасын белер шуннан соң!

...Таҗеддин хәзрәт бинадан чыгуга, янына улы Җәлаледдин килеп басты. Аның борчу катыш кызыксынулы карашыннан Таҗеддин хәзрәтнең күңеле булды:

– Хәл-әхвәлләрне белештек, улым. Сәламәтлегемне сораштылар... – Таҗеддин хәзрәт, гадәтенчә, шаяртуга күчте.

– Шулай да, әти...

– Нәрсә дисеннәр инде, улым, үлгәнче яшә, үзеңчә эшлә, диделәр! Кайда атың?

– Тугайда, тугарган идем.

– Әйдә, юлга кузгалыйк, төнлә берәрсендә кунарбыз.

Алар Минзәлә урамы буйлап атладылар, Таҗеддин хәзрәт, артка каерылып, ко-яшка карады: ай-һай, шушы мәгънәсез очрашу сәгать ярымлап вакытын алган икән!

Җәлаледдин, гадәттә сүзчән этисенең бу юлы сөйләшергә теләмәвен сизенеп, башка сорау биреп йөдәтмәде. Алар сүзсез генә тугайга атлап, атны җиктеләр дә кайтыр юлга кузгалдылар.

Арбага уңайлап утыруга ук, Таҗеддин хәзрәтнең күңелен әллә нинди сәер хисләр биләп алды. Ни хикмәттер, Таҗеддин хәзрәт, сәфәр чыга икән, үзен башка дөньяга килеп эләккәндәй хис итә башлый. Менә хәзер дә Җәлаледдин улы белән икесе башка дөньяга күчкәннәр сыман тоелды. Әйтерсең лә Җәлаледдин урынында Таҗеддинның яшь чагы, Таҗеддин хәзрәт үзе Ялчыгол хаҗидыр кебек. Ул, улының киң җилкәсенә карап сокланды. Бу икенче малае Җәлаледдин аның эшен дәвам итүче булыр сыман. Каләм-карага да кулы ятып тора, гыйлемгә дә хирыс. Бик тә, бик тә үзенең яшь чагын хәтерләтә бу егет!..

Таҗеддин хәзрәт тирә-юньгә күз салды: инде җиһан көз фасылына күчеп маташа – баксаң, унөченче август та җиткән ләбаса! Әнә, табигатьтәге ачык яшеллекнең эзе дә калмаган, каеннарның да күкрәп торган хуш исле яфраклары әле кайчан гына куе яшел төстә иде, инде менә сары ягыла башлаган үзләренә, агачларның ботаклары тәмам җиргә салынган – әйтерсең лә яшелле-сарылы шәлләре шуып төшеп бара...

– Һай, гомерләр! – дип куйды Таҗеддин хәзрәт авыз эченннән генә. – Инде милади белән мең сигез йөз дә егерменче ел җиткән.

Әле кайчан гына егет вакытында сәфәр арты сәфәр йөргән Таҗеддин хәзрәтнең дә сакалы агарып, чәче көмеш төсенә керде. Инде ул белгән кемнәр исән, кемнәр юк, дигәндәй... Гомер тиз үтә – сизми дә каласың, диләр иде – хак сүзләр булып чыкты. Тик менә тиешенчә яшәлдеме ул гомер? Таҗеддин хәзрәт атасы Ялчыгол хаҗиның сүзләрен исенә төшерде:

– Мин сиңа Таҗеддин дип юкка гына исем бирмәдем, улым. Диннең таҗы мәгънәсендә ул! – дигән иде.

Аның васыятьләрен үтәдеме Таҗеддин хәзрәт?

Ат басу юлы буйлап тузан кубарып чаба. Әнә шул тузан пәрәвезе Таҗеддин хәзрәтнең уйларын тәмам тузгытып ташлады – йокымсыраган хәзрәт, сискәнеп, күзен ачты: әллә өнендә, әллә уенда ул мең җиде йөз дә туксан икенче елның җаенә әйләнеп кайтты. Әнә, иркенгә чыгып кушаяклап чабарга тырышкан карт алаша – алмачуар ат түгел, Нугайбәк абзасының туры кара айгыры бугай; дилбегәне кагыштыргалап баручы – Җәлаледдин түгел, Нугайбәк абзасының кече улы иде; ак күлмәкле, яңа җиләнлесе дә абруйлы Таҗеддин хәзрәт түгел, Нугайбәк абыйсы белән хушлашып, аның хәер-фатихасын алып, Татар Җиреклесе авылына юл чыккан егерме тугыз яшьлек Таҗеддин иде...

Карт алаша тоягыннан күтәрелгән тузан, бөтерелеп, куерганнан-куерды, йомшак эздән тәгәрәгән тәгәрмәчләр, шалтыраудан туктап, көйле генә келтериләр иде... ■

«Тау бөркете буласым килде!..»

Шаһинур Мостафин

Һади Такташ хатыны Гөлчәһрә Хәмзина һәм уллары Рафаил белән. 1927 ел

Татар әдәбиятының олуг әдибе Һади Такташның бер гасырлык юбилее республикабыз башкаласында киң колач белән билгеләп үтәлде. Анда, кадерле кунаклар сыйфатында, Мордовиядән килгән абруйлы делегация дә катнашты.

Язмышыма тагын бер мәртәбә рәхмәт әйтәсем килә: ул мине тантаналы шул көннәрдә атаклы әтисенең юбилеена килгән Рафаил ага Такташ белән якыннан таныштырды, дуслаштырды. Татарстан Язучылар берлегенең ул вакыттагы рәисе Фоат ага Галимуллин Ташкенттан килгән хөрмәтле кунагыбыз – күренекле рәссам, сәнгать фәннәре докторы, профессор-мөгаллим, Үзбәкстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Үзбәкстанның Сәнгать академиясе әгъзасы Рафаил Һади улын озатып йөрү, башкалабыз белән таныштыру бурычын миңа йөкләде. Без мөхтәрәм аксакал белән аның әтисе җирләнгән М.Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркындагы туганнар каберлегендә дә булдык. Ул аннан, изге ядкәр итеп, кабер туфрагын да алды...

***

Гәрчә әнисе – Гөлчәһрә Хафиз кызы (1909-1957) ире Һади Хәйрулла улы белән аерылышса да, нәни Рафаил һәрвакыт әтисен сагынып яши. Шагыйрь дә үзенең улын бик юксына, рәсемен гел күкрәк кесәсендә йөртә. 1929 елның 7 августында язган «Руфик» исемле шигырендә, малаена мөрәҗәгать итеп, ул болай ди:

«Син беләсең, Руфик,
Беркем мине сагынып еламас,
Синнән башка беркем... беркем...
Күз яшь белән:
– Папа кайда? – диеп сорамас...»

Һади Хәйрулла улының 1930 елның 14 октябрендә «Рафаил Такташевка» дип адресланган хатын да дулкынланмыйча, рухи тетрәнмичә генә уку һич мөмкин түгел. Биредә шул хатны укучыларыбыз игътибарына да тәкъдим итәбез:

«...Рафаилгә үзенә укырга гына хат яза алмыйм. Шуның өчен миңа бик авыр. Еракта үзен сагынучы, өзелеп сагынучы атасы барын һәм аның бик сагынуын кем булса да аңарга аңлата алырмы? Күптән инде аның «папа» дигән сүзен ишеткәнем юк. Миңа бик авыр. Ул, бәлки инде, ул сүзне әйтергә дә оныткандыр. Ә аның тавышы һаман минем колагымда. Рәсеме һаман йөрәгемдә булуын ул әле аңлау дәрәҗәсенә җитмәгәнгә, йөрәгемне авыр сагыш тойгылары каплый.

Хатым аңар җылы хисләремне алып бара алсын иде.

Бер генә минутка ул минем яратуымны, өзелеп сагынуымны хис итә алсын иде.

Ерактан күрә алмыйм.
Бәхетсез минутларында
янында булалмыйм.
Ул шуны аңласын иде.
Кайчан күрә алырмын?
Күрә алырмынмы?
Аңар Казанда икәнемне әйтегез!

Сагынуымны аңлатырга тырышыгыз. Үземнең сәламәтлегемне, эшнең бик күп булуын, тиздән, бәлки, Казаннан Донбасска бер алты айга китәргә җыенуымны әйтегез!

Тизрәк үссен! Минем хатларымны укыр дәрәҗәгә җитсен!

Күз яшьләрем белән язган юлларымны үбәм. Хатымны укый алмаса да, кулына бирегез. Өзгәләсә дә, идәнгә таптаса да...»

Гарәп графикасында язылган әлеге ачык хат-открытка хәзер Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты каршындагы Кулъязмалар, фәнни һәм архив бүлеге мирасханәсенең Һ.Такташ фондында саклана.

Ил агасы Рафаил Һади улы белән без, Ташкентка кайтып киткәч тә, шактый вакыт үзара хатлар алышып тордык. Миңа ул үзенең русча язылган шигырьләрен дә җибәргән иде. Аларны «Казань», «Идель» журналларына (русча басмаларына) тәкъдим иттем...

Еллар үткәч, Рафаил ага Такташның «Избранные стихотворения» дигән исем астында 2006 елда Ташкентта чыккан беренче мөстәкыйль шигырьләр җыентыгы белән танышу бәхетенә дә ирештем. Әлеге китап Үзбәкстан Сәнгать академиясе академигы, атказанган сәнгать эшлеклесе, К.Бехзода исемендәге Милли сәнгать һәм дизайн институты профессоры Рафаил Һади улының 80 яшьлек күркәм юбилее уңаеннан нәшер ителгән икән. Атаклы рәссам-график һәм сәнгать белгеченең култамгалы (автографлы) тезмә әсәрләре тупланмасын миңа А.Н.Туполев исемендәге Казан милли-тикшеренү техник университеты (элекке КАИ) профессоры, икътисад фәннәре докторы, Россия Гуманитар фәннәр академиясе академигы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, шәрәфле язучы Рауза Кадыйр кызы Мәҗитова укырга биреп торган иде. Заманында алар – Рафаил ага Такташ исән чакта – үзара хәбәрләшеп яшәгәннәр. Хөрмәтле Рауза ханымның әнисе – Оркыя Галләметдин кызы заманында Һади Такташның энесе Габидулла һәм Муса Җәлил белән бергә Казан университеты каршындагы Татрабфакта укыган. Һади Хәйрулла улы үзе дә бирегә еш килеп йөргән; мөгаллимнәргә, студентларга һәм каләмдәш-рухташларына яңа шигырьләрен, поэмаларын укыган, иҗат кичәләрендә даими катнашкан. Әнисенең Такташка, Җәлилгә, гомумән, әдәбият-сәнгать әһелләренә карата ихлас мәхәббәте, сокланулы хисләре,

геннар аша, Рауза Кадыйр кызына да күчкән. Шуңа күрә дә ул Рафаил Һади улы белән бик теләп хатлар алышып торган. Күренекле рәссам-шагыйрь дә үзенең шигырьләр китабын, Татарстанда яшәүче дусларын барлаганда, иң беренчеләрдән булып күренекле галимә-әдибә Рауза ханым Мәҗитовага бүләк иткән. Самими-садә хисләрен чагылдырып, ошбу мәҗмугага, русча-татарча сүзләрне сайлап, болай дип язган ул: *«Дорогой и глубокоуважаемой Раузе Кадыровне Мазитовой с большой благодарностью за Вашу щедрость и уважение к моему отцу!*

Исән-сау булыгыз һәрдаим!
Зур ихтирам белән,автор:
Раф. Такташ. 2007, XII.»

Хөрмәтле Рауза ханым белән нурлыҗырлы фатирларында үзара сөйләшеп утырганда, ул, мөхтәрәм Рафаил аганың шигырьләр китабын кулларына алып: «Менә бу хикмәтле шигъриятне үзебезнең телдә – татарча да яңгыратасы иде! – дип әйтеп куйды. – Белсеннәр иде милләттәшләребез Һади Такташның гаҗәеп талантлы шагыйрь улы да барлыгын!»

Аның сүзләрен бирегә кунакка – галимә каләмдәшенең хәл-әхвәлен белергә килгән ихлас күңелле тагын бер әңгәмәдәшебез – тарих фәннәре кандидаты, татар хатын-кызларына, гыйбрәтле язмышларга багышланган берничә китап авторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Тәэминә ханым Биктимирова да бик хуплады. Икесе дә чын милләтпәрвәр шәхесләрдән саналган әлеге асыл затларның уртак фикерен белгәч, аларга Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының һәм Язучылар берлегенең Һ.Такташ исемендәге премиясе лауреаты, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе Рашат Низамиев кандидатурасын тәрҗемәче сыйфатында тәкъдим иттем.

Менә шул каләмдәш дустыбыз, изге теләгебезне үзе дә куәтләп, Рафаил ага Такташ шигырьләрен тәрҗемә итәргә алынды. Аннары рәссам-шагыйрь якташыбызның иҗат үрнәкләрен республикабызда чыгучы газета-журнал битләре аша да киң яктыртты ул.

Хәзер исә үзен «бунтарь йөрәкле, чабаталы даһи» дип атаган Һади Такташны тагын бер мәртәбә зурлап искә алып, аның лаеклы дәвамчысы-варисы булган Рафаил Һади улының татарча яңгыраштагы сайланма шигырьләрен «Безнең мирас» журналы укучылары игътибарына тәкъдим итәбез.

Биредә урнаштырылган фоторәсемнәрне Рафаил Такташның 2006 елда Ташкентта дөнья күргән китабыннан, Һади Такташның 2010 елда Казанда басылып чыккан томлыкларыннан, нәшер иткән басмаханәләреннән рөхсәт алып, файдаландык. Безнең игелекле башлангычыбызга – Рафаил Такташ шигырьләрен татарча аерым китап итеп бастырып чыгаруда һәм журналга әзерләүдә булышкан, хәерхаһлы булган һәр кешегә ихлас рәхмәтебезне җиткерәбез.

Хөрмәтле Рауза ханым Мәҗитова исә үзе туплаган-әзерләгән әлеге китапның һәм журналда басылган шигырьләрнең Һ.Такташ иҗатына гомере буена гашыйк булган сөекле әнисе Оркыя Галләметдин кызы Мостафинаның, этилеуллы Һади һәм Рафаил Такташларның якты рухларына изге бер дога рәвешендә барып ирешүен теләп кала.

РЕДАКЦИЯДӘН: *Республикабызның Мамадыш төбәгендә туып-үскән әдәбият-сәнгать әһелләре арасыннан иң беренче булып, әлеге борынгы, әмма елдан-ел яшәрә-матурлана баручы каланың* ***шәрәфле гражданины*** *исеменә быел тынгысыз җанлы эзтабар язучы һәм шагыйрь — Казандагы «Сүз» китап нәшриятының баш мөхәррире Шаһинур Мостафин лаек булды. Мөхтәрәм авторыбызны әлеге мәртәбәле исем белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары теләп калабыз!*

Рафаил Такташ
(1926-2008)

ӘЙ, ЯЗМЫШЫМ!..
(Шигырьләр)

«Балачак дәфтәре»ннән

Тау бөркете буласым килде! –
Очкан шәпкә уктай атылам:
Дошманны һәм вакытны җим(е)рәм,
Куып җитеп еллар артыннан!

Тыңла мине, таулар илчесе,
Яшел үзәннәрнең патшасы!
Җил-давылга каршы очу – бәхет,
Бөркет була алсам, һай, яхшы...

Үлсәм иде көрәш кырларында –
Югалткачтын актык көчемне...
...Кан чыгармый гына, бөркет сыман,
Син дә, дускай, үлмәс идеңме?!.

Фирганә. 1939 ел

***

Төнбоектай ак чәчкә син
Саташкан инешемдә.
Сөттәй ак юллар юрыйсың
Өнемдә һәм төшемдә.

Шигырь утым сүрелмәстер –
Мин бит океанга охшаш:
Күңелемнең төпкеленнән
Сүзләр чәчри – чуерташ!

Син – Җир кызы, охшагансың
Фәкать, фәкать үзеңә.
Лалә гөл сыман балкыйсың –
Түз, йөрәгем, түз генә!

Тау чаклы эшләр башкарам –
Үземә каратырга.
Ләкин әүвәл мин тиешмен
Тик сине яратырга!..

Ленинград. 1951 ел

***

Тормыштагы ике ямьне күңелем
Истә калсын өчен яраткан:
Күлдә су керүче бер гүзәлкәй,
Күккә ашкан горур наратлар!

1950 ел

***

Әй, язмышым!
Мәдәт бир син миңа
Яңа көрәшләрдә җиңәргә –
Кулымдагы факел сүрелмәсен,
Картлык сарылмасын иңнәргә!

Тормышка мин һаман гашыйк әле,
Сүрелмәсен шушы дәрманым.
Үтисем бар вөҗдан-намусымның
Үтәлмичә калган фәрманын.

Картлык, әнә, ишек шакый бугай,
Басып торам упкын ярында.
Көлемсерәп таңны каршылармын
Елмаерлык көчем барында!

Әй син, тәкъдир!
Эшләрем күп әле –
Сулышымны иртә өзмә син!
Кочсын мине сөю очкыннары,
Соңгы минут ашыгып килмәсен...

17 декабрь, 1981 ел ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

Р.Мөхәммәтҗанов фотосы

Ул миңа абый да иде...

Ирек Нигъмәти

Бер калада, бер казанда кайнаганга күрә, шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов белән гел аралашып яшәргә насыйп булды. Мин аны бертуган абыем кебек якын күрдем. Чордашларым арасында да аны шулай олуг шагыйрь итеп олылаган, хөрмәт иткән энекәшләре күп иде. Аз гына күзгә чалынмый торса да, бер бүлмәдә утырып эшләгән егетләр белән бергә, «бер-бер хәл булмадымы, авырып китмәдеме икән», дип борчыла, юксына торган идек. Аның иртән эш башлаганчы хәл белергә кереп чыгуына һәммәбез шулкадәр күнегеп беткән идек ки, хәтта хезмәтебезне дә ул күренмичә башлавы, ничектер, «бисмилла» әйтмичә тотынган кебек уңайсыз тоела иде. Һәммәбез, дигәнем Газинур Морат, Ләбиб Лерон, Ркаил Зәйдулла, Ләис Зөлкарнәй, Марат Закирлар...

Хәер, үзенең дә, шәхсән мине энекәшедәй якын күргүен тоеп яшәдем. «Идел-Пресс» йорты коридорында каләмдәшләрем белән бергә күрсә, иңбашымнан тотып читкә алып китеп хәлемне сораша, урамда очратса, тормышым белән кызыксына, әти-әниләремә, туганнарыма сәлам күндерә. Ни өчен дигәндә, ул алар белән таныш иде. Университетта укыган елларда Кызыл Позиция урамындагы тулай торак, кыш җитүгә, яраткан әдипләребез белән очрашу урынына әйләнә. Бу гаҗәеп шәп гамәлне, гадәттә, Фәиз Зөлкарнәев, Флера Низамова, Нәҗип Исмәгыйлев кебек, «Әллүки» дивар гәҗитен чыгаруда катнашучы өлкән курс студентлары башкара. Ул чорда без шигырьгә коенып яшәдек. Әле дә исемдә: беренче курста татар әдәбияты дәресендә укытучыбыз Мөхәммәт абый Мәһдиев, искитмәле кызык вә мәгънәле итеп, әсәрләндереп, безгә Равил Фәйзуллин, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов иҗаты турында сөйли. Һәркайсыбыз ләззәтле хыял дөньясына чума, Мөхәммәт абыйны тыңлый. Аның бер лекциясендә катнашу – бәгъзе бер югары уку йорты да бирә алмаслык белем, мәгълүмат алуга тиң иде... Дәресләр тәмамлануга, һәммәбезнең дә исәбе – төркемебез белән җыйнаулашып, Бауман урамындагы китап кибетенә төшү. Анда исә барыбызның да күзе татар әдәбияты бүлеге киштәләрендә: берәрсенең яңа китабы чыкмаганмы? Әнә шулай кош тотардай очып йөргән көннәрдә, китап кибетендә шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовның «Исәнме, йөрәк» исемле китабы пәйда булды. Бу китапны кулга төшергән айларда тулай торак студентлары, дәрес өйрәнәсе урында, төннәр буе Мөдәррис абыйның «йөрәген» укыды. Һәр битен ачкан саен, шигырьләрдән килгән югары көчәнешле кыска ялганыш, тимерче миченнән агылган кайнар дулкын сыман, сулышларны көйдерә, күкрәк куышындагы нәни йөрәк, шушы ләззәтле шигъри халәттән оясын тарсынып, сөенә-сөенә сикереп тибә иде. Мөдәррис абыйның үшән заманага кизәнеп язган кыю шигырьләре безнең дөньяга карашыбызны киңәйтте, күңел күзләребезне ачты, милли кыйблабызны билгеләде. Без бик тә бәхетле идек. Менә беркөнне: «Ркаил Зәйдуллиннар төркеме Мөдәррис абыйны тулай торакка очрашуга алып кайткан», – дигән хәбәр таралды. Түземсезлек белән шул мизгелләр җитүен көтә башладык. Минем аны үсмер чагымда, 1973 елның җәендә, үзебезнең Биектау районындагы Яңавыл клубына шагыйрь Илдар абый Юзеев җитәкчелегендә бер төркем әдипләр белән чыгыш ясарга кайткан вакытта күргәнем бар иде. Алтынчы сыйныфтамы укыган чагым. Шигырь-хикәяләрем, мәкаләләремнең «Татарстан яшьләре», «Яшь ленинчы» газеталарында, «Ялкын» журналында дөнья күргән вакыты. Авыл халкы язучыларыбызның чыгышын яратып кабул итте. Клубта алма төшәрлек тә урын юк иде. Шунда Илдар Юзеев Мөдәррис абыйны тәкъдим иткәндә мәзәк итеп: « Хәзер сезнең алда иң талантлы, иң яшь, иң пеләш шагыйребез чыгыш ясый», – дип әйтүгә, халыкның гөр килеп көлүе хәтердә калган. Мөдәррис абый анда «Мишәр карчыгына» дигән күләмле генә шигырен укыган иде. Халык аны тынсыз калып, сеңеп, әсәрләнеп тыңлады, әле укып бетергәч тә беркавым исенә килә алмый торды, аннары гына шагыйрьне зурлап, озаклап кул чапты. Бәләкәй генә буйлы Шагыйрьнең һич көтмәгәндә гаепләү актыдай яңгыраган шигыре белән халыкның йоклап яткан җанын уятып җибәрүе, шигыренең милләтебезнең гыйбрәтле язмышына багышлануы, могҗизаи көч белән, җыелган халыкны шундый тетрәнү хәленә куйгандыр, дип уйлыйм. Тамашадан соң шагыйрь белән бик тә күрешәсем килгән иде. Әмма колхоз, совет рәисләре, авыл активистлары кочагында калган әдипләр янына якын килү мөмкин түгел иде... Тулай торактагы шигърият кичәсе бик күңелле үтте. Барыбыз да, дулкынланып, Мөдәррис абыйны тыңладык. Аның һәр шигырендә күңелләрдә йөргән һәр рәнҗүгә

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

Айрат Садыйков фотосы

Остаз үзенең яшь каләмдәшләре Ркаил Зәйдуллин (уңда), Газинур Моратов, Ләбиб Лерон белән. 1980 нче еллар.

җавап яңгырый сыман иде. Очрашудан соң, аннан еллар буе зарыгып көткән автографын алдым. Аның белән танышлыгым менә шул очрашудан соң башланып китте. Төрле әдәби кичәләргә килгән чакларда мин аның белән кул биреп күрешә башладым. Әмма безне якынайткан сәбәп бөтенләй үзгәчә булды. Бервакыт Мөдәррис Әгъләм белән «Ялкын» журналында бергә эшли башладык. Шулай тыныч кына эшләп йөргәндә (декабрь ае бетеп килә иде) әниләрдән хат алдым. «Бик тә «важный» эшләрең булмаса, Яңа елга авылга кайт», – дип язган иде әнкәй. Уйладым-уйладым да, кайту уен Мөдәррис абыйга да җиткердем. «Әйдә, – мин әйтәм, – авылга кайтып,әниләрнең хәлен белеп килик әле. Яңа елны да шунда каршылап, мунча кереп, бераз ял да итәрбез». Агай каршы килмәде. Без 31 декабрь көнне төш җитәрәк «Яшел Үзән-Күлбәш» автобусы белән юлга кузгалдык. Автобустан төшүгә, буран башланды, бар дөнья акка күмелде. Тирән кар ерып, ун чакрым ераклыкта урнашкан Мәмдәл авылына җиткәндә җиргә тәмам караңгылык иңгән иде инде. Буранның да туктарга исәбе күренми. Ә туган авылга кадәр тагын алты чакрым тәпилисе бар. Олы юлдан читтә урнашканга, безнең якка кышын сельпо атыннан башка берни дә йөрми. Анысы да – Мәмдәлдән атнага бер тапкыр кибеткә товар китерергә кирәк булганда гына... Юл күмелгәнлеген белсәк тә, алга таба кузгалдык. Барыбер кайтасы бар, икебезгә бураны да куркыныч булмас, дибез. Әмма бер чакрымлап киткәч, Мөдәррис абый караңгылык чоңгылыннан ниндидер тавышлар ишетә башлады. «Мәмдәлдән киләдер ул, – дим. – Ерак китмәдек бит әле». «Мәмдәл артта калды, ә бу бөтенләй башка тарафта бит», – диде юлдашым һәм бүрек колакчанын күтәртеп бәйләде. «Бу – сөйләшкән тавыш түгел, хатын-кыз кычкырган аваз, – ди агаем. – Әйдә, бераз шунда таба атлыйк, ачыла төшмәсме, буран да басылып килә».

Тавыш бирә-бирә, үзебез дә шул якка бара башладык. Бераздан билдән карга чумган ике кыз янына килеп чыктык. Безне күргәч, алар, табылуларына куанып,

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

елый ук башлады. Мөдәррис абый кызларның авыр сумкаларын кулына алды, мин исә икесен дә кар баткаклыгыннан сөйрәп чыгардым. Шулай әкрен генә кар өстеннән сөйрәләбез. Мин алдан, кызларның сумкаларын күтәргән Мөдәррис абый арттан бара. Күңелләрен «юату» өчен ул кызларга юл буе җеннәр турында ниндидер әкият сөйләп кайтты. Әзрәк курыксыннар, көч җыйсыннар, дип уйлагандыр инде. Чынлап та, алар шактый хәл туплаган булып чыкты. Авылга җитүгә, юл буе сөйрәлеп кайткан кызларга канат куйгандай булды! Алар кинәт, ах-ух килеп, кибет янында торган егетләр кочагына ташланды. Хәл керү колакларына шул егетләр тавышы ишетелүдән булган икән. Кызларыбыз, әйтерсең, автобустан яңа гына төшеп калганнар. «Кара, болар рәхмәт тә әйтмәде түгелме соң?» – дип куйды агай, арган кулларын уа-уа.



Николай Седов фотосы

Мөдәррис Әгъләмов иҗатташ дусты Зөлфәт белән. 6 март, 1994 ел.

Буранда юлга чыкканга бераз әрләп алсалар да, исән-имин кайтып кергәннәренә өйдәгеләр бик куанышты.

...Мунча кереп чыкканнан соң, табынга утырыштык. Әткәй безгә сугышта күргәннәрен, янә башка кызыклы хәлләр сөйләп, исләребезне җибәрде. Ул заманында Карәтмән авылы мәдрәсәсен тәмамлый, «Касыймия» мәдрәсәсендә белем ала. Ленинградны саклауда катнаша. Сапер була. Өченче һәм икенче дәрәҗә ике сугышчан «Дан» ордены белән бүләкләнә. «Мин бит, сапер булу белән бергә, батальонда агитатор да идем. Казакъ, таҗик, үзбәк егетләрен Ватан өчен гомерне дә кызганмаска үгетләдем. «Әкә, язып бир әле», «Әкә, укып бир әле», – дип сорагач, үз телләрендә үк өйләренә хатлар да яза идем *(шушы хәлне Казандагы сабакташ вә каләмдәш егетләргә сөйләгәннән соң, Мөдәррис абыйга «Әкә» дигән чираттагы яңа исем өстәлде. -* **И.Н.***)*. Әмма беркайчан да... », – дип көйләп кенә сөйләп барганда Мөдәррис абый, әтине бүлдереп: «О-о-о, агай, алайса, син чын партийный инде», – дип әйтеп куймасынмы! Әти дәшмәде, бераз тынып торды да: «Шулай уйлавыңда хаклык бар. Агитатор итеп билгеләнгәч тә, мине штабка чакырдылар. «Син җитди эшкә билгеләндең. Без Ленинградны саклыйбыз. Агитатор коммунист булырга тиеш. Менә сиңа партия уставы, укып чык та иртәгә җавабыңны бирерсең», – диде миңа командир. Минем иманым, кыйблам бер генә иде. Ул – Аллаһы Тәгалә. Хәзерге кайбер җитәкчеләр кебек, партия арты партия алыштырып йөрмәдем. Ә боларга ни диергә иде соң? Баш тартсам, мине атачаклар бит. Мин бит Ленинградны, Ленин каласын саклыйм. Берәү булса, уйламыйча да: «Мин риза», – дияр иде... Нишләргә? Ә мин аларга җавап таптым бит: «Мин андый изге кеше була алмыйм», – дидем.

Хәйлә белән әйттем, әлбәттә. Әмма шунсыз котылу мөмкин түгел иде». Әтинең сүзләреннән соң, Мөдәррис абый шактый озак башын чайкап утырды. Яңа ел каршылаганнан соң, йокларга яттык. Тәмләп йокыга гына киткән идек, әнинең йомшак кына итеп дәшкән тавышына күзләребезне ачтык: «Балалар, торыгыз әле, сыер бозаулаган! Әтиегез лапаста инде». Мин шундук аңлап алдым: абзарда мүкләнгән карөй (кара өй) булса да, кышын сыер бозаулый калса, яңа туган бозауны безнекеләр өйгә алып керә. Яшь бала кебек күргәнгәме, туңмасын дип җәллиләр. Бозау өйдә атна-ун көн тора. Бу көннәрдә өйгә аны имезергә 3-4 тапкыр әнкәсен алып керәләр. Шул хакта тиз генә Мөдәррис абыйга әйттем. «Син мине дөнья күрмәгән дип уйлыйсыңмы әллә? Мин дә авылда боларны күреп үскән такыр баш бит, әйдә, чыгабыз», – диюгә, шагыйрь каршында тынычланып калдым. Озын ләгәнгә башта йомшак печән түшәдек, аннары бер иске бишмәт кисәге салдык та карөйгә кердек. Әти сыер алдына чиләк белән онлы җылы су куйган, утлыкка җиләкле печән салган. Сыер исә, мөгри-мөгри, балакаен ялый. Тегесе торып баскан да, әнкәсенә сыенган килеш, юеш борыны белән сөт эзли. «Менә дөнья рәхәте кайда ул, агай, ә?!» – диде Мөдәррис абый әтигә көлеп-елмаеп. «Әйтәсе дә юк инде, егетләр, дип җавап бирде аңа әти. – Шигырь менә шушы бозау мөгрәвендә инде ул!». «Маладис, агай, – дип җөпләп алды әтинең сүзен Мөдәррис абый һәм миңа борылды: – Әткәңнең сүзен мәңге онытма, егет!» Без бозауны җайлап кына ләгәнгә салдык та, ике яклап күтәреп өйгә сыпырттык. Шул арада әни аңа күз тиюдән саклый торган кызыл муенса да тагып куйды. Аның шушы җанга: «И, кызым, бик ераклардансагынып килгәнсең бит син безгә, бик арып-талып килгәнсең,» – дип эндәшүенә дә Мөдәррис абый исе китеп башын селкеде. «Әниләр барысы да бертөрле икән, – диде ул барыбызга да ишетелерлек итеп. – Чорлар гына башка. Без көтү көткәндә бер сыер югалды. И эзләп карадык та инде. Айлар буе эзләдек. Кермәгән урман-чытырман калмады. Сыер хайваны ашап туймый бит ул. Бу да, хәтфәдәй болынны ташлап, елгага төшкән дә тояк арасына агач тамыры кереп эләгеп калган. Ычкына алмагач, ачлыктан балчыкка кадәр кимереп бетергән иде. Шул сыер аркасында суд юлларында йөреп, күпме җәфа чиктек. Ә әнкәй шул сыерның ачтан интегеп үлүен җәлләп елады».

Аннары без өйгә сыерны керттек. Ул тәҗрибәле әнкә иде. Ишектән керүгә, түргә узмыйча, мөгри-мөгри бозавы янына борылды. Аны ашатып, үбеп-ялап чистартты да: «Инде мин чыгам, балакаемны кадер-хөрмәттә генә генә тотыгыз», – дигән сыман, безгә борылды. Мөдәррис абый ишекне ачты.

Шушы кайтуны ул гомере буе күңелендә саклады. Казанда минем өйгә килеп чыккан вакытларында әтинең Ленинград блокадасында күрсәткән батырлыгын искә төшерми калмый иде. Әни Казанда торганда да аңа улы кебек яратып, гел җылы оекбаш-бияләйләр бәйләп җибәрде. Авылдашларым да кунакка кайткан чакларымда Мөдәррис абыйны Казандагы берәр театрда яки әдәби кичәдә күрүләрен өйгә кереп сөйләп, хөрмәтләрен белдерәләр. Гәрчә бик яшьли үк ата-ана назыннан, тәрбиясеннән мәрхүм калып үссә, яшәсә дә, Шагыйрь бервакытта да үзен ятимсетмәде, минемчә. Чөнки аның, үзе әйтмешли, чын-асыл Шигъри Әнкәсе бар иде!

Мин аны гел юксынып яшим. Һәр иртә, эш башланыр алдыннан, аның хәл белергә керүен көтәм. Ул миңа абый да иде бит!



Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ

(1946-2006)

ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ

Күз төбен ярып, яшьләрем
Тәгәри телем-телем:
Акчага сугылмаган тел
Ул дәүләт теле түгел.

Кәнфит-прәннек алырга
Йөгергән бала-чага
Акчага сугылган сүзне
Хәрефләп таный ала.

Нәкъ шулай белеп үсә ул
Туган телнең бар тәмен –
Ни нәрсә бер тиен тора,
Ни нәрсә – бер тәңкәлек.

Әткәң-әнкәңнең теленнән
Назлы моң ташып тора;
Ул, дәүләт теле дә булса,
Бер башка ашып тора.

Мохтажларына ярдәмле,
Яманга гыйбрәтле ул –
Бары акчага сугылган
Тел генә дәүләтле ул.

ӘЙТМӘГЕЗ ЯРЫМА

Бу кичне мин бер төш күрдем,
Җылан керде лә куеныма,
И әнкәем, җылан керде лә куеныма...
Солдат бәетләреннән

Сөйлиләр: болгари бабайлар
Бирегә урнашкан заманда
Идел-йорт охшаган җыланнар
Тутырган бик олы казанга.

Ул чорда һәрнәрсә иркендә –
Идел дә, хисләр дә йөгәнсез...
Ә бәлки шул чактан калгандыр
«Куенымда җылан бар» дигән сүз.

Кергәннәр бәйрәмдә, уенда,
Ау белән йөргәндә кергәннәр...
Төрлечә: яхшылык белән дә,
Яманлык белән дә кергәннәр.

Гөнаһсыз баланың куенына
Әнкәсен елатып кергәннәр,
Кергәннәр... агулы телләрен
Бал белән чылатып кергәннәр.

...Утырган бабамнар бирегә
Туздырып җыланнар оясын:
Агулы җыланнар аз калган –
Елга бер очратып куясың.

Чабасың сахралар эченнән,
Искәрми чабасың... тып-тыныч.
Өстенә басасың – чагалар,
Очраклы җыланнар куркыныч.

Шуышып узалар йөрәктән...
Төсләрен үзгәрткән җыланнар.
Күкрәгем – Идел-йорт, дусларга
Кычкырам: «Куенымда җылан бар!»

Куенымда җылан бар. Ир-егет
Ир булса, аңардан арына...
Куенымда җылан бар, дусларым,
Әйтмичә торыгыз ярыма!.. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

Адаш абый яки Отрар хатирәсе

Ләбиб Лерон

Бу арада казакъ әдәбияты һәм тарихы белән кызыксына башладым әле. Тиктомалдан түгел. Сәбәбе бар. Сәбәпчесе – мөхтәрәм адашым Лирон абый Хәмидуллин. Аңа шушы көннәрдә генә 85 яшь тулды. Туу вакытын төгәл күрсәтмичә, «шушы көннәрдә» дип язуымда хаклык бар: Лирон Хәйдәр улы 1932 елның 22 октябрендә туган, рәсми кәгазьләрдә исә «10 ноябрь» дип теркәлгән.

Баксаң-күрсәң, Лирон абый белән танышуыма да Пушкин гомере хәтле вакыт үткән икән инде. Могтәбәр юбилярыбыз турында сүз әйтми калу килешмәс, дип, тормышы-яшәешеннән, иҗади эшчәнлегеннән беркадәр хәбәрдар булсам да, аның биографиясен, басма китапларын янә бер кат күздән кичереп алырга ният иттем.

«...Отрар һәлакәте – Чыңгызхан кавеменең Урта Азия һәм башка илләрне басып алуы нәтиҗәсе. Ул кавем безнең җәйрәү далабызга, элегрәк һөҗүм иткән һун һәм гарәпләр, фарсы һәм грек басып алучылары кебек үк, зыян-зәүрәт, әрнү алып килгән. Бу яу кулыннан 1218 елны – Отрар, 1220 елны – Җәнт, соңра Сыгнак шәһәрләре һәлак була. Җәнт шәһәренең ул чордагы дәрәҗәсен чамалау өчен, Аралның «Җәнт диңгезе» исемен йөртүе дә җитә шикелле. Чыңгыз илбасарларына кадәр безнең дала «кангха иле», ягъни арык-каналлар иле, дип йөртелгән булган. Иң хәтәре – яу аны таптап, җимереп үткән. Чыңгыз явыннан соң ул кабат һушына килергә өлгерми, аны Җүңгәр атлылары таптап уза. Иран шаһы Надиршаһ та аның кала һәм каналларын янә бер ватып, яндырып китә әле. Шуннан соң элек бакча булган яшел дала ташландыкка әверелә, аны ком каплый башлый. Яуга каршы торып кан койган кыпчак һәм найман ырулары телендә бары гасырдан-гасырга «Отрар», «Җәнт», «Кангх» сүзләре генә онытылмый сакланып кала...»

Әлеге өзек казакъ язучысы Әнүәр Әлимҗановның (1930-1993) «Күкшел таулар илендә» дигән әсәреннән китерелде. Аңлашылгандыр, шәт, әсәрне казакъчадан татарчага тәрҗемә итүче – Лирон Хәмидуллин. Бу өзеккә бәйле сүзем әле алда булыр, дип, хәзер өлкән каләмдәшем турында сөйләүгә күчәм.

Лирон абый белән якыннан танышуыбыз хакында Аккош күленә нисбәтле бер мәзәккә тартым истәлегемдә язган идем инде. «Балта остасы» булып бер көн эшләп алуым турындагы ул язма «Аккош күле – илһам аланы» дигән күмәк хатирәләр җыентыгында (Казан: Мәгариф, 2007) басылды. Шул язмадан бер өзек: «...1980 елның май ахырлары. Ул чакта юлдашым кем булгандыр *(яшьтәшем, сабакташым Ркаил Зәйдулла булмадымы икән ул, дип уйлыйм хәзер. –* **Л.Л.***)*, Бауман урамындагы Матбугат йортыннан чыгып килешебез иде, каршыга Әдәби фонд директоры Лирон абый Хәмидуллин очрады. Мин аны таныйм (каләмдәш яшьтәшләрем белән Язучылар берлегенә килгәч, еш күрә идем), ул да мине исендә калдырган, ахрысы. Хәл-әхвәлләрдән соң, Лирон абый сынаулы-сораулы карашын безгә төбәде:

Сулда – Хупҗамал әби, уңда – этисенең сеңлесе Затия. Гармун тоткан малай – Лирон. 1940 ел

– Язучыларның Аккош күлендәге дачасында каккалыйсы-суккалыйсы эшләр бар иде. Балта-чүкеч тота белүче юкмы арагызда?

Юлдашым белән бер-беребезгә карашып алдык шикелле. Ул, миңа ишарәләп:

– Бар. Менә... Ләбиб белә! – дип тә әйтте бугай әле. Соңыннан үкенәм үкенүен, әмма теләсә нинди эшкә уйламыйча алына торган гадәтем бар.

– Эш кораллары бармы соң? – Лирон абыйга ризалык биреп ташлавым иде инде бу.

– Акча булыр. Кирәк-ракларны үзең сатып алырсың, – диде Лирон абый...»

Шушы күрешүгә хәтле дә, шушыннан соң да Лирон абыйдан исеменең каян килеп чыгуы хакында гел сорыйсым килеп йөрде. Бервакыт җай-форсат чыгып, тәки сорадым бит үзеннән. «Кысыграк күзләрен тагын да кыса төшеп, күзлеген төзәтә-төзәтә» (мәшһүребез Миркасыйм Госмановның аркадашы Лирон Хәмидуллинга нисбәтле сүзләре), ул болай дип җаваплады:

– Узган гасырның егерменче еллары ахырында эти дә, әни дә үз туган авылларында алдынгы яшьләрдән саналган, ахры. Икесен дә шәһәргә укырга җибәргәннәр. Алар шунда танышып кавышкан. Югыйсә һич тә кавышасы булмаганнар: туган авыллары Самара губернасының капма-каршы ягында. Хәзер ул авылларның берсе – Оренбург *(Искеавыл, Яңа Сергеевка районы. –* **Л.Л.***)*, икенчесе Ульяновск өлкәсенә карый. 1932 елның көзендә Ульяновск өлкәсенең Яңа Малыклы районында – Иске Төгәлбуга дигән авылда *(мәшһүр музыкант Фәйзулла Туишев (1884-1958) белән тарихчы-галим Җәмил Гыйльманов та (1925-1991) шушы авылдан. –* **Л.Л.***)* туган сабыйга исем кушуда, әлбәттә, авыл укытучылары активлык күрсәткән. Чыгышы хәзерге Нурлат районының Яңа Әмзә авылыннан булган Шәмсурый апа белән аның ире Насыйп һәм Җәмил Гыйльмановның эти-энисе *(Ибраһим ага белән Баян апа турында сүз бара. –* **Л.Л.***)* сиңа «исем бирде», дип сөйли иде әнием Бибиҗиһан...

11 яшендә этисез калган Лирон аганың *(аның этисе Хәйдәрҗан Нурыйҗан улы Хәмидуллин 1943 елның 27 июлендә Ленинград камалышында батырларча һәлак була. –* **Л.Л.***)* балачагын тасвирлаган язмаларында әбисе Хупҗамал исемен *(этисенең әнисе турында сүз бара, әнисенең әнисе Габидә әдип туган елда вафат була. –* **Л.Л.***)* еш телгә ала: *«Башкортстан язучысы Мостай ага Кәримнең «Озын-озак балачак» әсәрен укыганда, кабат үземнең балачак хатирәләре күз алдымнан үтте. Биш-алты яшьләр булганда, ялгызымны урамда калдырып китә алмаганда, әбием мине дә әби-чәбиләрнең йола мәҗлесләренә ияртеп йөртә иде, Пәрау авылының ишан хәзрәтләре йортында тәрбия алганлыктан, ул оста дога укучы һәм бик оста мөнәҗәт көйләүче санала. Шуңа күрәдер инде, биш йөз йортлы зур авылның без булмаган почмагы калмагандыр...*

Әбием кул эшләренә дә бик оста иде, мәрхүмә. Кыш айларында, кемнәрдәндер туку ыстаны алып кайтып, үзе үк ашъяулык, сөлге, алъяпкыч ишеләрне «суга», мин җепшүре ише вак-төякне аңа биргәләгән булам. Җеп чуалганда аның баш өстендә керосин лампасын тотып торырга да туры килгәли иде...

Сулдан уңга: Разил Вәлиев, Фәннур Сафин, Лирон Хәмидуллин, Празат Исәнбәт, Зәет Мәҗитов, Мирсәет Яруллин, Миргалим Харисов, Ризван Хәмид, Фаил Шәфигуллин, Зөлфәт. 24 май, 1974 ел

Киң сәкегә арка терәшеп яткач та без кышның озын төннәрендә тиз генә йоклап китмибез. Мич белән сәндерә ягыннан чикерткәләр черелдәвен, тыштагы суыктан бүрәнәләрнең шатырдап чатнап китүен тыңлап, озын-озын догаларны күңелдән генә укып ятабыз. Вакыт-вакыт әби аларны миңа кычкырып кабатларга куша, ялгыш әйтелгән сүзләрне дөрес укырга өйрәтә. «Дога белсәң генә иманлы булырсың, балам», – дип әйтә иде. Ә кайвакыт, тизрәк йоклап китсен, дигәндәй, ярымпышылдап берәр озын мөнәҗәтне көйли башлый иде.

1961 елда Габделҗәббар Кандалыйның шигырьләр җыентыгын алып укыгач, сискәнеп киткән идем. Әбием яттан көйләгән кайбер мөнәҗәтләр анда, һичбер үзгәртүсез, «мәнем», «сәнең» кебек сүз үзенчәлекләре белән басылган. Укый башлауга, әбиемнең моңлы аваз агышы күңелдә яңарды. Авылдашының (Г.Кандалыйның, димәк. – **Л.Л.***) ул шигырьләрен укып үскәнме әбием? Әллә соң халык арасында мөнәҗәт рәвешендә таралганын ятлаган булганмы, белмим...» («Балачак хатирәләре»ннән)».*

Язучының шул ук хатирәсеннән: *«Китап тотып шәм тирәсендә озаграк утырган чакларымда әбием:*

– Шәкертҗан агаң кебек (Хупҗамал әбинең Нурлаттан чак кына арырак булган Кизләү мәдрәсәсендә укыган туганы Закирҗан турында сүз бара. – **Л.Л.***) укымышлы булырсың ахрысы, – дип үсендереп куяр иде...»*

1939 елда мәшһүр авылдашы Фәйзулла Туишев Иске Төгәлбугадагы биш мәчетнең берсендә – клубка әйләндерелгән олы мәчет бинасында концерт куйган чакта, аны тамаша кылырга әбисе һәм сеңлесе Гөлфия белән «дәү» Лирон да бара: *«Без килгәндә өч бура тоташтырып ялганган зур клуб эче халык белән шыгрым тулы иде. Безгә элекке мәчетнең иркен сәндерәсенә менәргә туры килде. Анда да кеше күп иде. Тик бер мәрхәмәтлесе, кысыла төшеп:*

– Хупҗамал абыстай, утыр җаныма, – дигәч кенә әбиебезгә урын табылды. Сеңлем белән мин исә, башка балалар кебек, сәндерәнең алгы киртәләренә сөялеп бастык...» («Онытылмас бер көн»).

Каләмдәшләре Госман Садә (сулда), Барлас Камалов, Зөлфәт белән. 1980 нче еллар башы

Биредә Лирон абыйның истәлек язмаларыннан Хупҗамал әбисе турындагы мондый өзекләрне китереп, әдипләребезнең шәхес буларак формалашуында әбиләрнең йогынтысы гаять зур булуын янә бер искәртүем иде. Шәхсән, минем тормыш сәхнәмдә әниемнең әнисе Мофаккирә әби әйтеп бетергесез роль уйнады...

Гомеремдә иң күп китап укыган вакытым – мәктәп еллары һәм студент чак. Мәктәптә укыганда, китапханәләрдә нинди китап бар – барысын да, кем әйтмешли, су урынына эчтем. Студент чакта күбрәк колак ишеткәнгә, ягъни университетта укыткан мөгаллимнәребездән, рухи остазларыбыздан, каләмдәшләребездән ишеткән читят авторларның китапларына аеруча игътибар бирелде. Ул вакытта, үзем дә каләм тибрәткән кеше буларак, язучылар белән еш аралашырга туры килә иде. Әлбәттә, яңа танышкан әдипләребезнең китапларын, китапханәләрдән, китап кибетләреннән эзләп табып, барысын да энәсеннән-җебенәчә укып барырга тырыша идек.

Лирон абый Хәмидуллинның ике китабын – «Юлда» (1968) һәм «Дала иртәсе»н (1971) мин нәкъ менә әлеге дә баягы «балта остасы» вакыйгасыннан соң укыдым. Лирон абыйның рухи остазлары Әмирхан Еники белән Гомәр Бәширов әсәрләре дә, Хәмидуллиннарның гаилә дуслары булган Гариф Ахунов һәм Хәсән Сарьян китаплары да күбрәк шул чорда укылды...

Рухи остазлар, дуслар, дигәннән... Бер гәпләшеп утырганда, Лирон абыйдан: «Кемнәр белән аралашып яшәдең, бүгенге көндә кайсы каләмдәшләребез белән дустанә мөнәсәбәттә?» – дип сораган идем. Ул, җавап итеп, болай диде:

– Казанга килгәч, иң якын мөнәсәбәтем Хәсән Сарьян һәм Әмирхан Еники белән урнашты, дип саныйм. Соңгы көннәренә кадәр алар белән дустанә якын булдык. Каләмдәшләрем Зәки Нури, Гариф Ахунов, Фәрваз Миңнуллин, Азат Әхмәдуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллиннар белән бергә эшләү дәверендә якынайдык. Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалим иҗатлары күңелемә якын, кайчандыр алар белән дә бергә эшләгән идек. Нурихан Фәттах, Туфан Миңнуллин иҗатларын да зурлыйм, аларны бик ихтирам итә идем. Әхмәт Рәшит, Рәдиф Гаташ, Рәфкать Кәрами – фикердәшләрем. Заманында тәрҗемәчеләр секциясен ун

Хатыны Дания, балалары Булат, Зөһрә һәм оныклары Мансур, Таһир белән. 2002 ел

елга якын җитәкләдем, ул вакыттагы актив тәрҗемәчеләрдән Рәис Даутов, Кыям Миңлебаев, Таһир Нурмөхәммәтов, Яхъя Халитов белән китап нәшриятында да кулга-кул тотынып эшләдек. Нури ага Арслан, Марс Шабаев, Гәрәй Рәхим, Гөлшат Зәйнашева белән байтак еллар бакча күршеләре булдык...

«Отрар – безнең үткәнебез. Ул – Чыңгыз хан кавеменең иң әүвәлге, иң көчле явына каршы торган калаларның берсе. Миңа ул шәһәр үзебезнең Азия чигендәге Сәйхүн *(Сырдәрья елгасының әүвәлге исеме. –* **Л.Л.***)* **елгасыннан Европа читендәге ерак Андалузия тауларына хәтле җәелгән дәһшәтле яу кырының иң беренче форпосты, тау астында тапталып калган беренче солдаты кебек күзаллана...»**

Озак еллар СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры булып эшләгән Лирон абый Хәмидуллинны без, язучы булуыннан тыш, тәрҗемәче һәм галим дип тә беләбез. Казакъ язучысы Әнүәр Әлимҗановның мин алда өзекләрен китергән «Күкшел тау илендә» дигән повестеннан кала, ул, тәрҗемәче буларак, әлеге телдән татарчага тагын бихисап әсәрләр, әйтик, шул ук авторның «Отрар хатирәсе»н *(соңыннан бу ике бәян 1974 елда аерым китап булып басыла. –***Л.Л.***)*, Сайын Моратбәковның повесть һәм хикәяләрен («Әрем исе», 1986), Абай Конанбаевның «Хикмәтле сүзе»ен («Абай» җыентыгы, 1981), үзбәк язучысы Әсгать Мохтарның «Чинар» романын (1976), белорус әдибе Василь Быковның ике повестен («Һәйкәл», 1984), башкорт язучысы Яныбай Хамматовның «Бөртекләп җыела алтын» романын (1996) татар укучысы хөкеменә тапшыра. Лирон абый тәрҗемәсендәге «Отрар хатирәсе» һәм казакъ язучыларының повестьлары тупланган «Ак дөя» (1979) китабын исә (аны миңа дусларым туган көнем белән котлап бүләк иткән иде) 1980 нче еллар башында хатыным Фиданиянең туган ягында – Кукмара районының Октябрино дигән авылында бик тәэсирләнеп, яратып укыганым бүгенгедәй хәтеремдә. Ул китапларда язылганнар утыз биш елдан соң, 2017 елның 13 сентябрендә Төркестанда – Отрар шәһәрлегендә булган чакта, бөек шагыйрь, «Диване хикмәт»

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

(«Хикмәтләр тупланмасы») авторы Әхмәт Ясәвинең (1093-1166) остазы Арыслан баба мавзолеен карап йөргәндә күңелемдә кабат яңарды...

«Отрар җимерелгән, тузгытылган. Аның китапханәсенә тупланган меңләгән китапның язмышы аяныч. Бик күпләр әле дә аны яндырылган дип исәпли. Шәһәр кешеләре яуда кырылып беткәч, аның тереклек тамырларын – су юлларын ком баса, койма-йортлары җимерелә. Отрар – «бөек ефәк юлы»нда утырган шәһәр була. Заманында ул Азия белән Европа арасындагы үзара аралашу, сәүдә, белем һәм гыйлем, культура бәйләнешләрен бер төенгә төйнәп торган кала була. Яу, җимерелү шул бәйләнешләрнең барын өзә, юк итә. Дөрес, ике гасыр вакыт узгач та ул берникадәр тергезелә, яшәү дәрте белән яна башлый. Тик баш калкытырга өлгерми кала. Яңа сугыш афәте аны яңадан һәм инде мәңгегә җимереп ташлый. Бик күпләрнең башына җиткән әмир «Аксак Тимер дә Отрарда үлә», – дип язып калдырган безгә Чокан Вәлиханов *(чын исеме – Мөхәммәт Хәнәфия, 1835-1865, күренекле казакъ галиме, тарихчы, этнограф, мәгърифәтче, Чыңгызхан токымыннан – Вәли хан оныгы – Әбләй хан (1711-1781) торыны. –* **Л.Л.*)*...»**

Бигрәк тә төрки телле язучыларны күз уңында тотып, бер күрешүебездә Лирон абыйдан: «Татар укучысына бүген тәрҗемә әсәрләре кирәкме?» – дип сорадым. «*Бер генә әдәбият та үз-үзенә бикләнеп яши алмый. Һәркемгә башкалар белән көндәлек аралашу зарур булган кебек, әдәбиятлар да үзара аралашмыйча зур уңышка ирешә алмый. Бүген дә тәрҗемә әсәрләре бик кирәк. Шул ук төркиләр тарихына багышланган әдәби яки иҗтимагый эчтәлекле күпме китап басылып чыга хәзер. Бездә аларны язардай әдипләр дә, галимнәр дә сирәк. Ул өлкәне яхшы белгән Миркасыйм Госманов, Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин шикелле каләмдәшләребез аз, алар гына бу эшләрне башкарырга өлгерә алмый*». – Тәрҗемә өлкәсендә фидаиларча көч куйган, фанатикларча эшләгән әдибебезнең акыллы һәм үтемле җавабы иде бу.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Гаяз Исхакый (2010) һәм Җамал Вәлиди исемендәге премияләр лауреаты Лирон абый Хәмидуллинның галим буларак эзләнүләре аерым бер игътибарга лаек. Миркасыйм Госманов әйткәндәй, «бал корты кебек гел эзләнүләрен, шау-шусыз гына нәтиҗәле эшләвен дәвам иттерүче Л.Хәмидуллин 1998 елның башыннан алып хәзергә кадәр Татар энциклопедия институтында хезмәттәшлектә тора». Шундый эзләнүләренең күркәм нәтиҗәсе итеп, шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Закир Рәмиев (Дәрдемәнд), тарихчы һәм әдәбиятчы Габделбарый Баттал, аяныч язмышлы мәшһүребез Галимҗан Ибраһимов, атаклы «Галиябану» авторы, драматург Мирхәйдәр Фәйзи, татар телле тәүге газета-журналлар нашире һәм җырчы Камил Мотыйгый, фабрикант Акчуриннар, әдәбиятыбыз морзасы Әмирхан Еники турындагы хезмәтләрен искә төшерү дә җитә.

Сөекле хатыны Дания апа белән бергә ике бала (улы Булат һәм кызы Зөһрә) үстереп, аларны чын мәгънәсендә кеше итеп («Балалар үз юлларын тапты шикелле», – дип тыйнак кына әйтеп куйган иде әдип бер әңгәмәбез вакытында), инде күз карасыдай газиз оныкларын тәрбия кылучы сиксән биш яшьлек могтәбәр ил агасы Лирон абый Хәмидуллинның бүген дә милләт юлында игелекле гамәлләр кылып яшәгән чагы. Халкыбыз мирасын барлап, милләтебез мәнфәгатен кайгыртып гомер иткән олпат каләмдәшемә саулык-сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә бөтенлеге телим. Һәр яңа көн куаныч – шатлык кына алып килсен үзеңә, адаш Абый!

1 октябрь, 2017 ел ■

ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧ

(1895-1919)

1918 елгы сугыш хәрәкәтләре барышында шагыйрь башкорт гаскәрләре сафында хәрби корреспондент булып эшли. Соңрак, 1919 елның февраль аенда, уртак килешү һәм рәсми шартнамә нигезендә башкорт хөкүмәте һәм кораллы гаскәрләр совет ягына чыккач, Ш.Бабич Башкорт Республикасының Вакытлы хәрби-революцион комитеты каршындагы Матбугат бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкара. Шул чорда ул үзенең «Большевиклар белән килешү турында башкорт халкына көйле хитаб» дип исемләнгән шигырен яза. Ике йөз егерме дүрт юл тәшкил иткән бу озын шигырь-мөрәҗәгать, тиз арада типографиядә басылып, листовка рәвешендә халык арасында таратыла. Шагыйрь анда башкорт ыруының күп гасырлар буена бәйсезлек, ирек өчен көрәш алып баруы, хәзерге гражданнар сугышы шартларында милли азатлык хәрәкәтенең зур сынауларга, каршылыкларга дучар ителүе турында бәян итә, башкорт гаскәрләренең Дутов, Колчак ягында торып большевикларга каршы көрәш башлавының төп сәбәбен «Красная Гвардия дәһшәтеннән» Башкортстанның «канга батырылуы» белән аңлата. «Кызыл террор»ны шулай ачыктан-ачык фаш итү, мөгаен, кемнәргәдер ошап җитмәгәндер. Шигырь игълан ителүдән соң бер ай үтәр-үтмәс, 1919 елның 28 мартында, Темәстән Моракка Башревкомның типография җиһазларын күчереп алып барган вакытта, Зилаир авылы тирәсендә Шәехзадә Бабич берничә иптәше белән бергә кызыл гаскәриләр тарафыннан җәзалап үтерелә.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.140-141.

Рузәл Мөхәммәтша *әзерләде.*

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧ

БОЛЬШЕВИКЛАР БЕЛӘН КИЛЕШҮ ТУРЫНДА БАШКОРТ ХАЛКЫНА КӨЙЛЕ ХИТАП*

1

Башкорт намусына пычрак ташлап
Юрый кайбер битсез, имансыз;
Әйтә алар: «Дутов яклы булып,
Кара, пычрак юлны кугансыз!»

Менә хәзер дөнья алмашынды,
Һәр эш түнкәрелде аслына;
Без кушылдык якты, хөрлек якка, –
Дутов кайтты кара нәсленә!

2

Без кушылдык кызыл тарафына,
Кызыл безнең яклы булганга;
Азат Башкортостан җөмһүрлеген
Таныймын, дип хуплап торганга.

Без кушылдык хәзер кызылларга, –
Безнең өчен лаек шул булгач;
Нигә кушылмаска кызылларга,
Күптән көтеп торган юл булгач.

Нигә без качмыйк, ди, шул Дутовтан,
Дутов юыртып киткәч уң яктан?
Нигә ярашмаска большевик белән,
Безнең сукмак киткәч шул яктан?!

Большевиклар әйтә: «Бу дөньяда
Ярлы халык хөкеме йөрсен, – дип. –
Ярлы эшчеләрнең хас дошманы –
Буружуйларның тамыры корсын!» – дип.

Дутов-Колчак әйтә: «Эш башына
Алтын таҗлы патша менсен, – дип –
Патша менеп, һаман Николайдай
Ярлыларның канын имсен!» – дип.

Большевиклар әйтә: «Коллык бетсен,
Ярлы халык рәхәт яшәсен;
Ирек көне туып бу дөньяга,
Тигез, якты көннәр яшәсен!»

Дутов-Колчак әйтә: «Законнарны
Байбәтчәләр язып торсын, – дип. –
Ярлы, эшче халык әүвәлгечә
Байбәтчәгә хезмәт кылсын!» – дип.

Большевиклар әйтә: «Нәсел-нәсәп,
Түрәлекнең поты бер тин, – дип. –
«Калын җилкә» белән «ярылган күл»
Көнкүрештә булсын бер тиң», – дип.

Дутов-Колчак әйтә: «Җиргә, күккә
Хуҗа булсын фәкать патша, – дип. –
Мөселманнар һаман изелсен, – ди, –
Патшаныкы гына дөрес!» – ди.

Большевиклар әйтә: «Һәрбер илгә
Камил мохтарият бирелсен!
Һәрбер ярлы, мәзлүм, изелгән ил
Мохтарият алсын, терелсен!»

Дутов-Колчак әйтә: «Вак милләтләр
«Мохтарият» ала күрмәсен!
Патша кул астында гомер сөреп,
Буржуазлар җырын җырласын!»

Уйлап кара, башкорт, акылың белән:
Кайсы тараф сиңа хәерле?
Әнә теге яман Дутовлармы?
Әллә большевикмы хәерле?

Бер дә шиксез синең акылың әйтер:
Большевиклар юлы хәер, дип;
Җаның теләр шунда: «И Ходаем!
Дутовлардан мәңге аер!» – дип.

3

Бер без генә түгел, бик күпләрне
Ышандырды Дутов бер чакта;
Себер якта залим Колчак чыккач,
Кушылды да китте Колчакка!

Дутов төсен ачкач, Халык явы
Большевикка барып кушылды...
Дутов-Колчакларның юлын күреп
Чех-словаклар да пошынды.

Колчак чыккач, Дутов серен ачкач,
Барлык социалист партия
Изге ихтилалның хөрмәтенә
Тагылдылар кызыл артына!

*Шәехзадә Бабич. «Зәңгәр җырлар». – Казан: Тат. кит. нәшр.., 1990. – 244-248 б.

Шулай итеп, Дутов-Колчаклардан
Халык күңеле тәмам суынды,
Бу икәүгә каршы сугышу өчен
Кызылларга барып сыенды.

Ике залим читтән ярдәм сорап,
Союзникка атты күзләрен;
Союзниклар: «Сезгә гаскәр юк», – дип,
Аңлаттылар соңгы сүзләрен.

Шул сәбәптән хәзер Дутов-Колчак,
Белмим, инде нихәл итәрләр?
Нихәл итсен инде, мәгълүм хәлләр:
Тиздән җәһәннәмгә китәрләр.

4

Башкорт халкын элек аңламастан:
«Гакес инкыйлабчы, – диделәр. –
Патша утыртырга тели торган
Кара көчләр яклы», – диделәр.

Белсен уллар безнең башкортларның
«Гакес инкыйлабчы» түгелен;
Укысыннар башкорт тарихларын,
Шунда күрер башкорт күңелен!

Шунда күрер, башкорт борыннан ук
Инкыйлабчы булып килгәнен;
Залим түрәләргә башын бирми,
Ирек өчен сугыш кылганын.

Белеп торың. – безләр борыннан ук
Кара көчкә яман каршы идек;
Безнең үткәндәге каһарманнар
Заманына күрә – большевик!

Безнең Абыз, Акай, Салаватлар,
Кара сакал, Айдар, Күсимнәр, –
Болар бар да кара төскә каршы
Сугышып үлгән алтын исемнәр!

Ирек өчен, азат илкәй өчен,
Борыннан ук килдек кырылып,
Урыс белән ничә, ничә еллар
Сугышып барып, көчкә бирелдек.

Урыс кыскач безне шытырдатып,
Маиләттән чыктык, изелдек,
Җир тарайды безнең, ил карайды,
Адәм күрмәгәнне без күрдек.

Инде моңа форсат вакыт килгәч,
Башкорт халкы йоклап ятсынмы? —
Иле өчен сугышып шәһид булган
Олатайлар исемен сатсынмы?..

Юк, сатмады башкорт иске исмен,
Атылып килеп чыкты мәйданга!
«Мин – башкорт!» – дип, шунда
сөрәнләгәч,
Мәгърур халык калды хәйранга.

Бушка чыкты барлык явыз фикер,
Башкорт халкы үзен танытты.
«Азат Башкортостан» атын алып,
Кара көчкә каршы калыкты!

Ирек колы – башкорт, шулай булгач,
Дутов-Колчак яклы булырмы?
Аяк-кулын бәйләп, үзен-үзе
Кара көчкә тотып бирерме?

Мәңге бирмәс башкорт һәм бирдермәс,
Иле өчен янган сагышы!
Үлсә үләр газиз иле өчен,
Әмма тере калыр намусы!..

5

Үзаманым, энем, аксакалым,
Олатаем, апам, әнием!
Инанмагыз дошман сүзенә, дип,
Кайта-кайта җырлап көйләем!

Дутов залимнәрнең ялчылары
Сезнең арагызда йөрерләр,
Сезне алдап ауга төшерергә
Төрле кыяфәткә керерләр!..

Алар кара шайтан булсалар да,
Йөрер тыштан яхшы күренеп,
Сезне аягандай сүзләр сөйләп,
Фәрештәләр сымак кыланып.

Фетнә салып йөргән шайтаннарны
Советларга тотып китер син!
Кулга төшкән Дутов ялчыларын
Эһ, дидерми, эшен бетер син!..

1919 ■

ТАТАР ХӘРБИ разведчиклары

Рәис Зарипов

Хәрби разведчик Исмәгыйль Әхмәтовның шәхесен ачыклау өчен махсус хезмәтләр ветераны полковник Виталий Каравашкин китабыннан да өстәрдәй мәгълүматлар бар:

«1931 елның гыйнварында РККАның Разведка идарәсенә җибәрелә һәм радиоинструктор итеп билгеләнә. Күп мәртәбәләр чит илләрдә командировкада була. Хәрби электротехника академиясен тәмамлагач, Чехословакиядә ТАСС корреспонденты «түбәсе астында» эшли. 1940 елда Мәскәүгә әйләнеп кайта, Бүлек башлыгының махсус техника буенча урынбасары дәрәҗәсенә үстерелә. Шул елның сентябреннән хәрби разведканың Берлиндагы резидентурасында эшли. Алмания СССРга каршы сугыш башлагач, бик күп совет дипломатлары белән бер җиргә дә җибәрмичә тотыла (интернирование. – **Р.З.**). *СССРга 1941 елның урталарында әйләнеп кайта. Күп тә үтми, совет илчелегенең пресс-атташесы «түбәсе астында» Төркиягә җибәрелә.*

Әхмәтов 1942 елның май аенда төрек полициясенә килә һәм сәяси сыену урыны сорый. <...> 1948 елда төрекләр Әхмәтовны америкалыларга тапшыра. Ул ЦРУның Россия буенча консультанты булып тора һәм совет территориясенә җибәрәсе агентураны әзерләүдә катнаша. «Сталин ГРУында һәм аннан читтә: татарның Кызыл Армия разведкасыннан качуы» дигән китап нәшер итә» (Каравашкин В.В. Кто предавал Россию. – М.: АСТ: Олимп, 2008. – С.102-103.).

Виталий Каравашкинның үз хезмәтендә, «Әхмәтов 1940 елның сентябреннән хәрби разведканың Берлиндагы резидентурасында эшли», дип раславы аерым игътибарга лаек. Шул раслауга өстәмә дәлил итеп, танылган язучы Игорь Львович Буничның хезмәтеннән бер өземтә китерергә мөмкин: *«15 июнь көнне (1941 ел. – Р.З.) разведка сводкаларын карап утырган Сталин, күңеле әрнеп, нигездә бөтен совет разведкасының инглиз һәм америкалылыр ятьмәсенә эләккәнлегенә тагы да ныграк инанды. Һәрьяклап алманнарның озакламый һөҗүмгә кучәчәкләре турындагы кисәтүләр ява иде. Ә бит разведчиклар, артык мәшәкатьләнеп тормыйча гына, нәрсә күргәннәрен һәм нәрсә ишеткәннәрен хәбәр итүдән узмый.*

...Юлбашчының иртәдән үк кәефе күтәренке булганга, сводкаларга шаян резолюцияләр куюдан да үзен чикләп тормады. Берлиндагы хәрби атташе генерал Тупиковның, сугыш 22 июньдә башланачак, дип кисәткән яшерен хәбәренә Сталин: «Аңгыра генералга әйтегез, бу – инглизләрнең провокациясе», – дип сызгалап имзасын куйды.

Хәтта Деканозов (РККАда һәм эчке эшләр органнарында үткәрелгән канлы репрессияләрне төп оештыручыларның берсе, 1953 елның 23 декабрендә СССР Югары Судының Хәрби коллегиясе тарафыннан үлемгә хөкем ителгән һәм шул ук көнне атып үтерелгән Владимир Георгиевич Деканозов-Деканозиошвили. 3 нче рангтагы дәүләт куркынычсызлыгы комиссары, 1940 елның 24 ноябреннән СССРның Алманиядәге илчесе. – **Р.З.**)

Ахыры. Башы журналның 7 нче санында.

Исмәгыйль Әхмәтов



И.Әхмәтовның 1984 елда АКШта инглиз телендә дөнья күргән китабы

үзе дә ялган мәгълүматлар ташкынына кушылсын инде! Аның белән нәрсә булды? Ул инде, Деканозовны чакыртып кайтарырга һәм аңа карата тикшерү башларга вакыт җитмәдеме икән, дип, Берия һәм Молотов белән дә киңәште. Һәм нишләп әле һаман Әхмәтовтан бернинди дә хәбәр юк? Исмәгыйль Әхмәтов – НКВДның иң тәҗрибәле ликвидаторы май ахырында Алманиягә җибәрелгән иде. Әгәр дә кирәк булса, ул провокаторларга һәм паникерларга каршы тәвәккәл чаралар күрергә тиеш.

Легаль булмаган резидентлар Әхмәтовның килүе турында ишетүгә төрле якка чәчелделәр: кем – Бельгиягә, кем – Франциягә, ә кайберләре – хәтта АКШка. Алар артыннан куа торгач, Әхмәтов үзе дә Америка Кушма Штатларына барып җитте һәм анда төпләнеп калып, «Сталинның яшерен полициясе» дигән истәлекләрен язарга, дигән карарга килде. Аның китабы 11 басмада бик күп телләрдә басылып чыкты. Сталин әлегә болар турында белми иде. Ә белгәннән соң, аллә ни ачуы кабармады тагы. Әгәр Әхмәтов үз миссиясен үтәп чыкса, 22 июньгә безнең бөтен легаль булмаган разведка челтәрен суеп чыккан булыр иде. Ә аларга ихтыяҗ бик зур булды» (Бунич И.Л. «Гроза». Крововые игры диктаторов. 1997. Интернет. elibra.ru>... groza.-Krovauye-igry-diktatorov.html).

Әлбәттә, Игорь Бунич әсәрендәге әлеге өземтәдә сарказм, усал юмор һәм киная яхшы ук ачык төсмерләнә. Гәрчә утсыз гына төтен чыкмавын да чамаламый мөмкин түгел. Әхмәтов китабының 1984 елда беренче мәртәбә АКШта инглиз телендә дөнья күрүе мәгълүм. Принстон каласында яшәүче татар профессоры Вил Мирзаянов тарафыннан 2007 елдда рус теленә тәрҗемә ителгән шул китабында, элекке хәрби разведчик 1941 елның маенда үзен нинди шартларда Алманиягә җибәрү вакыйгасын да ташка басып калдырган: *«Бу кәгазь битләре Прагадан килгән хәбәр уңаеннан безнең Сталинга язган хисап иде. Әмма бер кәгазь битенә кызыл кара белән аркылы нәрсәдер язылганын күрдем. Анда, «Англия провокациясен тикшерергә! Сталин», диелгән иде. Мин*

кәгазьләрне кире Голиковка (Филипп Иванович Голиков, Кызыл Армия Генштабының Разведка идарәсе башлыгы, генерал-лейтенант. – **Р.З.***) бирдем, ә ул корыч-зәңгәр күзләрен миңа төбәп: «Иптәш Әхмәтов. Мин кушылган тикшерүне үтәүне шәхсән Сезгә тапшырам. Мин бераз соңрак Сезне Алманиягә җибәрергә дә уйлыйм. Тиз арада юлга чыгарга һәм май урталарыннан да калмыйча, Берлинда булырга тиешсез. Мин Сезгә, алдагы «түбә»гезгә алмашка, ТАСС Бюросы җитәкчесе сыйфатындагысын, икенчесен оештырдым. «Түбә» белән бәйле детальләрне төгәлләгез, бүлегегездә һәм персонал эшләрегездә тәртип урнаштырыгыз», – диде».* (Ахметов И.Х. Служба в сталинском ГРУ и побег из него. Бегство татарина из разведки Красной Армии. Интернет/httr//Iander.odessa.ua/GRU.pdf).

Биредәге өземтәдә Әхмәтовның бүлек башлыгы урынбасары түгел, ә бәлки башлыгы булуы ачык төсмерләнә. Ә бит бездә дөнья күргән белешмәлекләрдә, хәрби разведкага кагылышлы энциклопедияләрдә Әхмәтовның 1940 елдан Кызыл Армия Генштабының Разведка идарәсендә 4 нче бүлек башлыгы урынбасары итеп билгеләнүе раслана. Әмма ул үзе башкачарак мәгълүмат китерә. 1940 елның августында Генштаб академиясен «бик яхшы» билгеләренә генә тәмамлап, «инженер-майор» званиесе алып чыккан Исмәгыйль Әхмәтовны Кызыл Армия Генштабының Разведка идарәсе башлыгы Ф.И.Голиковка чакырталар. Шул уңайдан, милләттәшебез китабының «Багышлама» дигән өченче кисәгеннән бер мөһим өземтә: *«Голиков мине техник шпионаж белән шөгыльләнүче 4 нче бүлек башлыгы вазыйфаларын башкаручы итеп билгеләүләре турында әйтү өчен шактый озак вакыт сарыф итте. Мин киләсе көннән эшкә тотынырга тиеш булдым»* (Шунда ук).

Аның үз туган көнен 1904 елның 17 июне дип күрсәтүе дә рәсми чыганакларда китерелгән датадан аерыла. Әйткәндәй, Исмәгыйль Әхмәтов – Орск каласындагы Татар урамында яшәүче 6 балалы гаиләдә иң өлкәне, этисе – Хөсәен, әнисе – Фатыйма. Кайбер чыганакларда ул ГРУ полковнигы буларак телгә алына, шуңа да карамастан, бу мәсьәләдә аның үз китабының кереш өлешендә ташка басып калдырганына өстенлек бирү хәерлерәк булыр: *«Мин, Төркиядә Истанбул каласында дипломат «түбәсе астында» нацистлар Алманиясенә каршы операцияләр үткәрү бурычы куелган ГРУ подполковнигы, соңрак Сталин һәм үземнең хезмәттәшләрем белән араны өздем»* (Шунда ук).

Шулай итеп, энциклопедиягә кертелгән 18 татар хәрби разведчигының язмышларын барлап чыктык. Ахырдан, бу санның да соңгысы түгеллеген ассызыклау мөһим, ягъни ачыкланмаган югары чиндагы татар хәрби разведчиклары тагын да бар әле. Бер генә мисал итеп, полковник Гыйндулла Гатиатулла улы Гатиятуллинны китерергә мөмкин. Әлегә каһарман милләттәшебез турында мәгълүмат бик аз. Аның 1901 елда Башкортстанның Уфа районына керүче Нурлы исемле татар авылында 1901 елда тууы, 1919 елдан хәрби хезмәттә булуы, 1943 елдан Бөек Ватан сугышында катнашуы билгеле. Милләттәшебез Ленинград фронты штабының Разведка бүлегендә 3 нче отделение (диверсия) башлыгы, Ленин, Кызыл Байрак, I дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән. Полковник Гатиатуллинга бирелгән кыскача бәяләмә: «Разведка-диверсия төркемнәре әзерләүне һәм аларны дошман тылына ташлауны оста оештыра. Дошман турындагы кыйммәтле разведка мәгълүматларын вакытында җиткереп тора».

Хәрби разведка полковнигы Гыйндулла Гатиятуллин турында булган бөтен мәгълүмат әлегә шушы. Күренә ки, бу юнәлештә Мәскәүләрдән калышмыйча, алардан үрнәк алып, үзебезгә дә эшлисе дә эшлисе әле!.. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

«Ватан намусы өчен» исемле газетаның беренче саны 1942 елның 10 декабрендә Воронеж фронтында чыга башлый. Газета авыр һәм каты сугышлар белән данлы тарихи юл уза: Воронеж-Киев-Житомир-Тернополь-Львов-Берлин-Прага-Вена. Аның җаваплы мөхәррир урынбасары итеп шагыйрь, капитан Әхмәт Ерикәй, хәрби корреспондентлар итеп – шагыйрьләр Гали Хуҗи һәм Әхмәт Юныс, корректор итеп Әнвәр Ямангулов билгеләнә. Газета атнага ике тапкыр башта ике битле, 1944 елның 11 апреленнән дүрт битле булып басыла. Язучы, сержант Риза Ишморат газета редакциясенә 1943 елның 20 февралендә

Безнең иң үткен
һәм иң көчле корал

Әлфия Шамова

Ватан намусы өчен
Сугышчының законы
Үз эшләреннән мастерлары
Совет Информбюросыннан
Совет Ватаныбыз өчен!
Ватан намусы өчен
„Үлгән солдатлар яшьләргә үрнәк күрсәтер"
Вена шәһәрен азат итүгә бер ел
һөҗүм уңышларын ныгытып беркетергә.
(И. Сталин)
Ватан намусы өчен
Политик пропаганданың сыйфатын югарырак!
Фронтыбыз батырлары
Совет Информбюросыннан
Үч алуга чакыручы хат

М.Садри Рейхстаг янәшәсендә. 9 май, 1945 ел

Дәвамы. Башы журналның 9 нчы санында.

килә, ләкин штат тулы булгач, ул штаттан тыш кына эшләп йөри. 1943 елның апрелендә Ә.Юныс, көчле авырудан соң, бөтенләйгә Казанга кайта, ә 1 июльдән, Ә.Ерикәй резервка киткәч, газетада мөхәррир вазыйфасын Р.Ишморат башкара. 1944 елның февралендә газетага хәрби корреспондент булып шагыйрь, техник-лейтенант Мөхәммәт Садри, майда фронтның алдынгы сызыгыннан, миномётчы булып сугышкан җиреннән язучы, старшина Госман Бакир, ноябрьдә язучы Газиз Иделле һәм «Кызыл Татарстан»нан журналистка Фатыйма Галиева редакциягә иҗади командировкага килә.

1943 ел, 7 гыйнвар. «Татарстанда» дигән рубрика астында соңгы яңалык урнаштырыла: *«Республикабызның бөек патриотизм хисе белән сугарылган колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары «Татарстан колхозчысы» дигән танклар колоннасы төзү өчен средстволар җыюга кереште. Алар үзләренең саклык акчаларыннан 100 000 000 сум кертте инде. Средстволар керү дәвам итә. Азатлык сөюче татар халкының бу яңа ел бүләге немец оккупантларын тәмам җиңү көнен якынайтуда данлыклы Кызыл Армиягә ярдәм итсен»*.

Алга таба «йөгереп» шуны әйтәсем килә: тарихтан билгеле ки, Татарстан халкыннан җыелган акчага җитештерелгән беренче танк колоннасы «Татарстан комсомолы», икенче танк колоннасы «Татарстан колхозчысы» – 200 Т-34 танкы – 1943 елның май аенда 10 нчы танк корпусына бүләк итеп бирелә. Корпусның командующие, **генерал-лейтенант Василий Бурков** – Татарстанның Алабуга районы Кураково авылында туган шәхес. Корпус сугышчылары Прохоровка авылы янындагы хәлиткеч бәрелешләрнең берсендә, иң алгы сафта сугышып, җиңүгә ирешәчәк.

Өченче танк колоннасы «Кызыл Татарстан»1944 елның язында 23 нче танк корпусына бүләк итеп бирелә. Корпус командиры – якташыбыз, **генерал-лейтенант Алексей Ахманов**. Бу танклар сугышта беренче тапкыр 1944 елның җәендә Яссы-Кишинёв операциясендә катнаша, Будапешт шәһәрен азат итә.

Татарстан хезмәт ияләренең фронтка күрсәткән зур ярдәмнәре турында 23 нче танк корпусыннан 1945 елның апрелендә болай дип яздылар: *«Безнең танкистлар меңнәрчә километр юл үтте, дошманның 460 танкысын һәм бик күп санда самолёт, орудие һәм җанлы көчен юк итте. Сугышларда күрсәткән батырлыгы өчен безнең корпусның 71%ы орденнар белән бүләкләнде һәм 73 кешегә Советлар Союзы Герое дигән югары исем бирелде. Алар арасында якташларыбыз: лейтенант, мотоукчы бригаданың автоматчылар взводы командиры Зариф Алимов һәм 23 нче танк корпусы командиры генерал-лейтенант Ахманов»*.

1943 ел, 23 февраль. Бу сан 4 битле булып чыга. Анда Г.Хуҗиның «Исемсез каһарманнар» исемле поэмасы, Ә.Ерикәйнең «Татар егетләре» исемле очеркы дөнья күрә.

1943 ел, 28 март. «Татарстанда» сәхифәсендәге соңгы яңалыклар: *«Орденлы Татарстан АССР эшчеләре, колхозчылары һәм интеллигенциясе «Совет Татарстаны» дигән сугыш самолётлары эскадрильялары төзүгә 100 миллион сум акча җыеп, Дәүләт банкасына кертте.*

Татарстан хезмәт ияләре Ватан сугышы чорында оборона фондына 39 миллион сум акча һәм 12 миллион сумлык дәүләт заёмнары облигацияләре җыеп тапшырды, фронтовикларга 29 миллион сумлык бүләк җибәрде. Бу бүләкләр арасында туклану продуктлары гына да 33270 пот исәпләнә. Фронтка 23000 кыска тун, 54000 пар киез итек, 59000 пар телогрейка һәм чалбар, 106 000 пар җылы күлмәк-ыштан һәм бик күп санда башка җылы әйберләр җибәрелде. Болардан тыш, республикабызның колхозчылары 61141 килограмм йон һәм 97320 сарык тиресе җыйды.

«Ватан намусы өчен» газетасы редакциясе хезмәткәрләре. 1945 ел

Республикабызның комсомолецлары һәм яшьләре, үзләренең шәхси средстволары исәбенә, сугыш самолётларыннан торган өч эскадрилья («Комсомолец Татарии», «Казанский комсомолец», «Зеленодольский комсомолец») төзеп, Кызыл Армиягә тапшырды.

Дошманны тәмам тар-мар итү көнен якынайту өчен, хезмәт сөючән татар халкы, илебезнең барлык хезмәт ияләре белән берлектә, үзенең фронтка ярдәмен тагын да арттырачак».

1943 ел, 8 апрель. Ә.Ерикәйнең «Мин кызганмыйм» исемле шигыре, драматург Таҗи Гыйззәтнең «Ватан сугышы чорында татар совет сәнгате» дигән мәкаләсе дөнья күрә.

1943 ел, 8 август. *«Орёл һәм Белгород юнәлешләрендә булган сугышларның бер ае эчендә Кызыл Армия дошманның 120000 солдат һәм офицерын үтерде, 4605 танкысын, 1623 орудиесен, 11000 автомашинасын җимерде һәм юк итте, 2492 самолетын бәреп төшерде».*

1943 ел, 15 сентябрь. *«Быелның 23 нче февралендә 56 нчы гвардияче укчы дивизиядәге 254 нче гвардияче укчы полкның гвардия рядовое Александр Матвеевич Матросов Чернушки авылы өчен сугышта немецлар дзотының амбразурасын үзенең гәүдәсе белән каплый һәм дошман пулемёты шул полк сугышчыларының һөҗүменә комачаулый алмый».* (А.Матросовның чын исем-фамилиясе – Шакирҗан Юныс улы Мөхәммәтҗанов. Ул Башкортстанның Учалы районы Кунабай авылында туа. – **Ә.Ш.**)

1943 ел, 20 октябрь. «Изге теләкләрегезне үтәрбез» исемле хат, Татарстан Өлкә Комитеты секретаре Хәбир Пазиковның «Бөтенесе дә җиңү өчен!» дигән мәкаләсе, Мирсәй Әмирнең «Бабайлар» дигән кыска язмасы, Кави Нәҗминең «Муллануp Вахитов» исемле мәкаләсе дөнья күрә.

1943 елның 20 октябрендә Воронеж фронты үзенең тарихи яшәвен төгәлләгәч, «Ватан намусы өчен» исемле газета редакциясе Беренче Украина фронты карамагына күчә.

1943 ел, 16 ноябрь. Фатих Кәримнең «Совет солдаты» дигән шигыреннән бер өзек:
Башны саклый торган каскалардан
Җилкәләргә салкын су ага;
Манчып алган кебек, шинельләрнең
Салмак итәкләрен җил кага.

Гранаталар билдә, капчык иңдә,
Анда патрон, анда запаллар;
Иң башларын кисә капчык бавы,
Тирле аркалардан калка пар.

Кызганмыйбыз көчне, яшь гомерне,
Кызганмыйбыз кирәк урында;
Ут давылын ерып үтәрбез без
Илне азат итү юлында.

1943 ел, 19 ноябрь. 21 яшьлек татар егете Советлар Союзы Герое бронебойщик Габдулла Вәлиев фотосы, Гали Хуҗиның «Гармун» дигән шигыре басыла.

1943 ел, 12 декабрь. Өлкән лейтенант Г.Хуҗиның «Фәйзулла Әһлетдинов» исемле очеркыннан бер өзек: «*Сержант Ф.Әһлетдинов төнлә бер төркем сугышчылар белән Днепрны кичеп чыкты һәм уң як ярга беренчеләрдән булып аяк басты. Ул граната белән дошманның станоклы пулемётын җимерде, 18 солдатны һәм 3 офицерны дөмектерде.*

Таң алдыннан немецлар өч тапкыр контратакага ташланды. Кул сугышында Әһлетдинов яңадан 12 немецны теге дөньяга җибәрде. Ул, каты яралангач та, төп көчләребез килеп җиткәнчегә кадәр, сугыш кырыннан китмәде. Совет хөкүмәте татар егете Әһлетдиновның батырлыгына югары бәя бирде. Хәзер ул – Советлар Союзы Герое».

1944 ел, 18 гыйнвар. Г.Хуҗиның «Хатип Хәсәнов – Советлар Союзы Герое» исемле очеркыннан бер өзек: «*Т. авылы өчен каты сугыш барганда Хәсәновның пулемёт расчёты 84 фашистны юк итте. Гитлерчылар сугышка яңадан ике полкка якын пехота һәм 36 танк кертте. Бу вакытта Хәсәнов гранаталар белән тагын 30дан артык гитлерчыны кырып ташлаган иде. Таң алдыннан батальон дошман өстенә һөҗүмгә әзерләнде. Батальон авылга барып кергәндә Хәсәнов 67 фрицның башына җиткән иде.*

Август көннәренең берсендә Хәсәнов үзенең «Максим»ы белән 30дан артык гитлерчыны кырып ташлады. Ул каты яраланды, ләкин сугыш кырыннан китмәде. Немецларның ярсу атакасын озак вакытлар буе берүзе кире кайтарды. Патроннары беткәч һәм ул аңын җуйгач кына, гитлерчылар аны чолгап ала алды. Канга манчылган Хәсәновны немецлар, ерткычларча кыйный-кыйный, авылга сөйрәп алып кайта. Хәсәновтан бер сүз дә ала алмагач, ачулары соңгы чигенә җиткән фашист-палачлар аның башын кисә. Коммунист-сугышчы Хатип Хәсәнов әнә шулай һәлак булды».

1944 ел, 11 апрель. Капитан Риза Ишморатның «Рәхмәт сезгә, кадерле кунаклар!» дигән мәкаләсе (Татарстаннан фронтка килгән артистлар концерты турында), М.Садриның «Без җырлыйбыз» исемле шигыре басыла.

1944 ел, 6 июль. «Курск дугасындагы сугышларның геройлары» рубрикасы астында гвардия өлкән сержанты, Советлар Союзы Герое Хәмзә Мөхәммәдиев рәсеме басыла һәм «*Советлар Союзы Герое Фәррах Камалетдинов дошманның 43 танкысын юк итте, йөзләрчә солдат һәм офицерларын кырып ташлады*», – дип язылды.

1944 ел, 9 август. «Беренче Украина фронтындагы татар сугышчыларыннан татар халкына җавап хаты» басыла. Аңа барлыгы 2 меңнән артык кеше кул куя.

1944 ел, 8 сентябрь. «Совет солдаты» исемле очерк басыла. Аның авторлары – М.Садри, В.Ераносян һәм Г.Хуҗи. Анда Советлар Союзы Герое гвардеец Сәлимҗан Галимҗанов турында языла.

1944 ел, 7 октябрь. Капитан Г.Хуҗи, өлкән техник-лейтенант М.Садриның «Менә безнең якташ» (Нияз Зарипов турында) исемле очеркы басылып чыга.

1944 ел, 12 октябрь. М.Садри, Г.Хуҗи һәм А.Ивановның «Бу – үч көче» (старшина, пулемётчы Габдулла Вәлиев турында) дигән очеркы дөнья күрә.

1944 ел, 24 ноябрь. Госман Бакировның «Ут» исемле очеркы (Орудие командиры миномётчы өлкән гвардия сержанты Сәгыйть Нуретдинов турында), М.Садриның яшь сугышчыларга ярдәмгә – «Танкка каршы кулланыла торган мылтык» исемле мәкаләсе басыла.

1944 ел, 27 ноябрь. Г.Иделленең «Совет офицеры» дигән очеркы (Советлар Союзы Герое Әхмәдулла Ишмөхәммәтов турында), Таҗи Гыйззәтнең «Үч алырга чакыручы җырлар»ы дөнья күрә.

1945 ел, 7 апрель. «Татар халкына җавап хаты» (Икенче Белоруссия фронтының татар сугышчыларыннан җавап хаты. Бу хат шигырь белән язылган. Аның авторы – Шәрәф Мөдәррис. Хатка 4000нән артык кеше кул куйган) урнаштырыла.

1945 ел, 6 май. Риза Ишморатның «Берлинда» исемле мәкаләсендә болай языла: *«Менә ул фашист еланнар оясы, мең кәррә ләгънәтләнгән Берлин... Аның өстендә безнең җиңү байрагыбыз җилферди, ә һәр өйнең капкасына, тәрәзәләренә ак флаглар эленгән. Урамнарда немецлар үтеп йөриләр. Алар кулларына ак чүпрәкләр бәйләгәннәр. Болар барысы да – җиңелү, буйсыну билгесе.*

Моннан соң инде, башлары киселгән немец еланнар бервакытта да башларын күтәрә алмаслар».

1945 ел, 9 май. Г.Бакировның «Казан егете» (Сапёр Мөбарәк Хәсәнов турында) исемле очеркы, Г.Хуҗиның «Солдат» исемле шигыре дөнья күрә.

9 майда капитан М.Садри Берлиннан Җиңү турында материал алып кайта һәм Рейхстаг диварына: «Без җиңүчеләр булып Берлинга килеп җиттек!» – дип язып калдыра һәм Рейхстаг янында фотога төшә.

«Ватан намусы өчен» исемле фронт газетасы 1946 елның 3 июненә кадәр чыга (барлыгы 378 саны дөнья күрә).

Газета битләрендә Р.Ишморатның «Ленин ордены», «Гвардия майоры Бәдретдинов», Г.Иделленең «Якташыбыз Гәрәевнең батырлыклары», «Минзәлә егете» (Батарея командиры Салих Гатин турында), М.Садриның «Советлар Союзы Герое – Әнвәр Кәлиев», «Атаклы гармунчы Фәйзулла Туишев», «Сугыш осталары», «Арыслан баласы» исемле очерклары, «Сержант Ильясов һөҗүм итә», «Артиллеристлар», «Сапёр Мәхмүт Газизов», «Разведчик Касыйм Садыйков» дигән мәкаләләре, «Ай хикәясе» исемле баллада, «Каһарман дус» дигән поэма, Гали Хуҗиның «Россия», «Яу күрке» исемле поэмалары, очерклар һәм шигырьләр дөнья күрә.

Бу газета битләрендә Һ.Такташ, М.Җәлил, Ф.Кәрим, Ә.Юныс, Г.Бакир, К.Нәҗми, Ә.Ерикәй, Ш.Маннур, Ә.Фәйзи, Г.Кутуй, Ш.Мөдәррис, С.Баттал, С.Урайский кебек әдипләрнең әсәрләре дә басыла.

Фронт частьларында хезмәт итүче һәм газетага язышып торучы өлкән лейтенант Мостафа Ногман, лейтенант Мостай Кәрим, гвардия өлкән сержанты Гыйлемдар Рамазанов, кызылармеец Шәриф Сайкин шигырьләре дә урын ала. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

Халыкка кайтарылган исем...

Гөләндәм Давыдова,
Мамадыш районы төбәкне өйрәнү музееның фәнни хезмәткәре

Узган гасырның 20нче-30нчы еллары безнең төбәк тарихында гына түгел, ә илкүләм иң авыр еллар булып санала: Гражданнар сугышы, ачлык, колхозлаштыру, репрессия... Шуның өстенә, байлар һәм ярлы сыйныф арасында көрәш бара. Илгә белемле кешеләр җитми. Республика, райком, кантон белән идарә итү бик авыр шартларда бара. Җитәкчеләргә һәрнәрсәдә үзләренә «юл салып», башлап йөрергә туры килә. Шундыйларның берсе – Рәүф Әхмәт улы Сабиров. Ул иң авыр елларда Мамадыш өязе, ә аннан соң исә Мамадыш кантоны Башкарма комитеты рәисе булып тора.

Якташыбыз берничә ел ТАССР Үзәк башкарма комитеты рәисе вазыйфасын башкара, аңа Мәскәү Үзәк комитетында да эшләү насыйп була. Әмма, ни

кызганыч, Рәүф Сабиров репрессияләнә һәм 1937 елда атып үтерелә. Аның исеме халыкка бары тик 1990 елда гына кире кайтарыла... Сикәлтәле тарих юлларында һәрчак башлап йөргән, кая куйсалар да үз вазыйфасын намус белән үтәгән якташым турында киң җәмәгатьчелеккә белдерәсем килә.

ТӘҮГЕ АДЫМНАР

Рәүф Әхмәт улы Сабиров 1894 елда Мамадыш өязенең Айдар (хәзер Теләче районына карый) авылында дөньяга килә. Үз авыл мәктәбендә бераз белем алгач, Рәүф күрше Сатыш авылында мәдрәсәдә укый. Бераз акча юнәтү исәбе белән ул, әти-әнисен калдырып, Түбән Новгород шәһәренә чыгып китә, анда бераз кара эшләрдә эшләгәннән соң, Екатеринослав шәһәрендә тоз бораулаучысы булып эшли. Озакламый Беренче Бөтендөнья сугышы башлана һәм аны солдатка алалар, ә 1915 елның башында Герман фронтына озаталар. Өч ел эчендә сугышның бар авырлыгын кичергән, салкын окопларда ятып, күп кенә иптәшләрен югалткан, гаделсезлекләрне күреп дөньяга «күзе ачыла» башлаган егетне 1918 ел башында, 170 нче пехота дивизиясе делегаты итеп, Казанга съездга җибәрәләр. Большевиклар партиясе әгъзасы булып тормаса да, Рәүф Сабиров тулысынча алар позициясен яклап чыга һәм большевиклар белән бергә съездны ташлап чыгып китә. Ул инде яңадан фронтка әйләнеп кайтмый, ә «совет» идеяләре белән канатланып, туган ягына – Мамадышка кайта.

Яңа тормыш, яңа үзгәрешләр аны үз эченә бөтереп алып кереп китә. Рәүф Сабиров , беренче эше итеп, шәһәрдә оешып килүче большевиклар партиясенә керә, аның җитәкчесе Александр Давыдовның уң кулына әйләнә, Өяз мөселман комитетын оештыруда катнаша. 1918-1921 елларда татар педагогик курсларында укыта.

Җаны-тәне белән яңа тормышка бирелгән егетне якташлары 1919 елның апрелендә Мамадыш Өяз башкарма комитетының рәисе итеп сайлыйлар. (Бу вазыйфасында ул 1921 елның июненә кадәр тора.) Нәкъ шул көннәрдә Нократ елгасы яр буена адмирал Колчак гаскәрләре килеп җитә. Рәүф Сабиров бөтен көчне аңа каршы туплый. Меңнәрчә чакрым юл үтеп, бер тапкыр да җиңелмичә, безнең өяз чигенә хәтле килгән Колчак армиясе беренче җиңелү ачысын шунда татый. Миңа калса, шундый зур гаскәрне җиңүдә Беренче Бөтендөнья сугышында чыныгу алган, куркусыз, оештыру сәләте көчле булган Рәүф Сабировның роле бик зур. Тик сөенергә иртәрәк, авырлыклар әле башлана гына.

1920-1921 еллар яшь Татарстан Республикасы тарихына рәхимсез ачлык еллары булып кереп калган. Мамадыш өязендә дә ачлык хөкем сөрә. Кешеләрнең кайберләре урамнан барган уңайга егылып үләләр. Бигрәк тә кечкенә балалары булган гаиләләргә авырга туры килә. Балалар бакчалары, мәктәпләр ябыла. Шуның өстенә, өяздә дә, Мамадыш шәһәрендә дә холера, тиф кебек йогышлы авырулар тарала. Рәүф Әхмәт улы җитәкчелегендәге Өяз Башкарма Комитеты, ачлыкка каршы берләшергә, бердәм көрәшергә чакырса да, халык инде бу фәрманга буйсынмый: атлары булганнар – атларын суя яки бик кыйммәт бәягә сата башлый. Авыл кешеләре гаиләләре белән шәһәргә килеп тулалар, урлашу киң тарала. Ә шәһәр кешеләре,

киресенчә, эш урыннарын үз билгеләре белән ташлап, чит өлкәләргә «яхшы тормыш» эзләп чыгып китәләр... Кайбер авылларда коралллы чуалышлар башлана, фетнәләр кабына.

Рәүф Сабиров соңгы чараны куллана: өяздә хәрби хәл кертелә. Аның карары нигезендә, төнге бердән соң урамда йөргән кешеләр кулга алына һәм суд хөкеменә тапшырыла. Мамадыш шәһәрендә һәм авылларда, амбар тирәләрендә төркем-төркем булып җыелып торулар катгый тыела, ризасызлар кулга алына. Авырлык белән булса да, кантонда тәртип урнаша.

Бу сынауны зур сабырлык белән кичкән, кантонны ачлык хәленнән тиз арада чыгара алган Рәүф Сабировны ТАССРның Үзәк комититетында да күреп алалар һәм 1921 елның июнь аенда безнең якташыбыз ТАССР Үзәк башкарма комитеты рәисе итеп сайланыла. Бу вакытта аңа нибары 27 яшь була!

«ОЧЫШ» ЧОРЫ

Билгеләнүенең беренче көненнән үк, Рәүф Әхмәт улы үзен талантлы җитәкче итеп күрсәтә. Ул Үзәк башкарма комитеты алдына халык хуҗалыгын торгызу, тыныч юл белән республикакүләм зур уңышларга ирешү бурычын куя. Авыл хуҗалыгында, сәнәгатьтә яңа үрләр яулауга зур игътибар бирелә, мәдәният өлкәсендә эшләүчеләр алдына да аерым бурычлар куела. Рәүф Сабиров һәр өлкәдә эшләүче җитәкчеләрнең докладларын тыңлау белән генә чикләнми, еш кына үзе дә халык арасына чыга, съездларда кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшерә, республиканың халык хуҗалыгы белән идарә итү эшен берләштерә.

Якташыбызның армый-талмый эшләве, дөрес җитәкчелек итүе үзенең нәтиҗәсен озак көттерми: яшь Татарстан Республикасы ачлыкны җиңә: авыл хуҗалыгы торгызыла, үткәрелгән яңа экономик политика (НЭП) уңышлы чыга. Вакытлыча ябылган предприятиеләр ачыла, яңа завод-фабрикалар төзелә һәм эшли башлый. Ул вакыттагы халык хуҗалыгы торышын анализлаган бүгенге көн галимнәребез фикере буенча, ТАССР Үзәк башкарма комитеты рәисе булып Рәүф Сабиров торган еллар – республика тормышында халык хуҗалыгы һәм мәдәният өлкәсендә зур уңышларга ирешү, алгарыш чоры булып кереп калган.

Рәүф Сабиров тарафыннан 1923 елны язылган «Татарстан Республикасы авыллары ачлыктан соң» дип исемләнгән китапта әлеге елларның фаҗигасе җентекләп күрсәтелә. Ул анда гаилә-гаилә белән үлүләр, исән калганнарның «бәхетле тормыш» эзләп чит өлкәләргә китүләре аркасында авылларның юкка чыгуы, мал-туар үлүе, «кеше ашаучылык»ның киң таралуы сәбәпләрен атый, чыгу юлларын билгели һәм тиз арада НЭПны кертү кирәклеген ассызыклый.

Янә шунысын әйтү мәслихәт: Рәүф Сабиров Владимир Ильич Ленин белән дә якыннан таныш була: килеп туган төрле мәсьәләләр буенча ул турыдан-туры аңа мөрәҗәгать итә һәм күп очракта алар уңай чишелә. Кайбер сораулар Мәскәүдә Политбюро каравына тапшырыла, бу исә Рәүф Сабировның зур даирәләрдә танылуына китерә.

Башта ТАССР Үзәк башкарма комитеты рәисе, ә аннан инде Үзәк башкарма комитеты Президиумы рәисе булып якташыбыз 1924 елгача тора, аннан аны тагы да югарыга күтәрәләр, Мәскәүгә алалар һәм СССР Үзәк башкарма комитетында милли мәсьәләләр буенча җитәкче урынбасары итеп сайлап куялар.

ЯЗМЫШ СЫНАВЫ

Аяныч ки, 20 нче еллар ахырында йөз меңнәрчә гомерне өзгән «репрессия машина»сы эшли башлый, аның тәгәрмәче астына беренчеләрдән булып «милләтчелектә» гаепләнгән күренекле татар зыялылары, галимнәре, җитәкчеләре эләгә. «Солтангалиевчелектә» гаепләп, 1929 елда Рәүф Сабировны да кулга алалар, партиядән чыгаралар. Бу хәлләрнең башында мондый тарихи вакыйга тора: 1923 елны, әле Үзәк башкарма комитеты рәисе булган вакытында, ул партия җыелышында Солтангалиевне яклап чыга. Рәүф Сабировка нинди генә яла ягылмый?! Аның «эше»ндәге «гаепләрен» санап үтик: «советка каршы актив өндәүче, милләтчелектә башлап йөрүче, Япония шпионы, террор оешмасында торучы...». Шуның өстенә, аның биографиясендә дә казынып, янә бер гаеп табалар – мулла малае булган, социаль чыгышын яшергән, диләр. Чынлыкта, аның әтисе гади крестьян була, бары тик намаз вакытында манарага менеп азан гына әйтә. Рәүф Сабировның мәдрәсәдә белем алуы да зур гаеп итеп исәпләнелә.

Якташыбызны беренче көннән ук авыр шартларда тоталар, кеше чыдамаслык җәзаларга дучар итәләр, туктаусыз кыйныйлар. Берничә айга сузылган сорау алулардан соң, Рәүф Сабиров «сына», кайбер гаепләрне таный һәм аңа «халык дошманы» исеме тагыла.

Ике ел төрмәдә һәм лагерьда ябып тотканнан соң гына аны иреккә чыгаралар. Әмма ул инде үзенең җитәкчелек эшенә кайта алмый, Мәскәүнең автомобильләр эшләү заводы – «ЗИС»ка гади эшче – фрезеровщик булып урнаша. Талантлы кеше бар җирдә дә талантлы, югалмый, яңа үрләр яулый. Рәүф Сабиров монда да зур уңышларга ирешә, иң алдынгы фрезеровщик исемен ала, аннан аны катлаулы станоклар җыю эшенә куялар, бер-ике елдан бригадир итеп билгеләнә. Рәүф Сабиров «тумыштан ук» җитәкче булган күрәсең, аны заводның профсоюз комитеты әгъзасы итеп сайлап куялар, ул социалистик ярышлар оештыруда башлап йөри, эшчеләр арасында зур ихтирам казана.

Сабиров техника өлкәсендә югары белем алырга хыяллана, үзен тулысынча автомобильләр җитештерү эшенә багышларга уйлый.

Ләкин...1937 елда яңадан югары күтәрелгән якташыбызны икенче тапкыр кулга алалар. Бу вакыттагы репрессияләр башында 1921 елда Рәүф Әхмәт улы белән бергә ТАССР өлкә комитетында эшләгән Николай Ежов тора. Алар төрле мәсьәләләр буенча еш кына бәхәскә кергән булалар һәм бу бәхәсләрдә һәрчак Рәүф Сабиров өстен чыга. Үз сүзен курыкмыйча әйтә алган татар егетеннән Н.Ежов еллар үткәч «үч ала», репрессия ачысын бер тапкыр кичергән якташыбызны кабат кулга алдыра. Яңадан сорау алулар, кыйнаулар, җәзалаулар башлана... Бу елда кулга алынган бер генә «халык дошманы» да, мөгаен, исән калмагандыр: Рәүф Сабиров та, шул елның 30 нчы декабрендә тәмам кешелектән чыгарылып, атып үтерелә.

Мамадыш өязенең бер авылында туып, мәдрәсәдә белем алган, окопларда сугыш авырлыгын кичергән, бөтен республика күләмендә ачлыкны җиңүгә ирешкән, башта Мамадыш өязе, аннан Мамадыш кантоны башкарма комитеты оәисе, ТАССР Башкарма комитеты президиумы рәисе дәрәҗәсенә ирешкән, Мәскәү Үзәк комитетында эшләгән, В.И.Ленинның Татарстандагы ышанычлы көрәштәше булган Рәүф Сабировның гомере шулай өзелә. Күп кенә репрессия корбаннары кебек, аның да кабере билгесез. Соңлап булса да «исеме акланган» якташыбызны онытырга хакыбыз юк... ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

«Түгәрәк уен» фестивалендә музыка кораллары

Мандолина

Эльмира Каюмова

Камилә Каюмова фотосы

Илһамия Кутусова «Түгәрәк уен» фестивалендә чыгыш ясый. Казан Кремле. 2017 ел

Кыллы музыка уен кораллары татарларда (һәм борынгы бабаларыбыз – кыпчакларда) элек-электән кулланылган. Мандолинаның килеп чыгышы Италиядән дип санала. Ул лютня нигезендә барлыкка килә. Ләкин лютня үзе Европага Шәрык илләреннән күчә: археологик чыганаклар буенча, лютня сыман коралның ватаны – Месопотамия (хәзерге Гыйрак, Сүрия, Иран һәм Төркия җирлеге), туган вакыты – безнең эрага кадәр 4-2 мең ел элек.

Мандолина Россиягә 1770 елларда, ә татар музыкаль мәдәниятенә XIX гасыр ахырында килеп керә. Шәһәрләрдә кыллы оркестрлар оешкач, аларның чыгышлары халыкта зур кызыксыну уята. Бөек шагыйребез Габдулла Тукай да мандолина тавышын сәгатьләр буе тыңларга яраткан.

1990-2010 елларда, әлеге коралда уйнаучылар, сирәк булса да, Мөслим, Апас, Кукмара, Түбән Новгород якларында әле очрый иде. Башкаручыларның барысы да диярлек – мөгаллим булып эшләгән кешеләр (моны экспедиция материаллары исбатлый). Андый үзенчәлекнең сәбәбе шунда ки, совет чорында педагогия көллиятләрендә мандолинада уйнау аерым дәрес буларак кергән. Бүгенге заманда

Камилә Каюмова фотосы

«Түгәрәк уен» фестивалендә. Уңда – Илһамия Кутусова, янәшәсендә – Э.Каюмова, сулда – Сарман районы музыкантлары. Казан Кремле. 2017 ел

Э.Каюмова фотосы

Кәүсәрия Муллина. Кукмара районының Төркәш авылы. 2014 ел экспедициясе

мандолинада уйнарга өйрәтмиләр, дәресләр бетерелде, башкару традициясе дә сүнеп бара. Димәк, халык музыка уен коралларын (гомумән – этник традицияләрен дә) саклау һәм яшәтүдә укыту оешмалары искиткеч зур роль уйныйлар. Тарихи фактлар шул хакта сөйлиләр, үткәннәрнең сабакларын исәпкә алсак иде!

Минем уйлавымча, мандолинаның халык арасында таралуы очраклы түгел. Ул элеккеге чиртмә музыка уен коралларының дәвамчысы, югалган думбыраны алыштырган. Татарстан Республикасының Кукмара районы Төркәш авылында Кәүсәрия Муллинаны (1950 елгы, пенсиягә хәтле укытучы булып эшләгән) яздырганда, мандолина көйләрендә думбыра яңгырашы бик ачык сизелә иде.

Хәзерге вакытта мандолинада уйнаучылар бик аз. Шуларның берсе – Илһамия Кутусова (1965 елгы), ул Сарман районы Зур Нөркәй авылында гомер кичерә. Илһамия аңа 12 яшь тирәсендә 1958 елгы Әлфия апасыннан уйнарга өйрәнгән. Апасы исә мөгаллимлеккә укып чыккан күршесеннән күреп-ишетеп, мандолина чиртә башлаган. Музыка коралын Ленинградтан почта аша кайтарткан булган. Авылларында берничә кеше уйнаган. 1960-1970 елларда олырак кызлар урамда, капка төбендә җыелып, мандолинага җырлап утыралар иде.

Илһамия ханымның иң беренче үзләштергән көе – «Там, там, тамчы, там» (җиңел һәм өйрәнергә җайлы). Соңрак Казандагы химия-технология институтына укырга кергәч, мандолинаны үзе белән йөрткән, төрле концертларда катнашкан. Быел Казан Кремле тыюлыгында узган «Түгәрәк уен» фестивалендә дә мандолинада уйнап, күркәм чыгыш ясады.

Мәкаләне әзерләгән чагында, 2017 елның октябрендә Санкт-Петербург шәһәрендә Беренче халыкара мандолина фестивале үткәрелә, дигән хәбәр килеп иреште. Киләчәктә андый югары дәрәҗәле чараларда безнең уенчылар да катнашыр, дигән өметтә калабыз! ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ТАҺИР МУНЧАСЫ – Гомум кабул ителгән фикер буенча, Казан ханлыгы чорында Кирмән диварларыннан ерак түгел, Болак Казансуга кушылган җирдә урнашкан бер зур таш мунчаның исеме. Аның татарчасы русча чыганактан алынган (*«Таирова баня», «Даировы бани», «Даирова (Тахира) зовома»*). 1552 елда Казан шәһәрен Явыз Иван гаскәре штурмлаган вакытны тасвир иткән рус чыганакларында телгә алына. Ш.Мәрҗани дә, Һади Атласи да аны *Таһир мунчасы* дип аңлыйлар шикелле. Ләкин ул чорларда җәмәгать мунчасы кеше (хуҗасы?) исеме белән атап йөртелдеме икән, дигән мөшкел сорау туа. Ихтимал, монда антропонимның асыл мәгънәсен алырга кирәктер. Таһир – гарәпчә *таза*, *ару*, *пакь* мәгънәсендәге сүз. Димәк, бу мунча *ару мунча*, *ак мунча* яки *тәһарәт мунчасы* булырга да бик мөмкин. Башка төрле фараз да бар. *Даир* – «әйләнмәле» мәгънәсендә. Әгәр бу мунча шәрык мунчалары шикелле «бишбармак принцибы» буенча эшләнгән булса, анда юынган вакытта



Казан Кремле. (Билгеләп куелган бина – Таһир мунчасы). Н.Ф.Калинин рәсеме

Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

бер бүлмәдән икенчесенә (эссерәгенә) күчә барып, әйләнеп чыга торган булганнар. Ризаэддин Фәхреддин мунча(лар)ның исемен, тәрҗемә итеп тормастан, *Даировы бани* формасында (күплек санында) куллана. Күплек саны да мунчаның төрле бүлекләрдән торуы турында сөйләргә мөмкин.

Казан алынган вакытларда урыс казаклары әлеге мунча эченә кереп урнашалар һәм кальга тавына таба җир астыннан юл казырга керешәләр (камалыштагы кальгаларның диварын шартлату өчен «тихая сапа» ысулы). Димәк, бу мунчаны шактый зур булган, дип уйларга кирәк. Дженкинсон рәсеменә караганда, беркатлы, күп гөмбәзле бина булган. Ихтимал, төзелеше белән ул Болгардагы «бишбармак принцибы» буенча бина кылынган Ак пулатны кабатлаган булгандыр (XVI гасырның беренче яртысындагы Казан Кремле күренешен сурәтләгән рәсемендә Н.Ф.Калинин да аны бер зуррак үзәк гөмбәз тирәсендә урнашкан дүрт гөмбәзле бина рәвешендә күрсәтә). Мунча XIX гасырга кадәр эшләп килгән.

«Татар энциклопедиясе сүзлеге»ндә (2003) «Даир мунчасы» дип кенә алуны кулай күргәннәр.

ТИПКЕН – Кояш һәм Ай тартуы нәтиҗәсе буларак, диңгез суының тәүлеккә ике тапкыр күтәрелүе, мәд (г.), прилив (бусы русча термин). Елганы бугач яки язгы ташу вакытында суның җәелүе дә *типкен* дип атала, суны бугач,



агымның кирегә борылуын шулай ук *типкен* диләр. «Татар теленең диалектологик сүзлеге» (1993).

Татар теле диалектында бу сүз *кирегә бәрү, тибәреш*, русча *«отпор (бирү)»* мәгънәсенә дә ия.

Техник термин буларак, гидравлик типкен – гидравлический удар (русча).

ТИЯК, ТИЙӘК – 1.Билге өчен утыртылган таш; ташбилге; сәнам. Ыруның корбан чала һәм гел әйләнеп кайта торган урыны. Туган җир, ватан мәгънәсендә дә кулланыла торган сүз. Мал-туар өчен махсус көтүлекләрне

Тияк тәгәрмәче (храповик)

дә тияк дигәннәр. //Сөягем тиягемә кайтсын. Мәкаль. *Алланың рәхмәте: чакырылмаган Мәскәү кунагыннан кадерле тиягем артык зыян күрмәгән, кайсыбер фаҗигале авыллар кебек җир йөзеннән себереп ташланмаган.* Зиннур Мансуров. (Ватандашлар сугышы елларында шагыйрьнең туган авылы Түбән Ушмыга аяусыз революционер Лев Троцкийның килүенә карата.) 2.Киемгә төймә урынына тагыла торган агач таякчык. Кайбер сөйләшләрдә кием элгече. 3.Киндер сугу станы детале – *тыйгыч* яки *тыйгыча/тыйгыча таяк*, русча – *собачка* (башкорт теле диалектында *тормос* сүзе теркәлгән). //Тияк тәгәрмәче – русча: храповик. 4.Суйган терлекне тунау өчен аса торган агач элгеч. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

БОРЫНГЫ ТАТАР ЮЛЛАРЫ

(Ерак чорларга гомуми караш)

Рабит Батулла

Халык исеме буларак, «татар» сүзе язма чыганакларда (борынгы Кытай архивларында сакланып калган кульязмаларда) безнең дәвергә чаклы 209 елда, ягъни моннан 2225-2226 ел элек күренә башлый.

Тарихчы Ма Туван-лин бу мәсьәләдә башка галимнәр белән бәхәскә керә. Ул әлеге халыкның килеп чыгышын борынгырак чорга бәйли. Татарларның шул вакытта ук үзе белән санлашырдай көчкә ия булуын ассызыклый ***(Эдуард Паркер. «Татарларның меңьеллык тарихыннан»)****.*

ДАЛА ХАКИМЕ

Кытай архивында сакланган язмаларда бу халык «татар» дип кенә түгел, «хиенну» дип тә йөртелә. Шуннан соң атама үзгәрешләр кичерә: хунну, кунну, гунну, һуннар. Ләкин кытай телен озак еллар өйрәнгән **Эдуард Паркер «Татарларның меңьеллык тарихыннан»** исемле китабын язганда чыганаклардагы «да-да» атамасын турыдан-туры «татар» дип тәрҗемә иткән.

Борынгы тарихчыларның телләре бер, йолалары бер, яшәү рәвешләре бер булганга, ат өстендә туган, ат өстендә үлгән, киез йортларда, тула тирмәләрдә яшәгән, җылкы ите ашаган, кымыз эчкән күчмә кабиләләрнең барысын да (хиен-нуларны, скифларны, кыргызларны, башка төрк халыкларны) (төркиләрне) «татар» дип атавы мәгълүм.

Аның каравы, «төрк» атамасы язмаларга V гасырда гына килеп керә.

Татар ат сыртында туа, ат сыртында үлә, дигәннәр.

Татар монда туа, еракта үлә, дигәннәр.

Җылкы ите җыймаган, кымыз чөмермәгән татар – татар түгел, дигәннәр.

Атың булмаса, атаң сыртына атлан, дигәннәр. («Сине балачактан ат белән тәэмин итә алмаса, атаңны җик», мәгънәсендә.)

Татарның мендәре – ияр, ястыгы – туфрак, юрганы – күк йөзе, дигәннәр.

Дала кабиләләре оланнарны ау-яу һөнәренә сабый чактан ук өйрәтә башлаган. Балалар башта сарыкка атланып, җәядән ук атып, күсе-тычкан ауларга өйрәнгән. Үсә төшкәч, оланны юаш атка атландырганнар һәм, зуррак җәя биреп, куян, төлке ауларга алып чыкканнар. Тагын бераз үскәч, аңа җитез ат биргәннәр, кулына санай (еракка ата торган) җәя тоттырганнар. Сугыш җәясен тарта алса, үсмер егет яугир санала башлаган.

Яугир – яу ире, сугышчы, дигән сүз.

СУГЫШКА ӘЗЕРЛЕК

Яуга чыгар алдыннан дала-җәйләү кырмыска оясы кебек кайнап торган.

Ун кешегә бер казан, бер чатыр, бер җиңел сандал (ат дагаларга, дага алмаштырырга, башкасына әзерләнгән). Һәр яугиргә ике җәя (берсе – еракка атарга, икенчесе – якын арадагы сугыш өчен), бер садак ук, сөңге, кылыч, хәнҗәр, пәке, озын аркан, җәя кереше, мал эчәгесеннән үрелгән җеп төргәге, өтерге, ике кайрак (берсе – кылыч кайрарга, икенчесе – пәке үткенләр өчен), берничә камыт энәсе, без, сүстән, нечкә каештан, тегәрҗептән үрелгән җеп йомгагы, киез итеккә, күн итеккә олтан салыр өчен балавызланган, сумалаланган тегәрҗеп, олтанлык киез, иләнгән күн бирелгән. Аларның шулай ук ябынып йоклар өчен ябынчасы, ыстаннарда, кунышларда туктап торганда уйнар өчен думбыра, кубыз, сыбызгы-курай, барабан һәм башка, һәм башка исәпсез-хисапсыз әсбаплары да булган.

Бай яугир сугышка өч ат алган. Бер аты арыса, егет хәл җыйган атына атланган. Шулай итеп, төрк-татарлар ерак араларны җен тизлеге белән чабып узган. Яу кирәк-яракларын, чатыр киезен, шаңгыракларны, киергеләрне өченче атка төягәннәр.

Урта хәлле яугир яуга ике ат алган: берсенә атланып җир-ара кичкән, икенчесенә атланып орышка кергән.

Урта хәлледән дә түбәнрәк булса, яугир сыңар атта яу чапкан.

Яугирләргә сугыш алдыннан берәр үгез бирелгән. Шул үгезне суеп, сөякләреннән аерып, итен тозлап, киптереп, каклап, кипкән итне киледә төеп, он ясап, тире-киндер капчыкларга, тулымнарга тутырганнар. Ит оны бозылмаган, ашарга әзерләргә вакыт булмаганда, аны бер савыт чишмә суында болгатып эчеп куйганнар. Шуның белән көне буе тук йөргәннәр.

Җиңел коралланган болгар сугышчысы. X-XIII гасырлар. Таһир Абдул әл-Болгари реконструкциясе

СУГЫШ ҺӘМ СОЛЫХ

Төрк сугышчылары тимер боҗралардан «үрелгән» көбә «күлмәк» эченнән ефәк күлмәк кигәннәр. Яугиргә ук тисә, укны тартып алыр өчен ефәк бик уңайлы булган: ук белән бергә, ефәк тә яугирнең тәненә кергән; ефәкне әкрен генә, сак кына тартканнар – ефәк ертылмаган, аның белән бергә ук та ярадан чыккан.

Көбә өстеннән киез күлмәк кигәннәр. Сөңге яки ук тисә, киез аларның һөҗүм куәтен киметә төшкән.

Җәядән ук атканда яугирләр әүвәл керешне күкрәккә таба тарткан, соңрак колакка таба тарта башлаганнар. Алай иткәндә укның очу аралыгы да, үтерү көче дә арткан.

Сугыш тәмамлангач, дошман як каракаршы утырып солых төзегән, соңыннан ап-ак җылкы чалып, уртак табын ясаган.

БАЛБАЛЛАР

Ерак Көнчыгышта, Урта Азиядә, Украина, Кырым далалары уртасында бихисап таш балбаллар басып тора. Татар кешесе! Аларга очрый калсаң, баш и! Алар – ата-бабаларыңның, ана-корткаларыңның рухы. Дога кыл!

Чикмән кигән, янбашына кылыч таккан, уң кулына тустак тоткан яки ялан-башлы, мыеклы, кәҗә сакаллы, буе метрике метр ярымнан артмаган һәм гранит, мәрмәр яисә тау ташыннан ясалган сыннар белән унбер мең чакрым җир тулган!

Меңләгән балбаллар арасында хатын-кыз сыны күбрәк. Бу ни дигән сүз? Учак җылысын, учактагы утны сүндермичә саклаучы – ана, газиз телне саклаучы – ана, токымны тәрбия кылучы – ана. Келәм-палас сугучы – ана, җәйге челләдә бозылмаслык ризык, казы, каклаган ит әзерләүче – ана. Токымның дәвамы – анада. Бу сыннар бөек Ана хөрмәтенә бастырылган!

Янбашына кылыч аскан, тустаганда кымызмы, бузамы, сумы, җимеш сутымы тоткан балбал – кем? Атабыз, ир-ат! Ватанын, гаиләсен, балаларын, токымын саклап орышларга кергән, яуларда катнашкан, җәрәхәтләр алган һәм аты өстендә үлем белән көрешеп дала туфрагына егылган баһадир ул!

Бу сыннар – асыл татар-төрк угылкызлары хөрмәтенә калыккан мәңгелек һәйкәлләр.

САБАН ТУЕ

Бүгенге Сабан туен, бик борынгыдан килгән бәйрәм, дип сөйләргә күнегелгән. Ул, чыннан да, шулай. Сабан туен Олимпия уеннарының күчермәсе, дигән фараз да бар. Дөрес, Олимпия уеннары дүрт елга бер уздырылса, Сабан туе әлегәчә ел саен үткәрелә.

Кытай чыганакларында Сабан туена охшаш мәртәбәле чараны сурәтләгән язма бар. Бу бәйрәмне һәр Яңа елны каршылаганда татар дәүләтенең башлыгы Җания оештырган.

Ул башта Сабан туе дип аталмаган, Жыен (корылтай, тупланыш) дип йөртелгән.

Без үскәндә дә Жыен – аерым, Сабан туе – аерым бәйрәм ителә иде. Соңыннан гына аларның икесен куштылар.

Жыен – аксакалларның үзара киңәше булып, төрле мәсьәләләрне уртага салып хәл итәр өчен жыела иде. Бу йола тәңречелек заманыннан килгән: башта жыен (киңәшмә, фикер алышу) уздырылган, хөкем чыгарылган, аннан соң бәйрәм ясаганнар.

Борынгы бабалар әүвәл Күккә (Тәңрегә, Кояшка), аннары Җиргә, аннары рухларга, әрвахларга багышлап корбан чалганнар. Корбан итеннән бөтен халык (будун) авыз иткән.

Аннан соң ат узышлары, дөя ярышлары башланган. Узышларны Җания үзе күзәткән һәм үзе үк нәтиҗә чыгарган.

Җания идарә иткән елларда җинаять кылыну бик сирәк күренеш булган. Кылынган очракта, баягы чарада җыелган халык алдында бу кешенең җинаятен фаш иткәннәр, аңа нинди җәза бирү турында киңәш-табыш корганнар. Яргулауны (ягъни хөкемне) Җания оештырган.

ХӨКЕМ ҺӘМ ҖӘЗА

Гаепсез кешегә һөҗүм итү борынгыларда иң зур җинаятьтән саналган. Андый адымга барган кешене, җинаяте расланса, үлемгә хөкем иткәннәр. Яки аның шайтан сөяген (ашык сөяген) чәрдәкләгәннәр. Яисә җинаятьченең гаиләсе, каршы якка салган зыянын кайтарып бетергәнче, кол булып торган.

Сугыш вакытында һәр киселгән дошман башы өчен зур мөгезгә шәраб салып биргәннәр.

Сугышта кулга төшерелгән мал – җиңүчегә ганимәт, әсирләр җиңүчегә кол булган.

Фетнә күтәргән яки йортта кара гауга чыгарган кешене үлем җәзасына хөкем иткәннәр.

Бозыклык, фахишлек өчен (җинаятенең зурлыгына карап) ир кеше печтерелгән яки гәүдәсе кылыч белән урталай ярдырылган.

Башка берәүнең күзен яралаган кеше зыян күрүчегә кызы белән түләгән. Кызы булмаса, хатыны белән түләргә мәҗбүр ителгән. «Күз өчен кыз» гыйбарәсе шуннан калган, мөгаен.

ХАТЫН-КЫЗГА МӨНӘСӘБӘТ

Борынгы татар дәүләтләрендә хатын-кызга мөнәсәбәт аеруча хөрмәтле булган, ир-егетләр үзләрен бик әдәпле тотканнар. Йортка килеп керүгә, ир бала иң башта анасына баш игән, аннан соң атасы алдына йөгенгән.

Кияүдәге хатынны көчләгән кешегә үлем җәзасы бирелгән.

Игътибарга алыйк: татар илендә хатын-кызны көчләү хакимияткә каршы баш күтәрү, ватанны сату, кеше үтерү кебек зур җинаятьләр белән бертигез күрелгән.

Ахыры киләсе санда ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе*



Элек Ушковларныкы булган затлы йорт

1919 елда Казанның Үзәк китапханәсе шәһәребезнең иң матур урынына – элек эшкуар-сәнәгатьче Ушковларның затлы аерым йорты булган бинага күчерелә.

1925 елда М.Вахитов исемендәге Үзәк шәрык китапханәсен В.И.Ленин исемендәге Үзәк китапханәгә кушарга, дигән карар чыгарыла. Дәүләт бюджетына күчереләчәге, әдәбият белән тәэмин итү өчен өстәмә финансланачагы да искәртелә. Нәкъ менә шушы дәвердә китапханә фондын милли әдәбият җәүһәрләрен саклау урыны итәргә, дигән бурыч куела. Бу максатка ирешү фәкать 1929 елда, китапханә типографиялардән чыккан һәр басманы түләүсез һәм мәҗбүри алдыра башлагач кына мөмкин була.

1920–1930 нчы елларда китапханәнең директоры булып менә кемнәр эшли: Д.Калинин (1919-1922), Н.Семенов (1923), А.Гумеров (1923-1935), Ф.Никулин (1935-1938), Г.Жданов (1938-1939).

Рәисә Зариф кызы Мөхетдинова

1934 елда Үзәк китапханә – Өлкә китапханәсе, ә инде 1941 елда Республика китапханәсе итеп үзгәртелә һәм республика күләмендә китапханә эшләрен җитәкләүче методик үзәк функциясен үти башлый. 1939-1962 елларда китапханәне **Рәисә Зариф кызы Мөхетдинова** җитәкли.

Бөек Ватан сугышы чорындагы китапханә эшчәнлегенең мөһим тармакларын

*Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.

искә төшерик: гади эшчеләр арасында һөнәргә өйрәткән техник әдәбиятны пропагандалау; госпитальдәге яралы солдатлар өчен күчмә күргәзмәләр, һөнәри мәктәп-училищеларда, эшче тулай торакларында, завод-фабрика цехларында күргәзмәләр оештыру; үзлегеңнән белемеңне күтәрү кабинетлары эшчәнлеген җайга салу... Әлбәттә, сугыш чорының авырлыгы үзен бөтен өлкәдә дә сиздерә; ягулык җитми, кәгазьгә кытлык; финанс ягыннан кысылу сәбәпле, вакытлы матбугатка да мулдан язылып булмый. Әмма шуңа да карамастан, эш туктамый, «Татарстан Республикасының производство мөмкинлекләре», «Бөек Ватан сугышы чорында татар халкының данлы уллары» дигән саллы библиографик күрсәткечләр басылырга әзерләнә. 1945 елда инде китапханәнең эшчәнлеге ныклы эзгә төшә башлый, күрсәткечләре яхшыра.

Маһирә Харис кызы Делешова

1962-1986 елларда китапханә директоры булып **Маһирә Харис кызы Делешова** эшли.



ОБ УТВЕРЖДЕНИИ УСТАВА РЕСПУБЛИКАНСКОЙ БИБЛИОТЕКИ ТАТАРСКОЙ АССР имени В. И. ЛЕНИНА

ПОСТАНОВЛЕНИЕ СОВЕТА МИНИСТРОВ ТАТАРСКОЙ АССР
от 20 июня 1966 г. № 331

Утвердить прилагаемый Устав Республиканской библиотеки Татарской АССР имени В. И. Ленина.

УТВЕРЖДЕН
постановлением Совета Министров ТАССР
от 20 июня 1966 г. № 331

УСТАВ
РЕСПУБЛИКАНСКОЙ БИБЛИОТЕКИ ТАТАРСКОЙ АССР
имени В. И. ЛЕНИНА

§ 1

Республиканская библиотека Татарской АССР имени В. И. Ленина является государственной научной библиотекой универсального профиля; республиканским хранилищем отечественных произведений печати, рукописных книг, литературы на татарском и иностранных языках; научно-методическим центром по руководству работой государственных массовых библиотек ТАССР, базой Министерства культуры ТАССР по координации и кооперированию деятельности библиотек всех ведомств и организаций на территории республики и оказанию методической помощи им.

Республиканская библиотека Татарской АССР имени В. И. Ленина открыта для всех граждан. Пользование библиотекой бесплатное.

§ 2

Республиканская библиотека Татарской АССР имени В. И. Ленина как государственная научная библиотека универсального профиля призвана путем использования всех средств пропаганды литературы и методов работы с читателем оказывать помощь партийным и советским органам в коммунистическом воспитании населения, в развитии народного хозяйства, науки и культуры; способствовать повышению научной и производственной квалификации специалистов.

В этих целях библиотека:

а) предоставляет свой фонд для использования всеми читателями в общих и специализированных читальных залах, отраслевых отделах и выдает по абонементу литературу на дом. При этом основное внимание сосредотачивается на пропаган-

В.И.Ленин исемендәге Республика китапханәсе Уставының титул бите



Разил Исмәгыйль улы Вәлиев

1965 елда, йөзьеллыгы уңаеннан, китапханәгә фәнни китапханә статусы бирелә. В.И.Ленин исемендәге Республика китапханәсенең Татарстан АССР Министрлар Советы чыгарган 331 нче Карары белән расланган Уставында эшчәнлек юнәлешләре билгеләнә: халык хуҗалыгын, фән һәм мәдәниятне үстерүдә ярдәм итү; укучылар белән эшләү алымнарын камилләштереп, басма чыганакларны пропагандалап, фән һәм сәнәгать белгечләренең осталыгын күтәрүгә ирешү.

Китапханә директоры вазыйфасында М.Х.Делешованы **Разил Исмәгыйль улы Вәлиев** алмаштыра, ул 1986 елдан алып 2000 елга кадәр җитәкчелек итә. Әлеге дәвер китапханә тарихына мөһим үзгәрешләр чоры булып кереп кала. Татарстан Министрлар Кабинеты 1991 елның 5 ноябрендә кабул иткән 471 нче Карар нигезендә В.И.Ленин исемендәге Республика фәнни китапханәсенә, милли мәдәни үзәк буларак эшчәнлеген тагын да колачлырак итү максатыннан чыгып, Милли китапханә статусы бирелә.

Шушы чорда, тарихи-мәдәни мирасны киләчәк буыннар өчен дә саклауны күздә тотып, «Мәдәният турында», «Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында», «Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану турында» Татарстан Республикасы законнарын да кертеп, әзлекле норматив-хокукый нигез эшләнә. 1998 елда кабул ителгән «Китапханәләр һәм китапханә эше турында»гы Татарстан Республикасы Законында Милли китапханәнең юридик статусы һәм, күптармаклы белешмә-мәгълүмати, фәнни-тикшеренү оешмасы, мәдәни, библиографик һәм методик үзәк буларак, эшчәнлек юнәлешләре махсус маддәләрдә беркетелеп куела.

Китапханәнең Уставында да төп эш-максатлары ассызыклап языла. Җәмгыятьнең төрле катлау кешеләренә дә файдалану мөмкинлеге биргән китапханәнең Уставында да күрсәтелгән төп максаты – җәмгыятьнең күпкырлы мәгълүматка булган ихтыяҗын канәгатьләндерү максатыннан иҗтимагый, мәдәният, мәгариф һәм фән өлкәсендәге вазыйфаларын башкару. Милли китапханәнең асыл бурычы – республикабыз казанышларын, үзенчәлеген, рухи

мирасын, фәнни һәм мәдәни эшчәнлеген тулы җирлектә ачу. 2000 елдан алып 2015 елга кадәр китапханәнең директоры **Наил Әкрам улы Камбеев** булды.

Татар халкы мәдәниятен таныту үзәге, дөньяда татар китабын һәм республика турындагы әдәбиятны туплау, саклау һәм тарату белән шөгыльләнүче бердәнбер җәмәгать китапханәсе буларак Милли китапханәнең актив эшчәнлеге дәвам итте. 2015 елда Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең директоры итеп **Сөембикә Разил кызы Җиһаншина** билгеләнде.

Наил Әкрам улы Камбеев

Сөембикә Разил кызы Җиһаншина

Эшчәнлек юнәлешләре артуга бәйле рәвештә китапханәнең структурасы да киңәйде. Хәзер биредә егермедән артык бүлек эшли: укучыларга хезмәт күрсәтү; мәгълүмат-библиография; китапларны туплау; китапларны саклау; китапларны фәнни эшкәртү һәм каталоглар төзү; китапханәара абонемент һәм документларны электрон юл белән алдыру; автоматлаштыру-компьютерлаштыру; татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү; сәнгать; патентлар; кулъязмалар һәм сирәк китаплар; вакытлы матбугат; күргәзмәләр һәм мәдәни программалар; теркәү һәм статистика; фәнни-методик; чит илләр телләрендәге әдәбият; төбәкара һәм халыкара китап алмашу; маркетинг; редакция-нәшрият; китап укуга җәлеп итү һәм тышкы элемтәләр; китапханә-мәгълүмати технологияләр; китапларның сәламәт торышын саклау һәм аларны сипләп-яңартып тору; хуҗалык эшләре бүлекләре.

Китапханәнең фонды республика җирлегендә чыккан басма документларның бушлай мәҗбүри нөсхәләре килеп торуыннан тулылана бара. Моңа ниләр керә соң? Язма яисә сурәтле, ноталы, карталы басмалар, кануни документлар, аудиовизуаль продукция (кино-, видео-, фото- һәм фонодокументлар); электрон басмалар, шул исәптән ЭХМ программалары, мәгълүмат тупланмалары, CD- һәм DVD-дисклар, типография ысулында басылмаган документлар (диссертацияләр, фәнни эзләнү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре хакында хисаплар, саклану өчен бирелгән хезмәтләр). Хәзерге көндә китапханә хәзинәсендә җамгысы 3,27 млн. данә документ саклана. Шулардан 120 меңе – татар телендәгеләр, 81 меңе – чит илләр телләрендә.

Китапханә фондында И.А.Второв һәм И.А.Сахаров, иске басма рус китаплары (1830 елга кадәрге) тупланмалары аерым урын алып тора. Кулъязмалар һәм сирәк

китаплар бүлеге фондында татар, гарәп, төрек, фарсы, рус һәм башка телләрдә 14 мең данә аерым кыйммәткә ия китаплар, өч меңгә якын кулъязма, фоторәсемнәр, революциягә кадәр басылган вакытлы матбугат төпләнмәләре, бик кечкенә күләмле җәүһәр басмалар саклана. Монда кулъязма әсәрләрдән Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасының күчермәләре, 1699 елда кулдан күчереп язылган Коръән, XIV гасырга караган фәлсәфи-этик язмалар җыентыгын, татар галәменең бөек шагыйре Г.Тукайның, танылган мәгърифәтчеләр Ш.Мәрҗани, К.Насыйриның үзләре исән дәвердә басылып чыккан әсәрләрен күрергә була.

Уникаль басмалар өч тупланмага берләштерелде: 1722-1917 елларда чыккан татар басма китаплары коллекциясе, Коръән коллекциясе һәм шәрык телле кулъязмалар тупланмасы. Танылган галимнәрдән Ә.Г.Кәримуллин, Р.Үтәбай-Кәрими, Ү.Байчура, Ә.Р.Тенишевның шәхси китапханә һәм архивларыннан документлар алынып, аерым тупланмалар оештырылды. Чит илдә яшәүче татарлардан килгән басма һәм кулъязма истәлекләр әкренләп татар эмиграциясе фонды буларак формалашты. «Татарика» фонды яңа басмалар белән даими тулыланып баетыла бара. Милли җыр-музыка сәнгатенә караган ноталы басмалар, танылган шәхесләрнең култамгалы җыентыклары – китапханәнең кабатланмас байлыгы.

Милли китапханәнең иң кыйммәтле хәзинәсе – республикада гына түгел, аннан читтә дә татар телендә нәшер ителгән басмалар, Татарстан һәм татар халкы турында төрле телләрдә дөнья күргән китаплар фонды. Татар халкының тарихына һәм мәдәниятенә караган асыл тикшеренүләрне, белешмә әдәбиятны, статистик материалларны да үз эченә алган бу фонд татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлегендә саклана. 1971 елда оешкан әлеге бүлек укучыларга күптөрле гыйлем тармакларын чагылдырган татарча хезмәтләрне, татар әдипләре әсәрләренең, башка телләрдән татарчага тәрҗемә ителгән матур әдәбиятның 1928 елдан алып 1939 елга кадәр латин хәрефләрендәге, 1940 елдан безнең көннәргәчә кирилл хәрефләрендәге басмаларын тәкъдим итә.

Китапханә хезмәткәрләре ел саен оештырыла торган фәнни-археографик сәфәрләрдә катнашалар. Нәтиҗәдә, илнең төрле өлкәләреннән табылган кулъязмалар, иске басмалар, фоторәсемнәр, кадими открыткалар, архив документлары хисабына фонд хәзинәсе тулылана бара. Китап культурасы үзәге буларак китапханә аерым кыйммәткә ия документларның күчермәсен эшләтеп, республикакүләм саклау фонды оештыруга ярдәм итә. Китапханә штатында 238 хезмәткәр санала, шуларның 182-се – югары уку йортларын тәмамлаган белгечләр.

«2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасын тормышка ашыру җәһәтеннән Милли китапханә республикадан читтә яшәүче ватандашларыбызны татар һәм рус телләрендәге милли һәм туган якны өйрәнүгә караган әдәбият, газета-журналлар, аудио-, видеоматериаллар белән даими тәэмин итеп тора. Бу эшне Милли китапханә башка регионнардагы китапханә-абонентлар белән килешүләр төзеп башкара. Татар телен өйрәнүгә ярдәм итү, татар мәдәниятен, әдәбиятын популярлаштыру башка төбәкләрдә яшәүче татарларның ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә дә юнәлтелгән.

Китапханә эшчәнлегенең эзлекле үсеше – аның мәдәни, мәгърифәт, информация һәм фәнни эзләнүләр үзәге статусына ия икәнен гамәлдә раславы белән бәйле. Милли китапханәнең иң мөһим бурычлары – эш алымнарына яңалык кертү, хезмәт күрсәтү мөмкинлеген киңәйтү, кулланучыларны мәгълүмат белән тәэмин итү өлкәсендәге халәтне һәм таләпләрне анализлап эшчәнлек формаларын

төрлеләндерү, социаль проблемаларны хәл итүдә йогынтыны көчәйтү өчен халыкны җәлеп итәрлек күркәм имидж булдыру. Шулай ук китапханә эше шәхес һәм җәмгыятьнең мәгълүмат туплау культурасын тәрбияләүгә, китапханә эшчәнлегенең инфраструктурасын булдыруга, дөньяви фикер омтылышы яссылыгында профессиональ аң-белемне үстерүгә, демократик җәмгыять ирешкән рухи кыйммәтләрне югары кимәлдә аң-зиһенгә сеңдерүгә, замана таләпләренә буйсынып, коллега-белгечләр белән, шул исәптән халыкара киңлеккә чыгып, даими бәйләнешкә керү, аларның хезмәтләре белән танышуны җанландыруга юнәлтелгән. Агымдагы эшчәнлек документларны барлау, туплау, теркәү-исәптә тоту, шулай ук аеруча әһәмиятле документларны цифрлаштыру белән бәйле яңа информатизация чараларын нәтиҗәле куллану һәм үстерүгә нигезләнә.

Югары статус бирелү Милли китапханә эшчәнлегенең сулышын киңәйтеп җибәрде, моңарчы булмаган һәм өстәмә хезмәтләрне күрсәтү өчен яңа бүлекчәләр төзелде. 1999 елда мәгълүмат-библиография бүлеге нигезендә Республика хокукый мәгълүмат үзәге (Россия Президенты карамагындагы хөкүмәт элемтәсе Федераль агентлыгы белән килешү төзелеп) һәм Мәдәният-сәнгать мәгълүматлары үзәге оештырылды (министрлык әһелләренә, мәдәни-агарту оешмаларына һәм уку йортларына мәгълүмат һәм белешмәләр бирүне күздә тотып).

Милли китапханә республикабызның әдәби һәм мәдәни тормышында чын

Татар ПЕН-клубы әгъзаларының татар әдәбияты классигы Габдулла Тукайга багышланган «түгәрәк өстәл» мәҗлесендә катнашучылар китапханәнең «Мәгарә» залында (сулдан-уңга): басканнар – Разил Вәлиев, Равил Фәйзуллин, Әхәт Мушинский, Ркаил Зәйдулла; утырганнар – Рафаэль Мостафин, Нурихан Фәттах, Илдар Юзеев, Әмирхан Еники, Миркасыйм Госманов, Туфан Миңнуллин. 1996 ел

мәгънәсендә кайнап торган үзәккә әверелде. Разил Вәлиев инициативасы белән башланган **«Ел китабы»** дигән республикакүләм конкурс инде менә өч дистә ел дәвамында үткәрелеп килә. Ел саен иң укыла торган, иң шәп китаплар, күпсанлы укучыларны җәлеп итеп, ачыклана һәм аларның авторлары истәлекле бүләкләргә лаек була. Бөтендөнья язучылары Халыкара ПЕН-клубының Татар ПЕН-үзәге 1996 елда оешып, шушы китапханә «куенында» эшли башлавы да табигый. Татар әдәбиятының күренекле әсәрләре инглиз, төрек, рус телләрендә басылып чыккан

ЯДКӘРЛӘРГӘ – БЕР ГАСЫР

Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондыннан

1917 елның 1 ноябре

КАЗАН ГУБЕРНА КОМИССАРЫ ЧЕРНЫШЕВНЫҢ МАМАДЫШ ӨЯЗ КОМИССАРЫНА ТЕЛЕФОНОГРАММАСЫННАН

Минем тарафтан алынган телеграммаларның күчермәләрен хәбәр итәм. Петроградта большевикларның чыгышы бастырылды. Мәскәү гарнизоны Вакытлы хөкүмәтне яклап чыкты. Керенский һәм Родзянко Мәскәүдә яңа хөкүмәт төзи. Казанга хакимиятне большевикларга бирмәскә. Икенчесе: Игълан итәм: мин, Вакытлы хөкүмәтнең министр-рәисе һәм Россия Республикасының барлык хәрби көчләре Башкомандующие, бүген Ватанга тугрылыклы калган фронт гаскәрләре башында килдем. Аңламыйча яки буталып Ватан хыянәтчеләре, революцияне сатучылар шайкасына кушылган барлык частьларга бер сәгатькә дә соңармыйча кайтып, үз бурычларын үтәргә боерам. Бу әмерне бөтен роталарда, командаларда, батареяларда, эскадроннарда, сотняларда укырга боерам... А.Керенский. Өченчесе: Ватанны һәм революцияне коткару комитеты гаскәрләре тарафыннан барлык юнкер училищелары һәм казак частьлары азат ителде, Михаил сарае алынды, броневиклар һәм орудие автомобильләре кулга төшерелде, телефон станциясе алынды һәм изоляциядә калган, большевикларның соңгы сыену урыны булган Петропавловск крепосте һәм Смольный институты биналарын алу өчен көчләр туплана.

Тулы тынычлык сакларга, Ватанны һәм революцияне коткару армиясе командующие полковник Полковниковның сугышчан әмерләрен үтәгән комиссарларга һәм офицерларга мөмкин булган бөтен ярдәмне күрсәтергә, үзләрен хәрби-революцион комитет дип атаучыларның комиссарларын кулга алырга тәкъдим итәм...

Бу телеграммаларны хәбәр итеп, Россия Республикасының Вакытлы хөкүмәте исеменнән аларны халык арасында таратырга һәм авыр вакытта Ватан алдындагы бурычларын онытып, революцияне һәм азатлыкны саткан һәм Учредительное собраниене җыюны өзәргә омтылган җавапсыз затлар өеренең хакимиятне кулга төшерүенә юл куймаска боерам.

ТР ҮДА ТСД, ф. 5599,тас.1, э.1б, 65б. Күчермә.

Документлар урыс теленнән тәрҗемә ителеп бирелә.

1917 елның 10 ноябре

ЛАЕШ ӨЯЗ ҖИР УПРАВАСЫНЫҢ КАЗАН ГУБЕРНА ҖИР УПРАВАСЫНА ХАТЫ

Лаеш өязе буенча бөтен җирдә шәхси биләмәләргә һөҗүмнәр бара. Икмәк һәм терлек талана. Шәхси биләмәләрдәге корылмалар яки сүтеп алып кителә, яки яндырыла.

Талау һәм янгыннар стихияле төс һәм күләм алганга күрә, аларны туктату өяз җир управасының көченнән килми һәм ул бу турыда Губерна җир идарәсенә хәбәр итеп, моңа бәйле күрсәтмәләр көтә.

ТР ҮДА ТСД, ф.174, тас.1, э.83, 58б.

1917 елның 22 ноябре

ЛАЕШ ӨЯЗЕНЕҢ ДЕРЖАВИНО ВОЛОСТЕ ҖИРБИЛӘҮЧЕСЕ ХӘСӘН ТАҺИРОВНЫҢ АВЫЛ ХУҖАЛАРЫНЫҢ КАЗАН ГУБЕРНА БЕРЛЕГЕНӘ ГАРИЗАСЫ

Ноябрь аеның 15ендә Барск-Бирма авылы крестьяннары минем утарымны талап, игенне, барлык терлек-туарны, авыл хуҗалыгы коралларын һәм өйдәге бөтен әйберләрне төяп алып киттеләр. Каралты-кура әлегә калды. Талауда ул авылның барлык крестьяннары да катнашты. Урланган әйберләрнең исемлеген төзеп һәм китерелгән зыянны хисаплап, Берлеккә тапшырырмын. Берлектән мөмкин булган ярдәмне күрсәтүен һәм китерелгән зыянны каплатуын үтенеп сорыйм.

ТР ҮДА ТСД, ф.174, тас.1, э.83, 370б.

1917 елның 23 ноябре

КАЗАН ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫ КАРШЫНДАГЫ МИЛЛӘТЛӘР ВӘКИЛЛӘРЕ УТЫРЫШЫ БЕРКЕТМӘСЕННӘН

Катнашалар: 1.Бөтенроссия мөселман хәрби шурасы комиссары подпоручик Габдерәшитов; 2.Аның иптәше мичман Мәкъсутов; 3.Украина генераль гаскәри комитеты вәкиле чиновник Поповский; 4.Казан Украина громадасы вәкиле поручик Чикилевский; 5.Баш поляк хәрби башкарма комитеты вәкиленең урынбасары прапорщик Михаловский.

Подпоручик Габдерәшитов рәислек итә. Казан хәрби округы штабы каршында милли гаскәрләр булдыру мәсьәләсе карала.Чиновник Поповскийның докладыннан соң, Округ белән идарә итү Советына тәкъдим итү өчен, шушы әмер проекты карала:

Армияне үзгәртеп кору принцибыннан чыгып, милли-территориаль нигездә, Округ белән идарә итү Советы, штаб каршындагы милләтләр вәкилләренең тәкъдиме буенча... билгеләнгән принципны гамәлгә ашыру һәм милләтләр белән бәйле барлык мәсьәләләрне хәл итү өчен... округ штабы каршында мөселман, украин, һәм поляк, кирәк булган очракта, башка бүлекчәләр белән дә, милли гаскәрләр бүлеген оештыра...

ТР ҮДА ТСД, ф.36, тас.1, э.105, 20б.

*Документларны басмага **Римма Садыйкова** әзерләде.* ■

E-mail: prm.archive@tatar.ru
www.arhiv.tatarstan.ru

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

ХОТНЯДАГЫ «ИЗГЕ ЧИШМӘ»

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

Арча районындагы Хотня авылы турында XIX йөзнең икенче яртысында И.А.Износков менә ниләр язган: *«Хәзерге алпавыт бакчасы урынында элеккеге татар авылы Буклавычның зираты булган. Бакчадагы зур ташлар салып эшләнгән мәгарә астыннан үз агымы белән күлгә чишмә чыга. Монда зиярәт кылырга килүче татарлар, мәгарәдә шөһрәтле изге кеше җирләнгән, диләр»*. Замагында Перцовларның берсе чишмәне, җирле халык килеп йөрмәсен, дип, чүп-чар өеме белән күмдереп тә куйган була. Әмма, гаиләсе авырый башлагач, чишмәне төзекләндерермен, дип нәзер әйтә. Савыккач, вәгъдәсендә тора һәм тирә-яктагы татар авыллары халкы чишмәгә янәдән йөри башлый.

Хотня авылындагы «Изге чишмә» һәм аның тирә-ягы «Таттелеком» АҖнең генераль директоры Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин һәм аның хезмәткәрләренең иҗтиһады белән заманча төзекләндерелде, анда ял итү, су коену урыннары булдырылды. ■

Су коену урыны

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның ноябрь ае

Сәхифәне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Властьның советларга күчүе

3 ноябрьдә, көндез сәгать 2дә Театр мәйданында, Дворянски собрание алдында Революция штабы тантаналы рәвештә властьны Эшче, солдат вә крестьяннар советына бирде. Иң әүвәл Ершов сөйләп, хәзер властьның бөтен халык кулында булганын, моннан соң чын хөрриятнең вөҗүдкә [мәйданга] чыгачагын бәян кылды. Башкалар да шул рухта сөйләделәр. Соңыннан музыка илә солдатлар таралды.

Кояш. – 1917 – №1180. – 8 ноябрь.

Мөселман юнкерлар дикъкатенә

Главный штабның Казан штабына бирелгән телеграммына күрә, бу көннән прапорщик школасын тәмам итә торган юнкерлар, әфитсәр булгач, тугрыдан-тугры Симферопольдәге 32 нче полкларга гына йибәрелергә тиешлеләр. Бөтенрусия мөселманнары Хәрби шурасының Казан округы штабындагы комиссары подпоручик Габдулла Габдерәшидов.

Кояш. – 1917 – №1182. – 14 ноябрь.

Реферат укыла

Дүшәмбе көн, 20 ноябрьдә, сәгать 4 ярымда Казанда укучы мөселман яшьләренең «Берек» оешмасы квартирасында оешманың әдәби түгәрәге әгъзасы Габделбари әфәнде Биккинин «Татарлар вә аларның әдәбияты хакында тарихи мәгълүмат» дигән эчтәлектә әдәбияттан беренче реферат укыячак.

Кояш. – 1917. – №1184. – 19 ноябрь.

№10

Учредительное собрание сайлауларында, мөселманнар, шушы унынчы номер спискәгә тавыш бирегез. Казан мөселман социалистлары, кушылып, Учредительное собраниегә мөселман социалистлар списогын чыгарырга булдылар. Списокка кергән кандидатлар: 1) Ильяс Алкин – Хәрби шура рәисе; 2) Әхмәдбәк Салихов – Бөтенрусия мөселманнарының Милли шурасы рәисе; 3) Мулланур Вахитов – Социалистлар комитетының рәисе; 4) Фатих Мөхәммәдьяров – доктор; 5) Җиһангир Алкин – Хәрби шура әгъзасы; 6) Шәһид Әхмәдиев – «Аваз» газетасының мөхәррире; 7) Гатаулла Баһаветдин – гаскәри ахун; 8) Мирсәед Солтангалиев – Казан өязе земствосының мөхәррире; 9) Хатиб Мөхетдинов – Мәркәз укытучылар бюросының әгъзасы.

Дәреслекләр йитештерү оешмасы

Ишетүемезгә күрә, Казанда укыту эше мөтәхассыйсләре [белгечләре] вә зыялыларымыз тарафыннан татар мәктәпләренә дәреслекләр йитештерү өчен һәйәт гыйльмия тәшкил ителгән. Бу һәйәтнең беренче мәҗлесе хәзерге көндә түбәндәге

Даталар иске стиль белән бирелә.

эшләрне башлаячак икән: 1) ибтидаи мәктәпләр өчен татар тарихын язарга; 2) ибтидаи мәктәпләр өчен татар тарихы хрестоматиясен тәртип итәргә (беренчесе языла башлаган инде, икенчесенә материал җыела башланадыр; 3) һәйәт тарафыннан тикшерелеп чыгарылган китапларның имлясын бер тарызда [рәвештә] йөртү зарур табылган һәм шуның өчен, Бөтенрусия мөселман укытучыларының икенче съездында кабул ителгән имляга кирәкле хәрефләрне ясатырга йибәреләчәк. Һәйәт «Дәреслекләр йитештерү оешмасы» исемендә йөртеләчәк.

Кояш. – 1917. – №1186. – 26 ноябрь.

Талаулар

Чар өязендә Кече Битаман карьясе янында Фатима Апанаева һәм Әхмәдхуҗа Сәедовларның урманнан гыйбарәт булган имениесе бар иде. Шул кечек имениедәге хуторлар ошбу көннәрдә Бикнарат авылының мужиклары тарафыннан таланган. Болар, бикле йозакларны үтеп кереп, һәммә өй әсбапларын вә йорт әсбапларын «ганимәт мал» уларак талап китүләре белән бергә, йортларны ут төртеп яндыру белән дә янаганнар. Өйләрнең тәрәзәләрен дә берсен-бер калдырмыйча урыннарыннан куптарып алып киткәннәр. Хезмәтчеләргә өч көн миһләт [кичектерү] бирелгән. Шулвакыт эчендә аларга хезмәтчелектән ваз кичеп, үз авылларына кайтып китәргә боерылган. Талау өчен махсус агитация ясалып, Бикнарат авылы татарларының һәрберсе әлеге хуторга килергә, иң кимендә һәрбер йорттан бер кеше булырга договор ясаганнар. Дача янында иҗарәгә [арендага] бирелә торган тегермәннең бөтен каралтылары белән мужиклар кулына калырга тиешлеге бәян ителгән. Әгәр дә хуҗасы үз ихтыяры белән китмәсә, кыйнап җәзалау белән куркытканнар. Йир комитетының фәрманына да карамастан, бөтен урманнар бу көннән башлап киселеп бетәргә хөкем ясалган. Авыл белән авыл арасында низаг киткән. «Ганимәт маллар»ны бүлешү вакытында болар аз гына сугышмыйча калганнар. Бүлешә алмаганлыктан, ачу белән бәреп-ватып бетергәннәр.

Лекторлар кирәк

10 декабрьдән башлап Чар өязенең Күлле-Киме авылында өязнең земски управасы тарафыннан, мөселман милли мәктәпләре өчен укытучылар хәзерләү максаты белән, вакытлы педагогически курслар ачыла. Шул курсларда укытыр өчен мөселман лекторлар кирәк.

Шураның мәҗбүри карары

Гаскәргә кием-салым әзерләү урыннарында заказларны тиз генә арада өлгертеп булмау сәбәпле, Казанның Эшче, солдат вә крестьян вәкилләре шурасы, фронттагы гаскәрне һич кичектерми җылы кием белән тәэмин итү өчен, түбәндәге карар бирде: 1) Казанның бөтен гражданнары кулларында булган артык җылы киемнәрен Солдат, эшче вә крестьян вәкилләре шурасына тапшырырга тиешләр; 2) һәрбер гаилә үзенең бер җылы нәрсәсен тапшырырга тиеш; 3) кеше саен ике пәлтә (җәйге вә кышкы), ике пар фуфайка, бер җылы чалбар, өч пар оек, бер одеал, бер пар перчаткасы гына булган гаиләләр бу мәҗбүри карарга керми; 4) балалар һәм хатын-кыз киемнәре алынмый. Әлеге карар буенча 29 ноябрь вә 5 декабрь арасындагы көннәрдә җылы нәрсә җыю булачак. Җыючы Шураның үз әгъзалары гына булып, нәрсә җыяр өчен аларның кулына Шура тарафыннан вәкаләтнамә бирелер. Бу вәкилләр, нәрсә биргән кешегә кул куеп, Шураның мөһере басылган квитанция бирерләр.

Кояш. – 1917. – №1187. – 28 ноябрь. ■

НОЯБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 2 октябрьдә Казанда журналистларның «Многоликая Россия» X Бөтенроссия ачык бәйгесенең йомгаклау тантанасы узды.

● 2-5 октябрьдә «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Рәдиф Сәгъди белән Ленар Гобәйдуллин Пермь өлкәсенең Барда районында эшлекле сәфәрдә булды.

● 3 октябрдә Казанның татар телендә белем бирүче 3 нче гимназиясендә «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире шагыйрь Ләбиб Лерон белән очрашу булды.

● Октябрь ае башында Татарстан китап нәшриятында күренекле язучы, тәрҗемәче һәм галим Лирон Хәмидуллинның Г.Тукай, Дәрдемәнд, М.Фәйзи, Ә.Еники, Ф.Туишев, Л.Хәмиди кебек атаклы шәхесләребез турындагы әсәрләре тупланган «Зарницы на горизонте» дигән китабы урыс телендә дөнья күрде.

● 5 октябрьдә Казан Кремлендә Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» республика фондының Попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиев республикабыз белән танышырга дип килгән чит ил журналистлары белән очрашты.

● 9 октябрьдә Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» Республика фондының Попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиев төрек тарихчы-профессорлары, фән докторлары Илбәр Ортайлы һәм Ташансу Түркәр белән очрашты.   Казан Кремлендә узган әлеге очрашуда Төркия һәм Татарстан арасындагы фән, мәдәният һәм тарихи мирасны саклау буенча хезмәттәшлекне үстерү мәсьәләләре каралды.

● 11 октябрьдә Чаллыдагы 54 нче гимназия укытучылары һәм укучылары, шулай ук яшь иҗатчылар «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон белән очрашты.

● 14 октябрьдә Казанның Кәрим Тинчурин бакчасында Хәтер көне – матәм чарасы узды.

● 20 октябрьдә Яшел Үзәннең А.М.Горький исемендәге мәдәният сараенда мәрхүм журналист Александр Филипповның яңа китабын тәкъдим итү чарасы үтте.

● 20 октябрьдә «Әкият» татар дәүләт курчак театры бинасында Г.Кариев исемендәге татар дәүләт яшь тамашачы театры Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, танылган драматург Рәдиф Сәгъдигә 60 яшь тулу уңаеннан юбилярның «Мәхәббәт утравы» диган спектаклен сәхнәгә куйды.

Спектакль алдыннан булган котлау вакытында «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон Россия мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте рәисе шәех мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин исеменнән мөхтәрәм язучыбызга Россия мөселманнарының иң югары бүләген – «Әл-Фәхр» орденын тапшырды.

● 20 октябрьдә классик язучыбыз Аяз Гыйләҗевнең әсәрләрен рус, төрек һәм венгр телләренә тәрҗемә иткән өч шәхес – Наил Ишмөхәммәтов, Фатих Кутлу һәм Арпад Галгоци бер-берсе белән Казанда очрашты.

● 22 октябрьдә Мәскәү шәһәренең «Москвич» мәдәният үзәгендә Рәшит Ваһапов исемендәге халыкара татар җыры фестивале концерты узды.

● 22 октябрьдә Азнакай шәһәренең 9 нчы «Салават күпере» балалар бакчасында татар телен өйрәтүче һәм татар төркемнәрендә эшләүче тәрбиячеләр арасында һөнәри «Сөмбелә» бәйгесе үтте.

Мирасворд



Су, кымыз салыр өчен тар авызлы, капчык сыман күн савыт

XX йөз француз әдибе

Идел буе Болгары шәһәре

Иван Крылов повесте

Франция һәм Германиядәге елга

«Ямашев» трилогиясе авторы

... Бикчәнтаева

«... Мәргән» дастаны

Юкәдән үрелгән кәрзин (диал.)

Җәя җебе

Нурланыш бирәмлеге

Г.Тукайның 1911 елда язган шигыре

Мәдинә шәһәренең борынгы исеме

1915-1917 елларда Оренбургта татарча чыккан сатирик журнал

... Сафиуллин (сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе)

Фасил Әхмәтовның Разил Вәлиев сүзләренә язган җыры

«... тәме» романы (Мәдинә Маликова)

Калакирмәннәрдәге эчке саклы (бор.)

Борынгы греклар гаскәрендә рота яки эскадрон

Камил Кәримов романы

Сагыш төсе

Санкт-Петербургта чыга торган әдәби журнал

Янып, көленнән кабат ярала торган мифик кош

«... вә Димнә»

Хәсәнов, Идиятуллин

Антал ... (мадьяр шагыйре)

Борынгы грекларда җиңү Алиһәсе

Рәхим, Ильясов

Язучы Газиз ...

Шагыйрь Ямаш Игәнәй туган авыл

Орышу, тиргәү

Кыргызстан акчасы

Шагыйрь Рафис Корбанның 2004 елда чыккан китабы

Латин хәрефе

... бүкәне

Көнбатыш Европада яшәгән борынгы халык

Иван Тургенев повесте

Гарәп хәрефе

Аз санлы төрки халык

Бер илдә, өлкәдә, төбәктә яшәүче барлык кешеләр (иск.)

... Байжиев (кыргыз әдибе)

10 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: Әҗем, Яхмос, «Өмет», ера, Голәм, флейта, Рәмзи, Дусым, Акай, Бөгелмә, илд, гошер, Архимед, Ким, юри, софа, хак, Ван, өсәк, Латыйп, Ея, чорма.

Өстән аска: Фидаи, Җамал, «Уклар», Садри, Мотыйгый, көләч, кираса, ая, Хәтер, «Мөгез», Кыям, Ядегәр, дог, еш, салпы, лайм, Мөлеков, рә, Фирм, Сөембикә, маш.

Рәис Габдулла төзеде.

В.И.Ленинның Казандагы музей-йорты

Безнең мирас №11 ноябрь 2017

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
ЕЛЪЯЗМАСЫ / НОЯБРЬ

• 785 ел элек (1232)
Кол Гали «Кыйссаи Йосыф» әсәрен иҗат итә башлый.

• 205 ел элек (1812)
Мәшһүр фикер иясе һәм дин белгече Габденнасыйр Ибраһим улы әл-Курсави (1776-1812), хаҗ сәфәренә чыккан юлында авырып китеп, Истанбул каласының Азиядәге өлешенә караган Искедар шәһәрендә вафат була.

• 100 ел элек (1917)
Ноябрь башында Мәҗит Гафуриның «Кызыл байрак» исемле шигырьләр җыентыгы басылып чыга.

• 95 ел элек (1922)
8 ноябрьдә Казанда беренче татар театрын рәсми рәвештә ачу тантанасы була.Театрга «Октябрь революциясе» исеме бирелә.Төрле оешмаларның тәбрикләреннән соң,Фәтхи Бурнашның «Җирсезләр» исемле әсәренең бер пәрдәсе уйнала.

• 90 ел элек (1927)
Газиз Губәйдуллинга Бакуда профессор дәрәҗәсе бирелә.

• 85 ел элек (1932)
25 ноябрьдә Казан дәүләт яшь тамашачылар театры ачыла.

• 80 ел элек (1937)
7 ноябрьдә Казанда В.И.Ленинның (1870-1924) музей-йорты ачыла.

• 75 ел элек (1942)
7 ноябрьдәТатар дәүләт академия театрында Нәҗип Җиһановның «Илдар» операсы (Муса Җәлил либреттосы) премьерасы күрсәтелә.

• 55 ел элек (1962)
10 ноябрьдә Мәскәүдә татар совет язучысы Мәхмүд Максуд (1900-1962) вафат була.

• 25 ел элек (1992)
6 ноябрьдә Татарстан Республикасының Төп Кануны – Конституциясе кабул ителә.

*Журналга **Марат Закир** әзерләде.* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2017



НОЯБРЬ 2017

Историческое наследие: «История турков и татар». А.Валиди; «История деревни Вязовый Гай». М.Вальшин; «Святые села Нырсы». Р.Нутфуллина; «Обращение большевиков к мусульманам и османская пресса». Н.Давлет; «Имя твоё и суть твоя». А.Сибгатуллина; «Муслим – край с исторической памятью». А.Ахметзян.

Татарский мир: «Память и родной язык». Р.Файзуллин; «Кутадгу билик» – ценное наследие» (пресс-конференция); «Развязывая «узел Шыгырдан». Ф.Кутлу.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Г.Ибрагимов.

Литературное наследие: «Таджеддин Ялчыгол». Р.Галиуллин; «Хотелось быть горным орлом!..» Ш.Мустафин; «Он для меня и братом был...» И.Нигмати; «Адаш абый или Отрарское воспоминание». Л.Лерон.

Художественное наследие: «Мандолина». Э.Каюмова.

Слово – украшение языка: «Словарь национальных терминов». А.Тимергалин; «Древние татарские обычаи». Р.Батулла.

100 лет назад...: «Казанские вести» в газете «Кояш»: ноябрь 1917 года.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. NOVEMBER 2017

Historic heritage: «Turkish and Tatar history» by A.Validi; «The history of Vyazoviy Gay village» by M. Valshin; «The sacred ones of Nyrsy village» by R. Nutfullina; «Lenin's government's address to the Muslims and the Ottaman press» by N.Davlet; «Your name and your inner world» by A.Sibgatullina; «Muslimovo is a district keeping memory» by A.Akhmetzyan.

Tatar world: «Memory and mother tongue» by R.Fayzullin; «Kutadgu bilik is a precious heritage (the conference of pressa)»; «Wrapping out the «Shigirdan's knot» by F.Kotlu.

Religious heritage: «The Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov.

Literary heritage: «Tadjeddin Yalchigol» by R.Galiullin; «I would like to be a mountain eagle!...» by Sh.Mustafin; «For me he was just like a brother too...» by I.Nigmati; «Uncle Adash or Otrar recollection» by L.Leron.

Artistic heritage: «Mandolin» by E.Kayumova.

Word is a language's decoration: «Dictionary of national terms» by A.Timergalin; «The ancient Tatar customs» by R.Batulla.

100 years ago...: «Kazan news» is in the «Koyash» newspaper: November of 1917».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

Рәссам Хәмзә Мәүлихан улы Шәрипов 1957 елның 4 февралендә Пермь өлкәсенең Барда районы Аклыш авылында туган.

1987 елда В.И.Мухина исемендәге Ленинград югары сәнгать училищесын тәмамлаган. Хәмзә Шәрипов – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, «Европа-Азия» Халыкара гуманитар академиясенең шәрәфле академигы, ТРның һәм Россиянең Рәссамнар берлекләре әгъзасы. Ул этник авангард стилендә иҗат итә. Чаллы каласында яши.

«Түгәрәк күл». Киндер, майлы буяу. 1995

ХӘМЗӘ ШӘРИПОВ





«Җайдак». Киндер, майлы буяу. 2014 ел

«Бер көй». Киндер, майлы буяу. 1995

4 612750 670172

*«**БЕЗНЕҢ МИРАС**» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*